1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН 2019 ОКТЯБРЬ № 10

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ЯҢА МОДА – ТРЕНИНГЛАР
тылсым таягы бармы

ИҢ АВЫРЫ – ХЫЯНӘТ
бәхеткә юллар урау

БАЛА БЕЛӘН... ЭЛЬБРУСКА
мин ачкан дөнья

Резеда НУРИСЛАМОВА:

ХАТЫН-КЫЗ ҺӘР ЧОРДА ҮЗЕНЧӘ МАТУР...

Минем өчен син һаман да – 17дә!..

Минем өчен син һаман да – 17 дә!..

Бу фотосурәтләр еракта калган кабатланмас мизгелләргә – Яшьлеккә алып китә... ...Шундый зур галәмдә меңнәр арасыннан бер-береңне эзләп табу – үзе үк могҗиза! Аны күргәч кабынган хисләр – иң саф, иң ихлас, иң садә... Йөрәктәге сагышы да – якты, татлы, моңлы... Беренче очрашу... Аның кебек башка берәү дә юктыр! Дөнья – матур, яшәү шундый рәхәт! Очар өчен канатлар кирәкми дә!.. Ярату, йөрәккә генә сыялмыйча, җанда шигырь булып бөреләнә... Һәм мәңгегә Син – Шагыйрь, Ул Илһамчың булып кала...



Тәуфикъ КАМАЛИЕВ

РОЗАЛАР

Ак розалар өздем берәмтекләп,
Розаларның исен кем сөйми?
Һәм шуларга кырау тимәсен дип,
Соң кайсыбыз инде көрсенми?!

Мин охшаттым сине
Яз башында
Кар астыннан чыгып сак кына,
Ачылам-ачылам диеп торган гөлгә,
Омтылганы хәлдә яктыга.

Өздем-өздем ап-ак розаларны,
Синең өчен аны өзәм мин;
Сеңлем итеп назлап, сөеп карыйм,
Син розалар кебек гүзәл, дим.

Берни булса хәзер кызарасың,
Ә үзеңдә күпме дәрт һәм наз!
Елмаюлар җанны җылыта төшсен,
Наз дигәнен чайпалт, түк бераз.

Гел очратам роза чәчәкләрен,
Утыралар җилдә сибелеп.
Арасында бигрәк берсе ошый.
Шунысына дәшәм, сеңел, дип.

Рәсемдә: шагыйрьнең хатыны Роза ханым Мулланурова. 1963 ел.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!


© «Сөембикә» 2019

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Фото: Анна Арахамия

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәмmәтова

Тышлыкта:
Резеда Нурисламова
Фото: Анна Арахамия

Верстка:
Резеда Галиуллина
Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Раилә Хәялиева
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 3.10.2019 ел.
Заказ О-2734
Тираж 4943

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»


ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002





Фото: Елена Сөнгатова – elena@art16.ru



Илдар Зарипов эше. «Сөембикә»



Розалина ШАҺИЕВА

Сөем-сөем-Сөембикә

...Кызыл Казан өсләреннән
очып бара киек казы –
Картлар әйтә: падишаһ ул –
Казан кызы,
Нәүмиз хатын Сөембикә.
Тол калмаган тоткынлыкта,
Тез чүкмәгән читенлектә,
Кол булмаган тар читлектә –
Атылмаган манарадан,
убылмаган бөеклектән –
Исән икән, илдә икән,
тере чыккан хәрабәдән
Сөем-сөем-Сөембикә...

Мәңге кара яра сыман
җиде катлы бу манара –
Ниләр күрдең шул арада?
Хәсрәт икән, һиҗрәт икән,
мәңге тере миһраҗ икән,
ил өстеннән ыңгырашып
искән каты җилләр икән,
Ташкын-ташкын мөһаҗирләр
үткән ачы юллар икән,
ачылмас гөл, уллар киткән
төпсез упкын, дәрья икән
Сөем-сөем-Сөембикә...



Безнең тышлыкта

«Конференцияләргә, күргәзмәләргә еш йөрергә туры килә. Әмма җитештерүчеләр арасында битенә инъекция ясаткан хатын-кызны, гомумән, күргәнем, очратканым юк.»



14 Күз яше кебек чиста...
Гөлнур Сафиуллина

Заман һәм без



6 Укытучы – үзе кодекс язучы
Чулпан Галиәхмәтова

Арча мичуринчылары 10
Лилия Гәрәева




20 Авылны яшәтүче ул!
Мәдинә Авзалова



Бөгелгән бил – сынмас 28
Гөлнур Сафиуллина

Татар дөньясы

32



Чит илдәге татар утравы
Раилә Хәялиева

Мәдәни тормыш



38

Зәйтүнә
Марат Әмирханов

Яшәеш

«Иң авыры – якыннар хыянәте...»
Чулпан Галиәхмәтова
48

52



Кырыс Эльбрус кырысмы?
Эльза Нәбиуллина

Хуҗабикә

62 Ташкабактан – спагетти

60



Таҗикча люля-кебаб

УКЫТУЧЫ – ҮЗЕ КОДЕКС ЯЗУЧЫ



Фото: Раилә Хәялиева

Укытучы – мәңгелек һөнәр диярдем мин. Нинди генә заманда яшәсәк тә, тормышыбызга төрледән-төрле инновацияләр, яңа технологияләр килеп керсә дә, укытучының роле кимемәячәк, киресенчә, артачак кына. Чөнки олы тормышка юлыбыз хәреф танып, сүзләр укудан, кулга каләм тотып язарга өйрәнүдән башлана. Ә укытучыларыбызның әйткән сүзләре, өйрәткән гыйлеме гомер буе безне озата бара. Мәгариф өлкәсендәге эш алымнарын заманага яраклаштырып яңартып тору – хакимиятнең бурычы. Россия мәктәпләрен дөнья күләмендә көндәшлеккә сәләтле итеп әзерләү максатыннан, илкүләм «Мәгариф» проекты гамәлгә керде. Ул 2024 елга кадәр исәпләнгән. Бу вакыт эчендә нинди үзгәрешләр булачак, педагогларны, ата-аналарны нинди яңалыклар көтә, гомумән, укытучыларның җәмгыятьтәге урыны хакында Татарстан мәгариф һәм фән министры Рафис БОРҺАНОВ белән әңгәмә кордык.



Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

Бүгенге көндә белем һәм тәрбия бирүдә мәктәптән дә яхшырак җәмгыять институты юк.

Рафис Тимерханович, әйдәгез, әңгәмәбезне укытучыларыгызны искә төшерүдән башлыйк әле.

– Мәктәп тәмамлавыма инде 40 ел. Шулай булуга карамастан, беренче укытучымның гына түгел, бөтенесенең дә исемен дә, кыяфәтен дә хәтерлим, барысы да күз алдымда. Сыйныф җитәкчем Щелкина Галина Николаевна күп хаталардан, ялгышлардан саклап калды мине. Авыр туфрагы җиңел булсын. Кызганыч, күбесенә рәхмәт әйтергә өлгермәдек тә. Алар, минемчә, бу дөньядан туп-туры оҗмахка күчкәндер, башкача була да алмый. Һәрберсе безне тәрбияләүгә, белемле итүгә үз өлешен кертте. Укытучыларымның күп сүзләрен бүген искә төшереп, яңа мәгънәләрен ачам.

Укытучыларның абруе аларның безгә салган тәрбияләрендә чагыла. Аларның һөнәренә мөнәсәбәте кешелек сыйфатлары буенча билгеләнә. Нәрсә генә әйтсәләр дә, теләсә кем укытучы була алмый ул. Мөгаллим – талант иясе. Шуңа да алар гомеребез буе йөрәк түрендә. Күп һөнәр ияләренең хаталарын төзәтергә була әле, ә менә укытучыныкы гафу ителми, аны төзәтеп тә булмый, чөнки 7 яшьлек балага бер елдан 8 яшь тула – вакыт югала. Шуңа күрә җаваплылык та башкача. Республикада мәгариф өлкәсенә катнашы булмаган кешеләр, гомумән, юк. Үзегез уйлап карагыз: 3 млн. 800 мең халыкның 430 меңе мәктәптә укый, 220 мең сабый балалар бакчасына йөри, югары уку йортларында – 150 мең, һөнәри урта белем бирү учреждениеләрендә 70 мең студент белем ала. Һәрберсенең ата-анасы, әби-бабасы бар. Бала туып, ике ай узуга мәгариф аның тормышына килеп керә, ә опекага калган балаларны тугач ук куенга алабыз. Республикага кереп барган «Абилимпикс» ярышларында 63 яшькә кадәр катнашырга була. Димәк, кеше гомер көзенә кергәч тә бездән аерылмый дигән сүз.

«Мәгариф» илкүләм проекты Россия мәктәпләрен дөнья күләмендә көндәшлеккә сәләтле итеп оештыру максатын куя. Татарстанда әлеге проект ничек гамәлгә ашырыла? Мәгариф системасында нинди үзгәрешләргә өметләнә алабыз? Нинди яңалыклар көтелә?

– Әлеге зур план берничә проектны колачлый. Башкарасы эшләр күп. Дөрес, Татарстанда моңа кадәр дә мәгариф өлкәсе игътибар үзәгендә булды. Балалар бакчасын гына алыйк. «Бәләкәч» программасы нигезендә күпме учреждениеләр төзелде, 2021 елга 1,5–3 яшьлек сабыйлар өчен балалар бакчасына чиратны бетерү бурычы куелды. Быел 30 объект кулланылышка тапшырылып, 3 яшькә кадәрге бәләкәчләр өчен 6 мең урын булдырыла. Ясле төркемнәре булган бакчалар төзү 2020–2021 елларда да дәвам итәчәк. Мәктәпләрдә икенче сменада укучылар санын киметергә, йә гел бетерергә тиешбез. Тик аның бер бик тә әһәмиятле ягы бар: шул рәвешле, тулы көнгә күчәчәкбез. Үзебез дә мәктәптә үстек. Иртән китеп, кич кенә кайта идек. Әйтергә кирәк, начар тәрбия алмадык. Бүгенге көндә белем һәм тәрбия бирүдә мәктәптән дә яхшырак җәмгыять институты юк. Һәм шулай булырга тиеш тә. Илкүләм проект кысаларында балалар бакчасыннан алып һөнәри колледжлар, югары уку йортлары яңа технологияләр белән җиһазланачак. Балаларга кечкенәдән үк һөнәр алу буенча юнәлеш бирү максатларында башкарыла бу. Эш урынына барып җиткәнче яшь кеше бөтенесен өйрәнергә, ягъни әзер кадр булырга тиеш. Безнең күп кенә программалар шуның белән бәйле. WorldSkillsның яңа циклын башладык. Ул яңа модалы сүз түгел. Бу эшне элек, Советлар Союзы вакытында да уңышлы алып бара идек. «Һөнәри осталык» бәйгеләре үткәрелде. Яшьләргә һөнәри квалификация алуга омтылыш тудырылды. Хәзер без балалар бакчасыннан ук кечкенәләрне һөнәрле итү юнәлешендә эшлибез. Бу яшьтә балага нәрсә биреп була икән дип кызыксынып, Кукмарада узган «Баласкилс»ка кергән идем... *(Кинәт җанланып.)* Анда нәрсә генә юк! Балаларны кәсепкә генә түгел, ике-өч телдә сату итәргә дә өйрәтәләр хәтта! Дөнья менә ничек үзгәрде. Яңа ихтыяҗлар, яңа таләпләр... Ә без, үз чиратыбызда, җәмгыятькә файдалы кешеләр үстерергә тиеш.

Әйе, Рафис Тимерханович, хәзер Z буыны үсә. Балалар шундый күп белә, барлык яңалыкны тизрәк «йотарга» тырыша. Моның өчен гаиләдә барлык шартлар тудырыла. Бу вазгыятьтә укытучыларга аеруча авырга туры килә, чөнки балалар гаҗәеп мәгълүматлы. Алар каршында абруй казану өчен укучылардан берничә адым алда булырга кирәклеге көн кебек ачык. Тик укытучылар җилкәсенә салынган бюрократик йөк аларның тулы потенциалын ачарга мөмкинлек биреп бетерми кебек... Вакытлары җитмәскә дә, дәртләре булып, дәрманнары булмаска да мөмкин. Министрлык бу юнәлештә нинди эшләр башкара?

– Укытучыларны кирәкле-кирәксез эшләрдән арындыру буенча һәрбер яңа карар чыгарган саен, мәшәкатьләре арта гына. Шуңа күрә аларның эшен җиңеләйтү буенча тавыш-тын чыгармас идем. *(Уйланып.)* Әгәр дә шушы булган йөк белән туктап калып булса... Дөрес әйтәсез, мәгариф өлкәсендә генә түгел, сәламәтлек саклау системасында да, башка төрле тармакларда да хисап алып барырга кирәк. Шунсыз анализ ясап булмый, анализ ясалмый икән, дөрес карарлар кабул ителмәячәк. Ләкин һәр җирдә чама булырга тиеш һәм бу мәсьәләдә дә...



Һәр халыкның телне тирәнрәк белергә теләгән, киләчәктә интеллигенция рәтләрен баетачак егет-кызлары бар.

Чама дигәннән... Мәктәпләргә гаджетлар үтеп керде, һәм укытучы белән укучы арасында килеп туган төрле четерекле хәлләрне социаль челтәрләргә чыгару очраклары ешайды. Укытучы да кеше! Тормышында төрле авырлыклар килеп чыгарга мөмкин. Ә аңа иртән укучылар каршына барып басарга кирәк. Министрлык укытучының эмоциональ халәтен кайгырту өчен нинди чаралар күрә? Бәлки, махсус курслар бардыр, бәлки, мәктәпләрдә алар өчен махсус психолог кабинетлары булдыру кирәктер?

– Сезнең белән килешәм. Бер дәрес эчендә укытучы укучыга караганда күбрәк арый, таушала. Ул берьюлы 30 кеше белән эшли. Аңа 30 кешенең характерын, энергетикасын үзе аша үткәрергә кирәк. Бу мәсьәлә буенча психологлар белән бергә киңәшмәләр үткәрәбез. Машина да бензинсыз йөрми. Укытучыга да ярдәм кирәк. Үзәкләштерелгән психологик хезмәт кенә оештырып булмый. Бәлки онлайн формада ясарга кирәк булыр... Бу эшне башкарып чыгуны озакка сузмабыз дип уйлыйм.

Россия Мәгариф министрлыгы Бөтенроссия Мәгариф хезмәткәрләре берлеге ярдәмендә «Һөнәри этика кагыйдәләре турында» кодексны яңартты. Анда язылганча, укытучылар баланың рухи үсешенә зыян сала торган мәгълүматларны социаль челтәрләрдә урнаштырырга тиеш түгел. Бу кешенең шәхси тормышына тыкшыну кебек кабул ителмиме? Укытучылар болай да бер калыпта яши торган кешеләр...

– Минемчә, укытучы үзе кодекслар яза торган кеше. Бертуктаусыз ничек эшләргә кирәген өйрәтеп, төрткәләп торсак, аның абруе югалмас микән? Дүрт-биш елдан соң ук кем булганнарын, нәрсә өйрәткәннәрен онытачакбыз бит. Педагогны бүгенге көне белән генә бәяләү дөрес булмас. Укытучылар турында яхшы уйлаучылар күп булса да, бу хакта язучылар бик сирәк. Кеше шундый бит инде ул, начарлыкны элегрәк күрә, аның турында тизрәк кычкырырга тырыша. Әлегә җәмгыятьтә нинди дер бер тенденция күзәтелә димме соң... Социаль челтәрләрдәге шәрехләмәләрне укып, бөтен республика шулай уйлый дип нәтиҗә ясый башлыйбыз. Ә аның өчен ата-ана белән киңәшләшергә кирәк. Һич кенә дә ашыгып нәтиҗәләр ясарга ярамый.

Гомумән, хәзерге җәмгыятьтә гасырлар буе килгән язылмаган кануннарны, тәртипне бер селтәнү белән юкка чыгарырга тырышу шаукымы бар. Шул ук дәреслекләр әллә ничә төрлегә үзгәртелде...

– Еш кына журналистлар миннән: «Нинди яңалыклар бар?» – дип сорыйлар. Ә минем өчен яңалыкларның булмавы яңалык. Процессны тизләтергә ярамый, бигрәк тә мәгарифтә. Бу уку программаларын үзгәртүгә дә кагыла. Аның бит стратегиясе, тактикасы бар. Ә стратегия, кимендә, ун-унбер елга исәпләнгән булырга тиеш. Нәтиҗәсен күрмичә, шундук үзгәртергә телибез. Ә асылы шул ук бит аның. Пифагор теоремасы, тапкырлау таблицасы үзгәрдеме, иллегә иллене кушкач йөз булудан туктадымы бүген? Ә бит санасаң, кырык ел эчендә күпме дәреслек, күпме яңа әсбап чыккан. Яңа фәннәр буенча сүзем юк. Төп фәннәр турында әйтүем. Рус теле һәм әдәбияты, татар теле һәм әдәбияты фәннәре турында әйтеп тә торасы юк. Алар – классика.

Татар телен өйрәнү мәсьәләсенә дә шул шаукым җилләре тиде микән әллә? Югыйсә телләр өйрәнүгә элек-электән үк омтылыш булган. Мәктәпләрдә татар телен укыту буенча низаглар әлегә кадәр тынмый. Баланың күп тел белүе көндәшлеккә сәләтлелеген арттыра гына бит. Тукай телен өйрәнергә теләмәгәннәр сәбәпне укыту программасының авыр булуы белән аңлата.

– Без укыганда татар теле дәресләре юк иде, әдәбият кына укыдык. Программа ел саен үзгәреп торды. Ләкин татарча укый да, яза да беләбез. Бәлки, барлык кагыйдәләрне белеп тә бетермибездер. Әмма укысаң, бар да истә кала. Минем үземдә күреп истә калдыру сәләте көчле. Укырга теләгән кешеләргә бүген мөмкинлекләр бар. Биология, физика, химия фәннәрен тирәнтен укый башлыйбыз икән, моның өчен борчылмыйбыз бит. Никтер тел мәсьәләсе генә каршылыкларга очрый. Ә бит һәр халыкның телне тирәнрәк белергә теләгән, киләчәктә интеллигенция рәтләрен баетачак егет-кызлары бар. Язучылар, шагыйрьләр, артистлар турында сүз бара. Кызганыч, татарча укыганнарга имтиханны туган телдә тапшырырга рөхсәт юк әлегә. Гәрчә бу теләктә бернинди яманлык та, начарлык та юк. Тел балаларны баета гына. Минем мөмкинлегем булып, балачакка кире кайтсам, өч-дүрт тел буенча 300 сүз булса да өйрәнер идем. Күп белсәң, бу зур дөньяда үзеңне иркенрәк тотасың бит. Республика мәктәпләрендә җиде тел туган тел буларак өйрәнелә, алты телдә белем бирелә. Уку йортлары кадрлар, укыту-методик ярдәмлекләр белән тәэмин ителгән. Белем бирүдә коммуникатив технологияләрне гамәлгә кертү максатыннан, Мәгарифне үстерү институты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Казан федераль университеты белән берлектә 1–9 нчы сыйныфлар өчен «Татар теле – Татарстан Республикасының дәүләт теле», «Туган тел», «Туган телдә әдәбият» фәннәреннән үрнәк уку программалары федераль реестрга кертү өчен әзерләнде. Хәзерге вакытта татар теле һәм әдәбияты буенча 1–9 нчы сыйныфлар өчен яңа буын укыту-мето-

дик комплектлар эшләнә. Республикада яшәүче башка милләт балаларына да туган телләрен өйрәнер өчен шартлар тудырырга тырышабыз. Норматив буенча сыйныфны комплектлаштыру өчен 25 бала кирәк. Без туган телне өйрәтү өчен сигез балага бер укытучы бирергә әзер. Чаллыда башкортлар туган тел дәресләрен укытырга мөмкинлек тудыруны сорап мөрәҗәгать иткәч, биш балага бер укытучы бирергә дә риза булдык. Сыйныф кына туплансын. Без һәр милләткә ярдәм итәргә әзер.

Мәктәпләр балаларны белемле итү, рейтингтан төшеп калмау максатларында каникулларга өеп өй эшләре бирәләр. Хәзерге укучыларның нагрузкалары шундый күп – урамга чыгып һава суларга да вакытлары юк. Ничек уйлыйсыз, балаларга бәйрәм вакытында, каникулларда өстәмә эш бирү дөресме?

– (*Елмаеп*.) Соравыгызны ни өчен елмаеп тыңлаганымны аңлыйсызмы? Быел Алла Пугачева башкаруындагы «Песня первоклассника»га 40 ел булды. Узган гасырда ук язылган җыр әле дә актуаль. Күрәсең, ул вакытта да мәктәптә уку җиңел булмагандыр. Дөнья, мохит үзгәреп тора, бүгенге балаларга кирәкле белемнәр күбәйде. Ләкин хезмәт урынындагы кебек, балалар өчен дә КЗОТ бар. Укыту сәгатьләренең саны чикләнгән. Шуңа күрә кем дә булса артык күп өй эше бирәләр дип уйлый икән, мәктәпкә барып сөйләшү урынлы булыр. 5 нче сыйныфка җиткәндә академик ясарга теләп, кызын йә улын барлык түгәрәк, секция, өстәмә дәресләргә йөртүчеләр баласының психикасында үзгәрешләр күрә икән, туктарга кирәк.

Россия Мәгариф министры Ольга Васильева үзенең бер әңгәмәсендә «Цифралы мәктәпнең киләчәге зур. Мәктәпләрне яңартачак, укытучыларга ярдәм итәчәк зур инфраструктура проект ул», – дип әйтә. Электрон дәреслекләр турында гына сүз бармый, виртуаль лабораторияләр, парта артыннан тормый гына Эрмитажда экскурсиядә йөрүләр керә моңа. Министр биш төбәк вәкиленең цифралы мәктәпләр буенча курслар узуы турында әйтте. Татарстан әлеге проектта катнашамы? Безнең мәктәпләр, аеруча авылдагы белем йортлары, моңа әзерме?

– Татарстан инде күптәннән белем бирүне мәгълүматлаштыру буенча эш алып бара. Бу – мәгариф системасын модернизацияләү буенча иң төп шартларның берсе. Республика мәктәпләрендә мәгълүматлаштыру 2000 елдан башланды. Быел «Цифралы белем бирү мохите» төбәк проекты кысаларында республиканың 15 мәктәбендә һәм 17 урта һөнәри белем бирү йортларында цифралы белем бирү мохитенең моделе кертелә. Шушы ук проект нигезендә балаларны цифралы, табигый-фәнни, техник һәм гуманитар юнәлешләр буенча әзерләү максатларында республиканың барлык муниципаль берәмлекләрендәге 97 мәктәптә «Үсеш нокталары» дип аталган белем бирү үзәкләре булдырылды. Биш елдан Татарстанда шундый 500 үзәк ачылыр дип планлаштырабыз. Белем бирү үзәкләре эшләгән мәктәпләрнең материаль-техник базалары яңартылды. Бу «Технология», «Информатика», «Тормыш иминлеге нигезләре» дәресләрен яңача укыту мөмкинлекләре тудыра. Моның өчен авыл җирлегендә эшләүче 146 технология укытучысы квалификацияләрен күтәрде. Моннан кала, информатика, технология, тормыш иминлеге нигезләре һәм өстәмә белем бирү буенча 424 педагог онлайн режимда әзерлек узды.

Беркемгә дә сер түгел, мәктәпләрдә ир-ат укытучылар аз. Ә бит хәзерге җәмгыятьтә тулы булмаган гаиләләрдә яшәүче балалар бик күп. Аларга ир-ат тәрбиясе җитеп бетми. Өйдә ата кеше – ир-ат юк, мәктәптә дә хатын-кызлар гына. Ир-ат укытучыларны җәлеп итү өчен нинди эшләр башкарыла?

– Аз дип кистереп үк әйтмәс идем. Өметле ир-ат укытучыларыбыз да бар. Педагогларның материаль хәлен яхшырту өчен республикада күп эшләр башкарылды. Мәсәлән, «Безнең яңа укытучы» грантын отучыларның хезмәт хакларына 8620 сум өстәлә. Ир-атны мәктәпләргә җәлеп итү өчен алда әйтелгән абруй да кирәк. Аларның хезмәте лаеклы рәвештә бәяләнсә, җәмгыятьтә хөрмәтле урын тотып торса, көчле затлар мәктәпкә бик рәхәтләнеп килер дип уйлыйм.

2020 елда илдә укытучыларны авыл мәктәпләренә җәлеп итү максатында «Земство укытучысы» программасы эшли башлый. Моңа кадәр дә Татарстанда авыл укытучыларына ярдәм итәләр иде. Әлеге программа нинди яңалыклар алып киләчәк? Авыл мәктәпләрендә мөгаллимнәр җитәрлекме?

– Әйе, әлеге программа гамәлгә ашырыла башлагач, шәһәрне калдырып, авыл мәктәбенә кайтып эшләгән укытучыларга торак шартларын яхшырту өчен бер миллион сум акча биреләчәк. Бу авыл җирлекләренә яшь кадрлар җәлеп итү, алар озакка калсын өчен шәхси торак белән тәэмин итү, укучыларның белем дәрәҗәләрен арттыру, җирле укытучыларны бераз булса да бушату өчен башкарыла. Сер түгел, Татарстанда мәгариф өлкәсендә кадрларга кытлык бар. Билгеле, Татарстан үзәккә генә карап утырмый. 2018 елдан башлап яшь укытучылар ипотека кредитларын түләү өчен 600 мең сум күләмендәге грантка дәгъва итә ала. Торак-коммуналь хезмәтләргә чыгымнарны каплау өчен дә хөкүмәт авыл җирлегендә эшләүче педагогларга субсидия бирә.

Илкүләм алып барылган «Мәгариф» проекты да ярдәм итәчәк, чөнки аның максаты: гомум белем бирү сыйфаты буенча Россия Федерациясен әйдәп баручы ун ил исемлегенә кертү. Ә укытучылар хезмәтеннән башка бу мөмкин эш түгел. Барыбыз да аңлыйбыз, яшәешнең киләчәге, сәяси тотрыклылыгы һәм икътисадый уңышлары балаларыбыз кулында. Ә нигез ташларын мөгаллимнәр сала.



АРЧА МИЧУРИНЧЫЛАРЫ



Лилия
ГӘРӘЕВА

Аралашкан өч-дүрт сәгать эчендә яшелчәчелек буенча тулы бер курс белем алдык без алардан. Сату өчен бәрәңгенең кайсы сорты кулай булуын да, базарга нинди кәбестә алып чыксаң оттырмаячагыңны да, яшелчәләр уңсын өчен җирне ничек эшкәртергә кирәклеген дә, нинди чүп үләне үсүгә карап, нинди ашлама кертәсен дә белдек. Эшен яратып башкарган кеше янында озаграк булсаң, үзеңнең дә күңеленә шул эш якын тоела башлый бит ул. Тракторлар гөрелтесе тынмаган, буразнада йомры бәрәңгеләр тәгәрәшкән, җир астында җиз казыклар, кат-кат тунлы кәбестә, чөгендерләр үскән җиргә – Илсөя ГАТАУЛЛИНАның крестьян-фермерлык хуҗалыгына, хуҗаларның үзләре белән дә, эшләре белән дә танышырга дип килүебез.

Кибеткә керсәк тә, кеше нәрсә ала икән дип карап йөрибез – үзебезгә тәҗрибә туплыйбыз.



Бер пай җиреннән

Арчага терәлеп утырган Айван авылын фермерлар авылы дисәң дә була. Мини-ферма тотучылар гына да дүртәү монда. Илсөя һәм Нафил Гатауллиннар исә авыл хуҗалыгының яшелчәчелек тармагын сайлаган. «Ни өчен шушы өлкә белән кызыксындыгыз? Яшелчә үстерү бик четерекле түгелме?» дигән сорау юлга чыкканнан бирле тел очымда иде. «Эшнең кайсысы җиңел соң? – ди Илсөя. – Сыер асрасаң, көн саен ашатырга, саварга кирәк. Яшелчә басуын берәр көнгә калдырып та китә аласың, терлекне калдырып китеп булмый».

Бер пай җире һәм хезмәт биржасы аша үз эшләрен ачып җибәрү өчен бирелгән 50 мең сум акчадан башлана бөтенесе. Әлеге акчага теплица корып, кыяр утырталар. «Нәрсәсе бар инде, үстермәгән кыяр түгел бит», – дип уйлыйлар һәм... ялгышалар. Иртә-кич утын ягып җылытыла торган теплицада кыярлар шәлперәя дә төшә. Дымы да, җылысы да җитәрлек югыйсә. Сәбәпнең мич якканда чыккан төтендә булуын соңыннан гына беләләр.

Арчадан Айванга күченгәндә үз эшебезне башларбыз, фермер булырбыз, дип ният тә итми әле Гатауллиннар. Нафил колхозда эшли, Илсөя – Арчаның чүәк цехында. Цех ябыла, колхозлар тарала... Кемдер эш эзләп Казанга китә, кемдер Себергә үк юнәлә. Нафил белән Илсөя исә Мари Республикасына юл тота. Юк, эш эзләп тә, бәхет артыннан да түгел, товарга дип килә алар Урман кешеләре иленә (мари – урман кешесе дигәнне аңлата. – *Авт.*)

«Андагы халыкның эшчәнлегенә исең китмәле. 90 яшьлек әбиләр дә бакчасында күп итеп кәбестә, кишер үстерә. Бәрәңгене гектарлап игәләр, – ди Илсөя, уңган күршеләргә сокланып. – Иске «ГАЗель» машинабыз бар иде. Түбәләмә тулганчы бәрәңге төядек, кәбестә, кишер тутырдык. Атна буе авылдан авылга йөреп яшелчә җыябыз да, шимбә-якшәмбе Казанга – базарга китәбез». Ә үзләренең биш гектар җиренә ул елны ашлык чәчәләр. Нигә ашлыкмы? Өч ел эшкәртелмәгән җиргә шунда ук бәрәңге утырта алмыйсың, каты корт аркасында үстергән уңышың сатарлык булмый икән.

Гөрли базар

Базарга чыктың да, алып килгән яшелчәңне җиңел генә саттың түгел әле. Моның шулай икәнен бик тиз аңлый Илсөяләр. «Артык эре дә булмасын, вагы да ярамый, күзләренең дә тирән булмаганы кирәк. Кәбестә белән дә шулай. Безнең мари әбиләреннән җыеп кайткан зур-зур кәбестәләргә бик кызыгучы күренми. Бер пешерерлек кенә тыгыз, вак кәбестә сорыйлар...» Беренче ел базарны өйрәнү елы була. «Базар җиңел генә бирелмәде, – ди Илсөя ханым. – Баштарак мәлләрдә сату авырдан барды».

Моңарчы бәрәңгенең матурлыгына игътибар да итмәгән Гатауллиннар базарда сату өчен аның яңа сортларын эзли. «Элек капчыкка тутыра идең дә, алалар иде: бәрәңгеме – бәрәңге. Хәзер алай түгел. Кеше товарны күз белән сайлый. Җыенысы бер зурлыктагы сап-сары бәрәңгеләрне тиз алып бетерәләр. Товарыңны бер ошатып калсалар, икенче юлы да синнән алырга тырышачаклар, алга таба сынатма гына!» – ди алар. Беренче елларны бәрәңгенең «Жуковский» сортын үстергән булганнар, хәзер «Гала» дигәнен игәләр. «Сез сатып бетерми торып, безнекен алучы булмас», – ди икән базардагы башка сатучылар.



Нәүфәл Гатауллин: «Яшелчәчелек – кызыклы өлкә, ел саен нәрсәдер өйрәнәсең, нәрсәдер үзгәртәсең... Эзләнүчән дә булырга туры килә: яңа сортлар, яңа препаратлар чыгып тора. Үз эшем ошый миңа. Ниятем – шушы җирдә эшләү».



PRESSA

Башка төбәкләрдәге фермерлар безгә кызыгып карый. Бездә мондый дәүләт программалары юк, диләр.

Экологик чисталык һәм сыйфат – менә шул Гатауллиннарның төп максаты. Шуңа да үстергән яшелчәләрен тирә-юньдәге кибетләр дә, рестораннар да бик теләп ала. Барлык яшелчәләренә сыйфат сертификаты бар. Сыйфатның төп контролеры – уллары Нәүфәл.

Яшь агроном

Экономист булам дип йөргән егет, көне килеп җиткәч, Казан дәүләт аграр университетының агрономнар әзерли торган факультетын сайлый. Бюджет урыннары булу гына кызыктырмый аны, алган белемен шунда ук сынап карау мөмкинлеге дә ымсындыра – басулары бакча башында гына лабаса. Нәүфәл белән сөйләшүе рәхәт. Яратып, эшнең төмен белеп сөйли. Хуҗалыкның төп көче, яшь мичуринчысы ул бүген.

Әлегә кадәр шул биш гектар җирдән алган уңышка канәгать булган Гатауллиннар, инде уллары да кайткач, быелдан хуҗалыкны зурайтырга булган. Авылдашларының пай җирләрен сатып алып, басуларын 33 гектарга кадәр киңәйткәннәр. Үзләренең тракторлары, кәбестә утырту агрегаты, кишер чәчкеч, бәрәңге казыгычлары бар. Иң куандырганы – 2016 елны дәүләтнең грант акчасына төзелгән яшелчә склады. 18 метрга 14 метрлы итеп салынган, көчле һава өрдергечләре булган бу яшелчә саклагычка 33 гектарда үстерелгән бәрәңге, кәбестә-кишернең барысы да сыеп бетәргә тиеш. Кызыксынучан Нәүфәл быелдан тагын бер яңалыкны сынамакчы – кәбестәләрне агач контейнерларда саклап карарга тели ул.

Кәбестәнең генә дә тугыз төрле сорты үсә аларда. Безнең гаҗәпсенгәнне күреп, егет шунда ук аңлата: «Бу үзенә күрә стратегик план. Бер сорт уңмаса, икенчесе уңмый калмас. Россиянең атаклы биологы һәм селекционеры Иван Мичурин да: «Табигатьтән рәхимлекләр көтеп тора алмыйбыз», – дигән бит. «Базар таләбен дә истә тотмый булмый, – дип ачыклый Илсөя. – Җәйге якта иртә өлгерешле сусыл, йомшак кәбестәгә сорау зур, аннан, бер пешереп бетерерлек тыгыз, вак башлысын сорыйлар. Көзге якта тозлый торган сортлар әйбәт сатыла. Аларын инде эре булса яхшырак алалар».

Йорт янындагы 10 сутый яшелчә бакчасын чын тәҗрибә участогына әйләндерә яшь агроном. Салатның төрле-төрле сортларын үстереп карый, кишер-чөгендерләр дә басуга чәчелгәнче сынауны башта монда уза. «Нәрсәләр генә үстереп карамадык инде. Кайсыдыр яшелчәне күпләп үстерүгә күчкәнче, башта аз гына күләмдә утыртып, базарга алып чыгып тикшерәбез, – ди Илсөя. – Халык яратып алса гына, икенче елны күбрәк үстерәбез. Кеше үзе белмәгән, ашап карамаган әйберсен бик алмый. Бер елны «Айсберг» салаты утырткан идек. Бик шәп үнды үзе, ләкин сатылмады...»

«Эксибишн» суганы, кызыл яфраклы салат, Пекин кәбестәсе – болар инде яшь агрономның тәҗрибә түтәлләре аша узган яшелчәләр. Пекин кәбестәсеннән сезонга икешәр уңыш алалар. «Ул кыска көн үсемлеге. Аны иртә язда һәм көннәр кыскара башлагач ике тапкыр чәчәбез. Яхшы уңыш алуның үз сере бар – үсемлек стресс кичерергә тиеш түгел. Бу юлы өстен каплап үстерү ысулын сынап карадык, – ди Нәүфәл, уңыш серләрен ача төшеп. – Каплап үстергәне инде өлгереп килә. Корткычлар да куркыныч түгел аңа. Ә ачык һавадагысы инде, мөгаен, өлгермәс тә».

Кәбестә басулары өстендә салават күпере. Дәүләтнең мелиорация программасы буенча алынган су сиптерү җайланмалары басуларны






Фотолар: Анна Арахамия һәм гаилә архивыннан

дымга туендыра. «2010 ел бик коры килгән иде бит. Ул елны басуларга суны кул белән сибеп йөрдек. Беренче мотопомпаны үз акчабызга сатып алган идек. Республиканың авыл хуҗалыгы җирләрен сугару программасына кушылып, тагын бер мотопомпа, барабан алдык», – ди фермерлар.

Язның көне ел туйдыра

Басуларда әле кар ятканда Гатауллиннарда инде эш кайный. Берсе-берсе 144 оялы меңнән артык кассетада кәбестә, суган орлыклары шыта. «Суган орлыгын бер ояга өчне чәчәбез. Күчереп утыртканда да аермыйбыз. Алар түтәлдә өчесе дә иркенәеп үсеп, бер төптән өч эре суган чыга. Уҗымын сатканда, кешеләргә дә шулай утыртырга киңәш итәбез» – Нәүфәлдән тагын бер кечкенә генә сер сезгә. Суганның яхшы сакланышлы «Спэниш Медальон» сортын да орлыктан чәчеп үстерәләр. Шушы нәни генә орлыктан тишелеп чыккан үсенте җәй эчендә йодрык кадәр суган булып җитешә.

Әти-әнисе башлап җибәргән бизнеска Нәүфәлнең дә, кызлары Ильвина белән Әлфинәнең дә булышуы зур терәк, әлбәттә. Ләкин орлыкларны чәчкәндә, уҗымнарны күчереп утыртканда, чүбен утаганда барыбер ярдәмчеләр кирәк. Стандартка ярашлы булсын өчен, бер гектарга, сортына карап, 35–45 мең үсемлек утыртылырга тиеш. «Баштарак авылдан кеше чакырып булмый иде. Хәзер үзләре эш сорап килә», – ди Илсөя. Чәчү, күчереп утырту эшләре беткәч, чүп үләннәре баш калкыта. «Агулы гербицидлар кулланмыйбыз. Без үстергән яшелчәләр өзгән көнне табынга куела торган. Корткычларга каршы контактлы биологик препаратлар сиптерсәк тә, чүпне кул белән утыйбыз. Кешеләргә эшләргә эш урыннары да кирәк бит», – ди алар. Быел җәй басуда югары класс укучылары эшләгән. «Чүп утаганга көненә 500 сумнан түләдек. Бик тырыштылар, акчасын вакытында алгач, үзләренә дә күңелле бит. Эш бик тыгыз чакта төшке ашны да үзебез әзерлибез», – ди Илсөя ханым. Бәрәңге алган вакытларда да басулар гөрләп торган. Кай көнне 15, кай көнне 27 кеше булганнар. Мәктәп укучылары да килеп, бер көндә үзләренә кышка җитәрлек бәрәңге әзерләп киткәннәр. Гатауллиннар хуҗалыгы ел саен Айван урта мәктәбен бәрәңге, кәбестә белән тәэмин итә.

Планнар зурдан

Җир кешесенең эше санап бетергесез. Кайчак ял итү түгел, утырып ашарга җай чыкмаса да, Илсөя һәм Нафил күргәзмә-семинарларда катнашу мөмкинлеген табарга тырыша. «Безгә андый чараларда катнашу кирәк. Кешенең ничек эшләгәнен дә беләсең, үзеңне дә күрсәтәсең», – диләр бит әнә. Бөтенроссия «Кыр көне» күргәзмәсе, «ТатАгроЭкспо» – үзләре үстергән продукция белән таныштыру өчен менә дигән мәйдан фермерларга. Андый мөмкинлекне кулдан ычкындырырга ярамый дип саный алар. «Татарстанда яшелчәчелек алай зур үсеш алган тармак түгел. Күрше Мари Иле, Чуашстан фермерларының тәҗрибәсе зуррак, аларда бик зур семинарлар уза. Ләкин күршеләр безгә карап кызыга. Чөнки Татарстандагы дәүләт программалары бүтән бер җирдә дә юк, – ди Нафил. – Эшне башлаган елларда бездә дә мондый ярдәм юк иде. әле. Баштарак җирне ала алмый изаландык. Булыр, диделәр. Шул сүзгә ышанып, 3 гектарга җитәрлек кәбестә чәчтек. Утыртыр вакыт җиткәч, җирнең булмаячагы ачыкланды. Күпме хезмәт әрәм китте ул елны. Ә хәзер караш башкача. Мә, ал, эшлә генә!»

Табигатьтә көз, ә Гатауллиннар хуҗалыгында инде яңа сезонга – язга әзерлек бара. Басуларның планын нәкъ менә хәзер сызып, җирне көздән әзерләп калдырасы бар. Яшелчә өчен басу төрлечә сөреләэ, ашламалар да төрлечә... Яңа сезонда масштаблар да зуррак булачак – 33 гектар мәйдан яңа хуҗаларын көтә.

Планнары бу гына түгел Илсөяләрнең. Иң зур эшләр әле алда... «Яшелчәне үстерү – ярты эш. Үстергәнне саклый да белергә кирәк», – ди алар. Ниятләре – Айванда яшелчә эшкәртү цехын эшләтеп җибәрү. «Базарда тозлы кәбестә, кыяр, салатларга ихтыяҗ бар. Әгәр без аны булдыра алабыз икән, ник әле тотынмаска», – диләр. Үз көчләренә ышанмасалар, алар бу эшкә алынмаслар да иде.

РЕДАКЦИЯДӘН: октябрь ае Илсөя һәм Нафил Гатауллиннар өчен аеруча кадерле ай. Быел аларның көмеш туйлары. Җирнең тырыш хуҗаларын без дә тәбриклибез. Алда әле ниятләрнең тагын да зурраклары тормышка ашсын!

КҮЗ ЯШЕ КЕБЕК ЧИСТА...



Фото: Анна Арахамия

– Бүген иртән Италиягә посылка салдык. Кичә – Латвиягә, Австралиягә... Мәскәү, Санкт-Петербург, Сочи, Пермь, Екатеринбург, Ижевск... Ул санаган шәһәр һәм ил исемнәрен язарга өлгермим – алар шундый күп! Ә посылкаларда... Аларда – матурлык! Крем, маска, тоник, мицелляр су... Тагын – молекулалар! №1, №2, №5, №15... Казаннан бөтен дөньяга таралган бу косметиканың сере нәрсәдә соң? «RESEDAODOR» компаниясенең генераль директоры, аңа нигез салучы Резеда НУРИСЛАМОВА белән шул хакта сөйләшәбез.



Гөлнур САФИУЛЛИНА

Һәр стресс картаю процессын кузгата. Моңа биткә инъекция ясау да кирә. Барысы да чама белән булырга тиеш.

Резеда, салам күченнән энә эзләгәндәй дөнья буйлап молекула эзләвегез нәрсәдән башланды?

– Үземнең проблемалар булганга тотынганмындыр бу эшкә… Яшь чакта биттә булган акне, ялкынсынуларның эзе калды. Аларга беренче җыерчыклар килеп кушылды… Молекулаларны үзем өчен эзләдем. Матур булам, дип, бертуктамый уколлар ясатып тору, бит тиресен филлер, мезопрепаратлар, җеп һәм токсиннар белән «тутыру» дөрес түгел дип саныйм. Хәзер 25 яшьлек кызларга да: «Профилактика өчен ботулотоксин эшли башлагыз», диләр. Тик, беренчедән, тире моңа бик тиз ияләшә: баштарак эффекты ярты елга сузылса да, соңрак ул бер айга да җитмәячәк. Аннан тенденция – бер нәрсә, ә аның соңыннан килеп чыгачак тәэсире – икенче. Лицензияләре бармы, юкмы, уколны бар да ясый хәзер. Конференцияләргә баргач, медицина юристлары белән аралашырга туры килә. Уколлар кайчак хатын-кызны ямьсезләп кенә калмый, шуның аркасында дөньядан китүчеләр дә бар: 36 яшьлек хатынның гомере шулай өзелде менә, дип сөйләделәр соңгы очрашуда да. Ахырын уйламый эшләү җинаятькә тиң… Ни дисәк тә, нейротоксин – көчле агу, нерв күзәнәкләреннән тыш, аның тагын кая, ничек тәэсир иткәнен без әле белеп бетермибез. Баш миенә дә эләгүе бар. Шуңа күрә аны бик сирәк, җитди проблемадан котылу өчен генә кулланырга кирәк. Ә аннан куркынычсыз юлга кучәргә. Европада мондый матурлык уколларын ясатмыйлар инде. Тирене барыбер алдап булмый.

Мин бит бу өлкәдә ят кеше түгел: моңарчы 10 ел заводта эшләдем. Технологтан сыйфат буенча директорга кадәр күтәрелдем. «Тенториум»ның косметология юнәлешендәге бик күп продуктларын мин җитәкләгән бүлек эшләде. Байтак проектларга патентлар язарга туры килде. Аларның рецептураларын әле дә яттан беләм… Шуңа күрә нәрсә эзләгәнемне чамалый идем. Иң элек гиалурон кислотасы белән репульпами кайтарттым. Лазер белән битемне шомартканнан соң, пигмент таплар белән капланды. Җыерчык басты. Тирем киптергеч кебек иде… Куллана башладым. Баштагы ике елда бизнес хакында бөтенләй уйламадым. Дус кызларым, таныш-белешләр – табиб, фармаколог, провизорлар белеп, ишетеп, күреп: «Азрак бирә алмассыңмы?» – дип сорый башладылар. Ике елдан соң миңа тәзелгән бу чиратның бик озын икәнен аңладым… Чиста килеш гиалурон кислотасы Россиядә беркайда сатылмый. Французлар белән сөйләшүләр алып барырга керештем: «Мин аны шул хәлендә алып кайтырга телим. Су һәм гиалурон кислотасы гына – башка берни булмасын», – дидем. Җиңел юл булмады ул… Әмма мин барысы аша да уздым. Үзебезнең продукцияне бөтен дөньяга озата башлаганга биш елдан артты инде. Минем кебек мондый активларны эзләүчеләр байтак икән.

«RESEDAODOR» эшләп чыгарган косметика чаралары башкалардан нәрсә белән аерыла ул?

– Фармаколог буларак, мин һәрвакыт составка игътибар итәм. Әйтик, сез гиалурон кислотасы кушылган крем сатып алдыгыз ди. Әмма аның кремда күпме икәнен сез берничек белә алмыйсыз. Закон буенча, ул аермачык күрсәтелергә тиеш түгел. Технологларга: «Кремның бәясен төшерергә кирәк», – дигән боерык куела икән, алар иң элек шушы активны киметә. Кайчак хәтта нульгә кадәр. Һәм җитештерүче моңа юридик яктан хаклы. Ә һәр препарат төрле дозада төрлечә тәэсир итә. Әгәр ул терапия дозасыннан кимрәк икән, аңардан инде кешегә файда юк. Бу очракта ул җитештерүчегә этикеткага язар, реклама мәгълүматында файдаланыр өчен генә кирәк.

Сатып алучы күп вакыт нәрсә өчен акча түләгәнен дә белми. Кайчак кибеткә кереп шампуньнәр карап йөрим, ингредиентларын укыйм. Бер мең сумга сатылган шампуньнең үзкыйммәте өч сум торырга мөмкин. Әйе, кабы матур, флаконы да. Димәк, сатып алучы шулар өчен генә түли? Кайбер ингредиентлардан инде бөтен дөньяда баш тарттылар, ә бездә, Россиядә әле һаман саталар. Чөнки алар арзан.

Ә «RESEDAODOR»да – киресенчә. Актив ингредиентларны без, гомумән, чиста хәлендә сатабыз. Гиалурон кислотасы икән, ул бары гиалурон кислотасыннан һәм судан гына тора. Башка берни юк! Күз яше кебек чиста дибез аның турында… Производствода аны технолог куша, ә монда сез үзегез: уч төбенә крем салып, шуңа бер-ике тамчы гиалурон кислотасы тамызасыз, икесен кушасыз һәм кай җирне дымландырырга кирәк – битне, кулны, муенны – шунда ук сөртәсез.

Молекулалар күп, әмма «иң беренче номерлы молекула» дип без гиалурон кислотасын атыйбыз.

Хатын-кыз өчен иң кирәк молекула, димәк, гиалурон кислотасы?

– Яшь барган саен, тиредә гиалурон кислотасы кими. Ә тирене дымландыру өчен ул барыбызга да кирәк. Калган молекулалар исә – күрсәткечләр буенча. Мәсәлән, ботулотоксинга охшаган, үсемлектән ясалган актив бар. Ул мимик җыерчыкларны «йомшарта». Кеше елмая, әмма аның йөзендә тирән «бураэна» инде чыкмый.

Яңа крем куллана башлыйсыз икән, аның тәэсире бер айдан соң гына күренә (күзәнәкләр 28 көн эчендә генә яңара). Ә гиалурон кислотасы ничек тәэсир иткәнен шунда ук тоячаксыз. Башка молекулаларга, әйткәнемчә, озаграк вакыт кирәк.

Клиник тикшеренүләрне өйрәнгәндә мин һәрвакыт аңа ничә яшьтәге хатын-кызлар катнашуга игътибар итәм. Чөнки күп компанияләр тикшерүләрне 35–42 яшьлекләрдә уздыра. Аларның эстроген дәрәҗәсе югары, шуңа күрә нинди дә булса нәтиҗәгә ирешү дә бик җиңел. Ә инде компания 56–64 яшьлекләр белән дә

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

Күп молекулаларыбызда хәләл сертификаты да тора. Клиентларыбыз арасында беренче таләп итеп моны куючылар күп.

эшли һәм менопауза вакыты җиткән, эстрогеннар дәрәҗәсе төшкән, кризис яшендәге хатын-кызларда ниндидер үзгәрешкә ирешә икән – бу күп нәрсә турында сөйли. Димәк, әлеге крем барысына да килешәчәк: яшьләргә дә, өлкәннәргә дә.

Молекулалар белән тестларны без дә еллар буе үткәрәбез. Ай саен яңа продукт чыкмый бездә. (Хатын-кызлар кулланып карады да, аларга ошады дип кенә яңа продукт чыгара алмыйбыз. Монда хатын-кыз объектив була алмый. Кемдер мактап җибәрсә, аңа, чыннан да, җыерчыклары беткән кебек тоелырга мөмкин. Безнең өчен иң мөһиме – тестлар күрсәткән нәтиҗә.) Һәр яңа продуктны башта... минем әни кулланып карый. Аңа инде 80 яшь. Ничәнче дистәне ваклавын белгәч, шунда ук: «Ә битегезне нишләтәсез, нәрсә кулланасыз?» – дип сорыйлар аннан. Әни аларны безгә җибәрә... Яңа продуктларны иң беренче кулланучылар исемлегендә үзем һәм минем кул астымда эшләгән кызлар да бар.

Бит тиресе бик сизгер булып, аллергия белән интегүче хатын-кызлар күп. Без – андыйлар өчен табыш Әйтик, крем 36 исемдәге ингредиенттан тора. Һәм аларның теләсә кайсысы аллергия китереп чыгарырга мөмкин. Шуңа да андый хатын-кызга косметика сайлау бик авыр. Ә бездә ул һәр молекуланы аерым алып карый: туры килә икән, шунысын сайлый, юк икән, икенчесенә туктала. Чиста молекула белән эшләү шуңа да җиңел.

Кремнарга ароматизатор да, буяу да кушмыйбыз. Ароматизатор белән бөтен нәрсәне дә яшерергә була: кремның исе никадәр көчле булса, аның составы шулкадәр начар дигән сүз. Димәк, технологларга нәрсәнедер пәрдә артында калдырырга кирәк булган... Әгәр компания продуктны болардан башка чыгарырга әзер икән, димәк, аның һәр ингредиенты уйланылган дигән сүз. Шуңа күрә безнең технологларга бик авыр бурыч куелды... Кибет киштәсендәге продукт төсе белән артык күзгә бәрелеп тора икән, составы белән кызыксынырга онытмагыз. Табигый экстрактлар беркайчан артык җете төстә булмый.

Без бүгенге көндә косметологиядә иң әйбәт дип саналган активларны гына кулланабыз. Мин актив артыннан барган заводлардан молекулаларны бөтен дөньяга билгеле брендлар да сатып ала: Armani, Dior, Chanel, Clinigue... Үткән баруымда, мәсәлән, минем белән янәшә чиста хәлдәге молекулаларны La Prairie вәкиле дә алды. Беләсез инде, атаклы Швейцария компаниясе бу. Бренд! Аларда кремнең бер банкасы 40–50 мең тора. Икебездә дә шул ук бер молекула! Аерма шунда: аларда ул крем составында, ә бездә – чиста хәлдә.

Косметика сайлаганда безнең иң зур ялгышыбыз нәрсәдә?

– Чистарта торган продуктлар, ягъни нәрсә күбекләнә, тән тиресенә шуның белән зыян салырга мөмкин. «Пенка», мицелляр су, гель, шампуньнәр... Гомумән, һәр күбекләнгән әйбернең составын карап алырга кирәк. Иң агрессив компонент – лаурилсульфат натрие – ул булмасын. Җитештерүчеләр аны ни өчен куллана дисезме? Әйе, бәясе бик арзан торганга һәм яхшы күбекләнгәнгә. Ә халык, кызганыч, күбекләнүне әйбәт күрсәткеч дип белә... Лаурилсульфат натрие бит тиресенә җитди зыян сала: эпидермисны боза, гидролипид катлауны юып төшерә. Икенчедән, кирәгеннән артык эчкә үтеп керә. Алай гына да түгел, калган ингредиентларны да үзе белән канга кадәр алып керергә мөмкин.

Теләсә нинди косметика, әйтик крем, 85–90 процент судан тора. Ә актив ингредиентлары – 1–2 процент кына. Әмма күп компанияләр шушы терапия дозасын да салып җиткерми. Шуның өчен дә, мәсәлән, гиалурон кислотасы кушылган кремның бәясе 30 сумнан 3 меңгә кадәр тора ала: барысы да концентрациягә һәм компонентларга бәйләнгән. Шул ук гиалурон кислотасын Кытайда да, Франциядә дә җитештерәләр. Беренчесе әтәч кикригеннән ясала, ә аңарда зыянлы матдәләр күп, шуңа да ул аллергия китереп чыгарырга, битне кызартырга, чеметтерергә мөмкин. Ә Франциядә эшләнгәне биотехнологик синтезлау юлы белән табыла. Монысы – иң чистасы.

«RESEDAODOR» компаниясе ничә исемдәге продукция тәкъдим итә хәзер?

– Иллегә якын... Тиздән шампунь, бальзам, чәч өчен спрей чыгарга тиеш. Безнең таләпләр буенча, Франциядә тагын ике төрле маска эшләнә. «Дөрес продуктлар» дибез алар турында: күбекләнә, әмма агрессив компонентлары юк. Без аларны бик озак эзләдек, шактый тестлар үткәрдек. Ниһаять, таптык. Компонентлары – төрле илләрдән. Россиянең үзендә субстанцияләр юк диярлек. Советлар Союзы таралганнан соң, бу өлкәдә инде берни дә эшләп чыгарылмый. Бездә ниндидер косметика җитештерелә икән, аның өчен чималны Европадан алалар. Яки Кытайдан, Кореядан... Без әлегә су чистартырга гына өйрәндек. Дөрес, майлы экстрактлар эшлибез. Аның исе бар, төсе бар – шуның белән шул. Тик фармакологлар өчен бу гына аз... Әзер экстрактка анализ ясалырга тиеш: ул ни дәрәҗәдә файдалы, тәэсир итүче матдәләре күпме... Без боларның берсен дә белмибез, чөнки Россиядә бу анализны ясаучы җиһазлар юк. Ат каштаны дигән экстрактны без дә файдаланабыз, әмма ул эсцин дигән матдәгә стандартлаштырылган. Бер миллиграммда эсцинның күпме икәнен, хатын-кызның аяк тамырларында тонусны күтәрү өчен аяк кремында аның никадәр булырга тиешлеген без тәгаен беләбез. Белмәгән очракта безгә нәрсәгә ул?

Активлар безгә дә Европадан – Италиядән, Франциядән килә. Алар активларны җитештерә, әмма үзләрендә мондый хәлдә, ягъни чиста килеш сатмый. Клиентка аны субстанция килеш илтеп җиткерү – безнең идея. Парижга бер баруымда Lorealнең технологы белән очраштык. Кич белән ул бер дус кызына кунакка китте. Төнлә миңа телефоннан фото җибәрде. «Карале, аның ваннасында синең кремнарың тора!» – дип язган...

Безнең кремнарның үзкыйммәте бик югары, шуңа да алар берничек арзан була алмый. Әмма безгә сатып алучы нәтиҗә өчен түли. Әгәр хатын-кыз иртә-кич ике тамчы «RESEDAODOR» молекулаларын куллана икән, димәк, ул үзенә тиешле терапия дозасын ала дигән сүз.

Резеда, сез косметология белән бәйле халыкара конференцияләрдә даими катнашасыз. Димәк, бу өлкәдәге соңгы яңалыкларның барысыннан да хәбәрдарсыз.

– Хатын-кыз үзенең тышкы матурлыгына бик зур игътибар бирә хәзер. Бу мәсьәләдә Россиядә стандартлар шактый югары, Европада инде алай түгел. Әйе, конференцияләргә, күргәзмәләргә еш йөрергә туры килә. Әмма җитештерүчеләр арасында битенә инъекция ясаткан хатын-кызны, гомумән, күргәнем, очратканым юк.

Сүз уңаеннан: косметология буенча иң көчле ил – Франция. Заводларда йөргәндә дә күренә ул. Бер продукт әзер булып сатуга чыкканчы, бер кочак документ җыела. Таләпләр югары! Парижда узучы In-cosmetics Global дигән халыкара конференциягә дә ел саен йөрим. Быел да бардым. Һәр җитештерүче белән тагын сөйләшеп, аралашып чыктым. Конференциядә яңгыраган соңгы тренд ошады миңа. Slow age дип атала ул. Әкренләп картаю, ягъни мәсәлән. Ниһаять, җитештерүчеләр, картаю – физиологик процесс, дигән сүзне әйтә башлады. Әйе, картаюны туктату мөмкин түгел. Алдатырсың Ходайны... Моны кабул итәргә һәм шуның белән яшәргә кирәк. Мин бу сүзләрне биш ел элек сөйләгән идем. «Нигә хафага бирелергә? Нигә моны туктату өчен миллионнар түгәргә?» – дип. Гомеренең һәр чорында хатын-кыз үзенчә матур. Әйе, тирене карарга, тукландырырга кирәк. Әмма картаю процессын туктатып булмый, аны әкренәйтергә генә мөмкин.

Тагын нинди кремнар уйлап чыгарырга хыялланамсы? Темалар бик күп... Витаминнар һәм БАД чыгарасы иде – Яңа Зеландия университеты белән шуның өстендә эшлибез. Нәрсә ишетергә теләгәнегезне аңладым. Әмма яшьлек эликсиры юк дип уйлыйм...

Резеда Нурисламова киңәшләре



■ Әгәр актив ингредиентлар гына язылып, тулы состав күрсәтелмәсә, кремны шундук читкә этеп куярга мөмкин. Бу – законны бозу: кремга нәрсә кушылган – сатып алучы барысын күрергә тиеш.

■ Кремның составы күбрәк ингредиенттан азрагына таба языла. Әгәр гиалурон кислотасы иң азакта, буяулар белән янәшә тора икән, бу кремны да алмасагыз була. Димәк, бу кремда ул бөтенләй юк диярлек.

■ Составында вазелин мае бар икән, бу кремны чүп чиләгенә ташлагыз. Вазелин – нефть продукты, ул машина тәгәрмәченә сыларга гына ярый.

■ Елена Малышева еш кына телевизордан: «Аяк кремын биткә дә сөртергә ярый», – дип сөйли. Ярамый! Компонентлар төрле аларда, хәтта бер үк компонент булганда да, ул төрле дозада төрле эффект бирә.

■ Актив матдәләрне укол гына илтеп җиткерә ала диләр косметологлар кайчакта. Моның алай түгеллеге күптән расланды инде. Бу – нибары маркетинг алымы гына.

■ Тире – үзенә кирәк бар нәрсәне дә үзе эшләп чыгара. Шулай ук, дымландыруны да. Тик без бит аларны гел юып төшерәбез. Һәм кабат кире кайтару өчен берни эшләмибез. Битне дөрес юарга гына кирәк.

■ Мицелляр су кулланасыз икән, соңыннан битне юарга кирәк. Күбекләнүче барлык продуктлар кебек үк, аңарда да селте бар. Әгәр ул югары икән, тиренең балансы бозыла. Нәрсә генә кулланса-гыз да, күбекләнүче продукттан соң, тирене нормага китерү өчен тоник сөртергә кирәк. Тоникның спиртсызын һәм буяусызын сайлагыз. Иң мөһиме – составында сөт кислотасы булсын. Ул – безнең тирегә иң якын кислота. Тониктан соң битне тукландырасыз, дымландырасыз.

■ Битне бары тик проблема булганда гына «чистартырга» кирәк. Һәм моны бары тик көзен һәм кышын гына эшләргә ярый. Җәй көне өйдә дә пилингның бары тик «йомшагын», җиңелен генә кулланыгыз. Чөнки һәртөрле кислота пигмент таплар китереп чыгарырга мөмкин.



Ярты миллионлы тираж белән бөтен СССРга таралучы журнал тышында сурәтләре басылып чыкканнан соң тормышларында нинди үзгәрешләр булды икән аларның? Бу проект шул хакта да... Татарстан тарихында аларның – ул чорда «Азат хатын», бүген инде «Сөембикә» булып басылучы журналыбыз геройларының да салган эзләре бар. Еллар сарысы сеңгән фотолардан елмаючы ул сөйкемле хатын-кызлар – республикабыз кичкән юлларның тере шаһитлары.

ҮЗ ҖИРЕНЕҢ ҮЗ ГӨЛЕ
































Фото: Анна Арахамия

**Галия Зарипова:
Үземне журналның тышлыгында күргәч, горурлык һәм шатлык хисләре биләп алды. Баштарак аңлап та бетермәгәнмендер әле, ә менә үз сурәтемне күргәч кенә хезмәтеңә күрә хөрмәтнең никадәр сөенечле хәл икәнлегенә төшендем. Гомерем буе хезмәттән, тормыштан тәм табып яшәдем.**

1966 ел. 19 яшьлек Галиягә тиз арада идарәгә килеп җитәргә кушалар. Казаннан корреспондентлар килгән икән. «Азат хатын» журналына фотога төшерергә телиләр икән уңган кызны. «Китегезче, – ди кыз. – Миннән алдынгыраклар да бар ич», – ди. Тик озак икеләнеп-нитеп торырга урын калдырмыйлар аңа: совхоз директоры үзенең кошовкасын җибәрә. Бөтен республикага даны таралган миллионер «Гигант» совхозының атаклы директоры Зыя Закировның сүзен аяк астына салып була димени инде?! Менә шулай итеп Әҗмәкәй авылы китапханәчесе Галия журналның 1966 елгы декабрь саны тышлыгына эләгә. Әлеге сан хәзер дә Галия Нурулла кызының фотоальбомында кадерле ядкарь булып саклана.

Әйе, дәрт-дәрман ташып торган чаклар. Китапханәчеләр авыл тормышының үзәгендә кайнаган заман: агитбригада белән дә йөри Галия, иптәшләр судында секретарь да, бәйрәмнәрдә биюче дә. «Фермадан кайтып та кермәдек инде, – дип искә ала һаман да шундый ук мөлаем йөзле Галия апа. – Берәр җитәкчеме, кунакмы совхозга киләсе булса, таң белән үк торып фермага йөгерә идек. «Бездә хезмәт – дан эше, бездә хезмәт – вөҗдан эше»ңне язып элмәгәнсең бит, диләр иде», – дип елмая ул. Плакатларны күп язса да, менә монысын бигрәк тә онытмый. Бәлки, үзе дә хезмәтен «кызыл» сүз өчен дип түгел, күңел биреп, намус белән башкаргангадыр. Совхоз стена газетасының редакторы да, рәссамы да була. Хәтта эшкә кызмача килгән иренең карикатурасын ясарга да туры килә үзенә. Нишлисең бит, яшереп калып булмый, партком биргән исемлектәге кешеләрне күрсәтәсе бар. Үзенә бирелгән Мактау грамоталарыннан кисеп алган «Ленин башлары» да газета чыгарырга китә: әйбәтрәк, үтемлерәк итеп эшлисе килгәннән инде монысы.

Ә 1977 елда Галия Зарипова гаиләсе белән Тукай районының (ул чагында Чаллы) «Новый» (Яңа) бистәсенә күченә (төрле авылларда, ләкин гомере буе үз ягында яши Иштирәк кызы Галия). Бирелә китапханәдә озак эшләми, баласы белән декрет ялына киткәннән соң, янәдән яраткан һөнәренә кайтырга туры килми аңа.

Китаплардан бүгенге көндә дә аерылмый Галия апа. Аңардан күбрәк китап укучы да юк, диләр. Элеккечә детективлар ярата ул: Агата Кристиның китапларын кат-кат укый, Шамил Шәйдуллин белән Мәгъсүм Насыйбуллин әсәрләрен ярата. Китапханәгә кайткан бер генә яңа китапны да күз уңыннан ычкындырмый. Әлегә кадәр хезмәттә булган Галия апа инде соңгы аен эшли икән. Тынгысыз күңеле, мөгаен, тагын үзенә яңа шөгыльләр эзләр. Ә әлегә ике бала анасы, инде туруны өчен әбекәй ул; «Нур» ветераннар клубына йөри. Күптән түгел генә Илһам Шакировның туган авылында фестивальдә катнашып кайтканнар. Хәзер дә бер генә бәйрәм дә Галия апа Зарипова катнашыннан башка узмый. Хәзер дә бии әле ул! Паспортта җитмеш ике булса да, йөрәк унсигездә ич. Менә дигән аш-су остасы булуын да беләләр бирелә. Кунак-төшем булса, аның тәмле коймакларын, гөбәдияләрен авыз итми китмиләр.

Лилия ФӘТТАХОВА






СӨТ ЭШКӘРТҮ





Авылны яшәтүче ул!



Мәдинә
АВЗАЛОВА

Эшне «мөгез»еннән эләктерә белгәнгә гел уң килеп торадыр. Мисал эзләп, ерак китәсе түгел. Әнә ул – Аш-Буҗи эшмәкәре, каршыбызда гына...

Аның турында ишетеп белә идек инде. Кукмара районының атаклы эшмәкәре (ай-һай, районның гына микән?.. Андыйлар республикада да бармак белән генә санарлык!) Фәнис Хәмәтдинов турында хакимият башлыгы урынбасары Равия Кәримуллина: «Табыш ул безнең өчен!..» – дип сөйләгәндә, җитәкче әйткән сүзләрнең мәгънәсенә төшенеп җитмәгәнбез икән әле. Аннан эшмәкәрнең үзен күрдек, эшләгән эшләре белән таныштык та, үзебез дә шундый нәтиҗәгә килдек: «Әйе, табыш!»

Фәнис Фәләхетдин улы Хәмәтдинов – тумышы белән Аш-Буҗи авылыннан. 200 хуҗалыклы авыл ул. Бер караганда, аерып күрсәтерлеге дә юк сыман. Бер караганда гына... Тикмәгә генә эшмәкәр, эзе тарихта калсын дип, үз акчасына туган авылы турында китап яздырмагандыр. Тикмәгә генә күренекле якташларының исеме буыннан-буынга күчсен дип тырышмагандыр. Табигате дә нинди бит әнә. Риваятьләргә кереп калган «Дәрә тау» үзе генә дә ни тора! «Кыйбла чишмәсе», «Салкын чишмә», «Самавырлы чишмә», «Вәли тавы», «Миңкәй елгасы»... Исемнәрен онытам дисәң дә оныта алмыйсың. Аңа – Фәнис Фәләхетдин улына – әнә шул матурлыкны, җанга кадерле булган әнә шул истәлекләрне сакларга, «картая» барган авылын яшәртү, яшәтү бурычы йөкләнгән. Юк, берәү дә йөкләмәгән аңа бу эшне. Ул аны җилкәсенә үзе теләп салган. Мин эшләмәсәм, кем эшләр, мин булдырмасам, кем булдырыр дигән.

Аш-Буҗи, Зур Сәрдек, Купка, Чишмәбаш, Кара Елга һәм Адай авылы кергән бу як җирләр элек «Коммунизмга» колхозына берләшкән була. Район халкына үрнәк булып, заманында ничек эшләргә, ничек яшәргә кирәклеген күрсәткән хуҗалык хәзер башка төсмер алды. Башка исем, башка эчтәлек алды диюем. Хәер, хикмәт исемдәмени?! Кешеләрендә! Нинди генә авыр хәлдә дә «югалып калмады дип әйтсеннәр», дип торучы Хәмәтдинов шикелле җанатарлар булганда, кечкенә генә авыл да меңләгән халыкны азык-төлек белән тәэмин итеп торучы зур үзәккә – көчле җитештерү үзәгенә әверелә ала икән. Без моны, эшмәкәрнең көлне чәчәк иткән белемәләрендә тукталыш ясый-ясый, үз күзләребез белән күреп, шуңа инанып кайттык.

Беренче тукталыш: Сөт продуктлары эшкәртү комбинаты

Дөресрәге, җаваплылыгы чикләнгән «Кукмара сөте» ширкәте дип атала. Ни өчен «Кукмара сөте» дип аталуын соңыннан аңладык. Бүгенге көндә ул районда тугыз төр сөт продукциясе җитештерүче бердәнбер комбинат булып чыкты.

– Кайчандыр гөрләп эшләп яткан Кукмара сөт комбинаты ябылгач, шушында – Купка авылында 2018 елны сөт эшкәртү комбинаты ачып җибәрдек, – ди Фәнис Хәмәтдинов үткәннәргә кайтып. – Халыктан көн саен 15 тонна сөт җыябыз. Көненә өч тонна сөт эшкәртелә. Алга таба 12 төр продукция җитештерүне күз алдында тотабыз.

Саннарга күчереп әйткәндә, менә шулай – кыска һәм төгәл. Ә ул саннар артында күпме хезмәт, күпме көч ятканын эшмәкәр үзе генә белә. Комбинат буйлап йөргәндә, ак халатлы кызларның сөт әйләнеп торган зур савытлар янында бертуктаусыз эшләвен күзәтеп торганда моны без дә бик яхшы аңладык. Сыйфатлы продукция җитештерү, кибеткә озатканыңны күз ачып йомганчы сатып бетерү өчен зур тырышлык сорала шул. Бу комбинат сөте белән кинәнгән Балтач, Арча, Мамадыш, Питрәч, Теләче, Малмыж (Киров өлкәсе) районнары халкының күңеле тыныч булырга тиеш: алар сыйфатлы, тәмле сөт эчә. Башка төр сөт продукцияләре дә тел-теш тидерерлек түгел. Карагыз инде, әнә ни дип тора бит комбинат рәисе Фәнис Фәләхетдинович! Баксаң, биредә «ак елга»ны әнә күзе аша үткәрүче өч фильтр эшли икән.

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

Фото: Анна Арахамия

Икмәк пешерүдән башланган эшнең көннән-көн колач җәя баруына авыл халкы да сөенеп бетә алмый. Ашлы һәм эшле бит алар хәзер.

«Киров өлкәсеннән дә алып кайтабыз сөтне, – дип сөйли эшмәкәр. – Анда безнең ике фермерыбыз бар. Шуларның хуҗалыкларына фильтрларны үзебез сатып алып куйдырдык. Сөт чиста кайтсын, дибез». Менә бит ничек! Шуңа да ул: «Җитештереп өлгерә алмыйбыз, киңәергә исәп», – дип тора. Көн саен комбинат капкасыннан биш машина 250 кибеткә юл ала. Күптән түгел генә йогурт әзерләү өчен җиһаз алып кайтып куйганнар. Эшли белсәң, эшне оештыра белсәң, кечкенә генә бинада да әллә ниләр майтарырга була икән...

Икенче тукталыш: пекарня

– Бәлкем, гараж итәрмен дип, өй янына бер бина салып куйган идем. Зур Сәрдектәге пекарняга газ кертеп йөргәндә башыма уй төште. Бина бар, нигә миңа үз эшемне ачмаска дим. Шулай иттем дә. Кирәкле җиһазлар кайтарттым да, бер авылдашым белән ипи пешерә башладык. Көненә йөзәр ипи пешерүдән башлаган эшебез уңай килеп чыкты. Сигез ел шул кечкенә генә бинада пешердек әле. Үзе кысрык, үзе эссе, үзе тәбәнәк... Аннары, 2011 елны, Адайда кибет белән райпо биләмәсен сатып алдым. Шунда яңа пекарня салдык. 2013 елның декабрендә мичтән беренче ипи чыкты...

Әйе, ул тукталып кала торган кеше түгел. Һәр башлаган эшенең уңай килеп торуын кара син! Авылдашларының терәгенә әйләнә барган эшмәкәр 2018 елның июль аенда тагын бер яңалыгы белән хәйран итә: туган авылы Аш-Бужида 850 квадрат метр мәйданда «Камыр ризыклары җитештерү йорты» ачып җибәрә. Яңа җиһаз, камил технологияле ул йортта хәзер 25 кеше эшли. Безне анда Фәнис Фәләхетдиновичның кече улы Фәнүс каршы алды. Фәнүс – азык-төлек җитештерү буенча югары белемле технолог. Аның бурычы – ике пекарняны да өзлексез эшләтү һәм сыйфатлы продукция җитештерү. Өзлексез дигәннән... Эшләр биредә өч сменада, чыннан да, берөзлексез! «Каян өйрәндегез бу кадәрле тәмле итеп пешерергә?» – дигән соравыбызга ул: «Камилләшәбез. Безнең пешекчеләребез бик оста. Ара-тирә Казаннан мастерлар чакыртабыз. Алар да өйрәтеп китә», – дип җаваплый. Әйе, мондый эштә бер урында таптансаң, булганыңны бер мизгелдә юкка чыгарып ташларга да була. Ә бу Хәмәтдиновларның планына керми. Гомумән, алар артка чигенергә күнекмәгән.

Башта Аш-Бужида башлангыч белем алган, аннан соң Зур Сәрдек мәктәбендә урта мәктәпне тәмамлаган Фәнисне әти-әнисе шулай өйрәткән. «Артыңа әйләнеп карама. Масайма, саран булма, гадел бул. Кешеләргә игелекле бул!» Шигарь булып яңгыраган бу сүзләрне Фәнис һич онытмый. Бүген ул үзе инде дәвамчылары булган уллары Илгиз белән Фәнүскә кабатлый. Улларын гадел булырга, игелекле булырга өйрәтә. «Кылган игелегең үзеңә икеләтә әйләнеп кайта. Эшемнең уң баруын шуннан күрәм», – дип торган әтиләре белән егетләр килешә. Башкача була да алмый, алар шулай тәрбияләнгән.

Аш-Бужидан биш чакрым арада урнашкан Зур Сәрдек мәктәбенә җәйләрен чаба-йөгерә, кышларын чаңгыда барулары эзсез узмый – биатлон буенча спорт мастерлыгына кандидат булу бәхетенә ирешкән Фәнис. Мәктәпне тәмамлагач, әтисе аны сыйныфташы белән бергә мотоциклга утыртып, авылдан 35 чакрымда урнашкан Савали (Малмыж районы) авыл хуҗалыгы техникумына илтә. «Монда синең кебекләр күп икән», – ди дә, малайны калдырып кайтып китә. Фәнисне, укырга кергән елны ук армиягә алып, Үзбәкстанга җибәрәләр. Хезмәт итеп кайткач, янә укуын дәвам иттерә. Шаулап торган «Коммунизмга» колхозына кайтканда 1985 нче еллар була. Хезмәт юлы агроном-агрохимик вазыйфаларын үтәүдән башланып киткән егеткә заманында профсоюз җитәкчесе булып та, авыл советы рәисе булып та эшләргә туры килә. Булдыклы егеткә кырын караучы, эшенә аяк чалучылар да булмаган түгел. Әмма егет бирешә торганнардан булып чыкмый. Үзенең нәрсәгә сәләтле икәнен ул көндәлек, әзлекле, иҗади һәм тырыш хезмәте белән исбатлый. Шуларның нәтиҗәсе безнең дә күз алдында.

Өченче тукталыш: Төзелеп яткан ферма

Моннан унике еллар чамасы элек биредә дуңгыз фермасы булган. Элек шулай иде бит – һәр хуҗалыкта диярлек дуңгыз үстерәләр иде. Вакыт узуга күпләрнеке шикелле бу ферма да таркалган. Караучысыз калган корылмалар әкренләп җимерелә, бетә-кырыла башлагач, җитәкче булып килгәннән соң, районны ныклап күтәрүгә-торгызуга алынган хакимият башлыгы Сергей Димитриев көннәрдән бер көнне эшмәкәргә болай ди: «Әрәм яткан ул җирләрне алмыйсыңмы үз кулыңа? Тотынсаң, булдырасың син».

Эшмәкәр озак уйлап тормый, ризалыгын бирә. Кул сузымында гына яткан ул җирләрне файдалы эшкә җигәчәгенә иманы камил аның.

– Монда күркә фермасы булачак, – ди ул якын киләчәктә тормышка ашачак хыялларына бирелеп. – Ыслау цехы да ачарбыз, күркә итеннән колбаса да җитештерербез.

Әлегә биредә эш кайный. Төзүчеләрнең кайсы корылма эчендә, кайсы тышта... Димәк, бик тиздән ул эшли дә башлар. Ә бу исә янә өстәмә эш урыннары дигән сүз. «Сөт продуктлары җитештерү комбинатын-

да, пекарняда, «Камыр ризыклары пешерү йортында», кибеттә эшләүчеләрне кушып исәпләгәндә барысы 115 кеше эшли», – дип горурланып сөйләгән Хәмәтдиновка авыл кешесен эшле итү үзе зур бәхет. Хәтта тормыш мәгънәсе дип әйтер идем. Без барында да аңа эш сорап шалтыратучылар булгалады. «Юк, – димәде. – Булгач, үзем хәбәр итәрмен», – диде. Һичшиксез хәбәр итәчәк. Минем моңа иманым камил.

– Акча каян җиткерәсез? – дибез, колач җитмәс эшләрне күз алдыннан кичерә башлап.

– Сигез миллион грант оттык, – ди ул. – Хөкүмәтебез эшмәкәрләргә ярдәм итеп тора. Процентсыз кредитлар да алгаладык. Шунсыз булмый.

Керем турында сорый башлауга ул: «Күп керә», – дип кенә куя. Керем ул шундый нәрсә: ничек эшлисең, шулай керә. Ә алар әнә алны да, ялны да белми эшли. Эштән төн уртасында да, таң атканда да кайтырга мөмкин ул. Чөнки эшләре, әйткәнемчә, өч сменада бара.

Соңгы тукталыш: «Фәләхетдин» кибете

Хәмәтдиновларның биш кибете бар. Шуларның икесе Нократ Аланында урнашкан. Безнең алдан җилдереп кенә барган җиңел машина диварына «Фәләхетдин» дип язылган кибет янына туктый.

– Бу кибет әти исемен йөртә, – дип дәвам итә сүзен Фәнис Фәләхетдинович. – Алар әни белән шушы кибеттә 40 елдан артык сату иттеләр.

Әлеге сәүдә үзәгенең хуҗасы – Хәмәтдиновларның олы уллары Илгиз. Ул да Казан химия-технология университетын тәмамлаган. Белгечлеге буенча инженер-теплотехник әкренләп әтисе кул астында уңышлы эшмәкәргә әверелгән. Гаиләсе белән Казанда да яшәп караган ул. Ләкин шәһәр тормышы аның өчен түгел. Күрәсең, анда – әти-әнисе, әби-бабасы каны. Хәзерге көндә Илгиз хатыны Лэйсэн белән ике малай үстерә. Без алар белән дә танышып чыктык. Болын кадәрле зур өйнең идәнендә тәгәрәшеп уйнаган малайлар кунаклар белән олыларча – кул биреп исәнләшә. «Мин Самир булам», – ди олырагы. «Ә мин Әмиршан», – дип кабатлый абыйсының сүзләрен нәни малай. «Әмирхан исемле ул, – дип төзәтә оныгын дәү әнисе – Фәнис Фәләхетдиновичның җәмәгате Гөлфия ханым. – Хәрефләрне бераз буташтыра».

– Монысы күркә директоры була инде, – ди Фәнис Фәләхетдинович дәү әтисе яныннан китмәгән бәләкәчне башыннан сыйпап. Безнең көлеп җибәрүебезне малай үзенчә аңлап, җәлт кенә икенче бүлмәгә шыла.

Әңгәмәбезгә кушылып киткән Гөлфия ханым азга гына үткәнгә кайтып, мәктәп елларын, педагогика училищесында укыган чакларны, Фәнисе белән бергәләшеп гаилә корып җибәргән мизгелләрне күз алдыннан кичереп, тыйнак кына сөйләп ала. Ул да шушы авылдан – Аш-Буҗидан. Белгечлек алып кайтканнан соң, башлангыч мәктәптә 25 ел балалар укыткан. Бүген дә эшсез тормый. Гаилә бизнесы икән, гаилә бизнесы! Фәнис Фәләхетдинович әйтмешли, бөтен финанс эшләре аның кулында. Акча хатын-кыз кулында була инде ул. Шулай булганда гына бәрәкәтле. Эшмәкәр минем белән килешә. Хатынына үзенә ышанган шикелле ышана, аннан башка бер көн дә тора алмас кебек! «Өйдә булмасам, әниегез кая китте, дип эзләп йөри ул мине», – дип елмая Гөлфия ханым. Ире, балалары, килене турында яратып сөйли.

Киленнәре Лэйсэн дә Хәмәтдиновлар төзегән нәни «империя»нең бер кисәге. Ул ире Илгиз белән биш кибетне товарлар белән тәэмин итеп торучы да, сатуалу проблемаларын хәл итүче дә. Банк эшләре буенча белем алган Лэйсэнгә боларның берсе дә кыен түгел. Бу эшләрдә ул күлдәге балык сыман. Дөрес, хәзергә ул әле декрет ялында. Шуңа да карамастан, бу мәшәкатьләрдән бер дә ерак китмәгән – барысыннан хәбәрдар.

Иганәчелек турында

Сүз үзеннән-үзе шуңа барып тоташа. Җаны белән авылга береккән Фәнис Хәмәтдинов өчен туган авылының сазлыкка баткан җирләрен гөл итү дә, мохтаҗ булганнарга матди ярдәм күрсәтү дә, кирәксенгәнен санаторийларга җибәрү дә табигый, шулай булырга тиеш дип кабул ителгән гамәлләр. Бу хакта сөйләргә яратмый. «Игелек кыл да күлгә сал, халык белмәсә, балык белер», ди бит мәкаль дә. Безгә дә ул сораштыра, кызыксына башлагач кына, дәшми калуны яхшысынмыйча сөйләде.

Эшмәкәр ел саен Сабантуйда биш авылга биш тәкә бирә икән. Һәр бәйрәмдә бүләкләр өләшү, табын янына чакырып сыйлаулар турында әйтеп тә торасы юк. Хәтта эшчеләренең салымына кадәр үзе түли! Монысына аеруча гаҗәпләндек. Бер уйласаң, аның кул астында эшләүчеләр хезмәт хакын начар алмый. Ә ул менә аларга «пожизненный» бүләк ясаган. Сыер сатып алырга теләүче авылдашларына да бик теләп булыша. Ни дисәң дә, сөт җыючыларга файда гына бит. Гел алга карап, киләчәк турында уйлап эш иткәнгә, әтисе Фәләхетдин абзый өйрәткәнчә, саран булмаганга эш бара. Фәнис Фәләхетдинович моңа үзе дә хәйран: «Берәр игелекле эш кылсам, икеләтә кайта. Гомер буе шулай булды», – ди ул.

...Шулай да аны борчыган нәрсәләр дә юк түгел.

– Кичләрен авыл урамнары буйлап йөрергә яратам, – ди ул. – Авылда буш өйләр бар. Шунысы күңелне тырный. Әгәр дә яшьләргә эш урыннары булдырсак, алар беркая китмәс иде. Һавасы да, кешеләре икенче бит монда...

Әйе, һавасы икенче, кешеләре, җитәкчесе... Башка дөнья, башка тормыш кагыйдәләре... Авылны яшәтүгә юнәлтелгән ул кагыйдәләр шәхси эшмәкәрлектә ирешкән казанышлары өчен «Ел эшмәкәре» исеменә лаек булган һәм хәтта ки Россиянең Мактау китабына кертелгән Фәнис Фәләхетдин улы Хәмәтдинов өчен инде күптән яшәү мәгънәсенә, яшәү рәвешенә әверелгән.

ТЫЛСЫМЛЫ ТАЯК БАРМЫ?


Фото: Анна Арахамия

Тормышка яңа дулкын – тренинг, вебинарлар заманы килде. Бәхетле, уңышлы булып, үз-үзең белән гармониядә яшәргә өйрәтүчеләр күбәйде.

Нәфисә СӘМИГУЛЛИНА

«Башка» МИН. 2017 ел

Хатын-кызның үзенчәлекле сыйфатларын, талантын ача торган курсның нәкъ яртысын түләрлек акча калды бу юлы банк карточкасында. Тәвәккәлләп язылыргамы ниһаять?! Әллә тагын бераз уйларгамы, бәлки, киләсендә?! Юк инде, болай да бер елга сузылды көтүләрем. Һаман мөмкинлек, вакыт юк, юл мәшәкатьләре... Шулай үземне хуплый-хуплый, катнашырга теләгән тренингның программасын яңадан өйрәнеп чыгам. Карале, мин кызыккан курс инде онлайн үткәрелә башлаган икән! Оho! Мөмкинлекне кулдан ычкындырмаска кирәк, минем кебек кул-аягы белән өйгә, бала тәрбияләүгә бәйләнгән әни кеше өчен бер яхшы билгедер бу! Я-зы-лам!

Психологик тренинглар тиз арада сәләтләреңне ачып, проблемаларыңны чишәргә булыша, сыйфат ягыннан яхшырак тормыш алып барырга ярдәм итә.

Хатын-кызның табигатьтән салынган, әмма дөнья мәшәкатьләренә чуаланып, каядыр тирәндә югала барган сыйфатларын торгызырга, хатын-кыз энергиясен кайтарырга булыша торган беренче тренингка шулай килдем. Мең кат шикләнү, икеләнү, сискәнү аша... Һәм оттырмадым! Остазыбыз шулкадәр көчле һәм оста булып чыкты, безнең курска килгән җиде кызның да тормышында әллә никадәр үзгәреш, яңалык барлыкка килде. Уйларны, гадәтләрне, фикерләүне үзгәртергә, иң мөһиме – үз-үзең белән гармониягә килергә өйрәндек. Шуларның нәтиҗәсе булып, күбебезнең тормышында яңа офыклар ачылды. Өендә тортлар пешерүче берәвебезнең заказлары әллә ничә тапкырга артып китте, ире эшле булды, икенчебезгә тренинг ахырында сөйгән егете тәкъдим ясады – озакламый гөрләтеп туй иттеләр, тагын беребез гаиләсе белән хыялындагы шәһәргә яшәргә күченеп китте... Һәм тагын шундый бик күп үзгәрешләр, үзенә күрә зур могҗизалар килеп керде безнең тормышка. Алдан ук шуны әйтәсем килә: тренингта беркемгә дә тылсымлы дару бирмәделәр. Бары тик тырышып-тырышып айның күренмәгән ягын өйрәнгән астрономнар сыман, без дә үзебезнең яшерен ресурсларны табарга, тормышка башка яктан карарга, хыялларны кәгазьгә теркәп барырга, хыял «тамырын» үстерергә, эмоциональ блоклардан арыну техникаларына, тормыштагы вакыйгаларның күбесе безнең уйлардан, ышанулардан «төзелүен» ачыкларга «гына» өйрәндек.

Иң авыры – үзеңне җиңү, диләр, дөрес икән. Ихтыяр көчен кулга алып, коуч (укытучыбыз) биргән өй эшләрен эшләп баручыларда беренче үзгәрешләр башланды. Үземне хәтерлим: атнага ике тапкыр, колакчыннарны киям дә, айпад аша эфирга «чумам». Өйдәгеләргә нәрсә тыңлаганымны әйтү уңайсыз иде башта, әллә ничек, аңламаслар төсле иде. Үзем өчен дә яңа дөнья бит әле. (Их, шул комачаулый торган тыйнаклык!) Ә могҗизаларым – күптән кызыгып йөргән киемсалым, бизәнү әйберләренең бүләк булып килүеннән башланды. Көтелмәгән бүләкләр бирәләр, алгач ачып карыйм – нәкъ миңа кирәклесе, мин кызыкканы! Ул чакта бер якын кешем белән араларыбыз бозылган иде. Озак борчылып йөрдем. Мөнәсәбәтләрне җайлый торган һәм Рәхмәт техникасын өйрәнгән вакыт. Аерым дәфтәргә әллә ничә көн рәттән шул кешегә рәхмәт сүзләрен яздым. Чыннан да, бик рәхмәтле идем бит мин аңа, тик аралар гына кечкенә бер кызулык аркасында бозылды. Рәхмәт яза башлаганнан соң, бер атна уздымы икән, туган көнем килеп җитте. Иртән иртүк беренче котлауны кемнән алдым дисезме?! Әйе инде, нәкъ шул якын кешемнән! Әйтерсең лә берни дә булмаган! Әй күңелле булды, рәхәтләнеп сөйләштек!

Тренинг вакытында да, аннан соң да мондый гаҗәп хәлләр шактый кабатланды. Барысын да теркәп бармаганга үкенәм хәзер. Тагын бер мисал гына язып үтәм дә... Арабызда курчаклар тегеп сатучы бер яшь әни бар иде. Хәзер кул эше белән күпләр шөгыльләнә, конкуренция дә көчле. Әлеге яшь әнигә дә курчакларын күбрәк сату өчен шактый тырышырга туры килә, күңеле төшкән мизгелләр дә булгандыр. Тренингның башында ук укытучыбыз безгә хыяллар исемлеге яздырды. Бер утыруда 100 хыял язарга! Хыялыңны язу – иң җиңел әйбер кебек тоелса да, бер, ике, өч... биш... җиде... Менә шул тирәдә туктый ул исемлек. Хыял тамырлары шыплап каткан икән безнең. Тырышасыңтырмашасың, язасың, кайбер хыяллар белән күңел килешми, син теләгәне түгел, кешедән кызыгып кына «машина», «чит илгә сәяхәт» турында язулар китә... Кыскасы, сез дә язып карагыз әле ул 100 хыялны. Яза алсагыз, икеләтә отачаксыз: язу дәверендә үзегезнең бу тормышта чыннан да ни теләгәнегезне аңлый башлыйсыз (!) һәм икенчедән, әзер булыгыз – кәгазьгә язылган хыялларның чынга ашу мөмкинлеге бермә-бер арта! Менә шул хыяллар исемлегенә курчаклар тегүче яшь әни үзе теккән курчакны Президентка бүләк итәсе килүе турында язган иде. Ышанасызмыюкмы, ярты еллап чамасы вакыт узганнан соң, бер интернет газетаны ачсам, беренче биттә шул яшь әни теккән курчакны тоткан Президентыбыз елмаеп тора! Алай гына да түгел, Президент курчак тегүче тырыш әнине яшь эшмәкәрләр белән булачак очрашуына да чакырган. Әлеге хәбәрне күреп сөенгәнем истә, чөнки хыялын чынга ашырыр өчен бу кызга үзбәясен (самооценка) күтәрү өстендә шактый күп эшләргә, уй-фикерләрен үзгәртергә туры килгәнен яхшы белә идем.

Ике айга сузылган тренинг тәмамланды. Канатлар үсеп чыккандай хис итәм үземне! Без, хатынкызлар, үз-үзебезне түбәнрәк бәяләргә өйрәнгән бит. Ә монда уңай якларны билгеләргә, аларны үстерергә, хатын-кыз кулында күпме көч барлыгын тоемларга өйрәттеләр. Син бит көчле икән! Күпкә көчлерәәәәәк! Тренингтан соңгы беренче үзгәрешләрне ирем тоеп әйтте: «Син башка хәзер, – ди – Күптән шулай ачыласың калган...» Чыннан да, мин башка хәзер. Инде кызларымны да шуңа өйрәтәсем килә...

Сак булыгыз, тренинглар! 2019 ел

Беренче тренингны шактый зур үзгәрешләр, яңа ачышлар белән узгач, күңелнең нәфесе ачылды. Вакыт булуга, сәламәтлек, финанс, үз-үзеңне табу өлкәсенә караган тренинг-марафоннар эзләргә утырам. Никадәр күп алар! Әле ике-өч



Галия ГЫЙМАДИЕВА,
психолог

– Без хәзер бик матур чорда яшибез. Кешенең үзен, күңел халәтен кайгыртырга күп мөмкинлекләре бар. Россиянең соңгы 100–150 еллык тарихына күз салсак, сугыш артыннан сугыш, революцияләр, дефолтлар, СССРның таркалуы… Элек кешегә исән калу өчен тырышырга кирәк булган. Хәзер заманалар тыныч, кеше, ниһаять, үзенең эчке дөньясы турында уйлана, үзенең сәләтләрен ачарга, үстерергә омтыла. Шуңа күрә нәкъ хәзерге вакытта психологик тренинглар киң таралды. Күбесе онлайн режимда уза. Уздыручылар өчен дә, катнашучылар өчен дә бу бик җайлы формат. Һәркем өйдән торып кына теләгән белгече белән аралаша ала.

Әйбәт коучны ничек табаргамы? Төп киңәшем – күзәтү. Бүгенге көндә бик күп психологлар, тренерлар белемнәре белән бүлешергә тырыша. Тренинг узарга җыенганчы башта тренинг уздыручы коучның социаль челтәрдәге постларын укырга, видеоларын карарга киңәш итәр идем. Тавышы, тормышка карашы, уй-фикерләре күңелегезгә ятышлы булмаса, ул уздырган тренинг сезгә бик авыр бирелергә мөмкин. Коуч белән интуитив якынлык урнашмаса, ул биргән өй эшләрен, төрле биремнәрне эшләү теләге дә булмас. Икенчедән, әлбәттә, узарга теләгән тренинг турында башкалар язган фикерләргә игътибар итәргә кирәк. Иң якын кеше тәкъдим иткәндә дә, үзеңнең күңелеңә туры килү-килмәвен тоемлау мөһим. Тагы бер әйбер бар: ул – җаваплылык. Тренерның җаваплылыгы – кешегә файда китерә торган мәгълүмат, эшли торган техникалар бирү. Ә кулланучы – алган белемен практикада кулланырга, өй эшләрен төгәл үтәргә тиеш. Тренер кешегә тормышын уңай якка үзгәртергә инструмент бирә, ә тренинг узучы ул инструментны ничек куллана, анысы менә һәркемнең үзеннән тора.

ел элек кенә мондый курсларны заманадан алга китеп уйлый белгән, үзләре дә шактый белем, тәҗрибә туплаган чит ил, Мәскәү белгечләреннән белем алган тренерлар гына уздыра иде. Ә хәзер алар шактый күбәйде. Кайсы гына социаль челтәрне ачып җибәрсәң дә, тренинглар рекламасына юлыгасың. Тренинг, марафон, вебинар, курс… төрлечә атала алар. Ашарга-эчәргә, яшәргә, урын-җирне дөрес итеп җыярга, иреңә телефоннан ничек дөрес итеп шалтыратырга… бөтен әйбергә өйрәнеп була.

Иң мөһиме – акчаң гына җитсен! Ә акча ягы… тренинг-марафоннарның бәясе хәзер 599 сумнан башлап, 120 меңгә кадәр җитә. Бүгенге көндә вебинар бизнесы – трендта, иң отышлылардан санала. Күз алдына гына китерегез, тормышның финанс өлкәсен җайларга өйрәтә торган иң гади бер атналык курс 1200 сум тора ди. Мондый вебинарлар, гадәттә, онлайн рәвештә уза һәм дөньяның төрле җирләреннән «яшәргә өйрәнергә теләүче» 300–800 тыңлаучыны җыя. Уртача 400 кеше генә катнашса да, бер вебинардан кергән сумманы үзегез исәпләп карагыз хәзер…

Бүгенге көнгә психология, иҗат өлкәсенә караган шактый вебинарлар уздым. Бу миңа нәрсә бирдеме? Иң беренче чиратта, сәләтле тренерларны акча өчен генә туры эфирга чыгучы тренерлардан аерырга өйрәндем. Әйе, тренерларның төрлесе була. Сине чыннан да шәхес итеп ача белгәне дә, киресенчә, ялгыш юлдан алып китүчеләре дә очрарга мөмкин. Сак булырга кирәк! Күпләр төрле психологик алымнар, баш мие белән эшли торган техникалар куллана. Кирәкме бу сиңа, нәкъ син теләгән әйберме ул? Җаваплылык һәрвакыт үзеңдә булырга тиеш. Вебинарлар миңа үз-үземә ышанычны арттырырга, дөньяга яңа күзлектән карарга, гаиләдәгеләрне әйбәтрәк аңларга, киләчәккә үзем теләгән төгәл юлны билгеләргә һәм бик кызыклы кешеләр белән танышырга ярдәм итте.

…Узган гасырның кырыгынчы елларында Америкада психологлар тарафыннан уйлап табылган вебинар, тренинглар инде безнең тормышка да үтеп керде. Мөмкинлеге булган һәркем шулар ярдәмендә тормышын үзгәртергә, мөнәсәбәтләрне җайларга, дөрес тукланырга, сәламәтләнергә омтыла. Бу дулкында шактый кайнаган кеше буларак, янәдән шуны гына әйтә алам: бер генә тренерның да тылсымлы таягы юк, алар бары тик үзебезне ачарга, барлык җавапларны да үзебездән табарга гына өйрәтә. Белеп торырга кирәк: бу бизнеста да алдаучылар да, алданучылар да һәм үзенә бик күп файда алучылар да бар. Барысын да СЕЗ хәл итәсез.

Ә болай… барлык чикләр дә үзебезнең башта, ә дөнья күпкә киңрәк икән ул!

Тренинг узучы кайбер хатын-кызларның фикерләре:

@aygul_temir_: Тренинглар узу хатын-кызга бик кирәк дип уйлыйм! Шул вебинарларны узып, төрле мәкаләләр укып дөньяга, үземә, иремә, балаларыма булган карашымны уңай якка үзгәртә алдым. Олы кызыма 1 яшь булганда, икенче балабызны алып кайтырга җыендык. Икенче бала тугач, олысы көнләшмәсен дип, психология белән кызыксына башладым. Шуннан китте инде! Тренинглар үз-үзеңне үстерергә бик ярдәм итә дип саныйм.

@elvirahadieva: Миңа тренинглар бер мода сыман гына тоела. Ун ел элек тә күмәк тренинглар бик популяр иде. Хәзер халык онлайн марафоннар уза. Хәзер өч кешенең икесе – «почти табиб». Уйландыра, ләкин ышандырмый.

ФОТОБӘЙГЕ: «ОБЪЕКТИВТА – ӘНИ»



Фото: Рамилә Нотфуллина. Казан.

«Объективта – әни» бәйгесе дәвам итә. Аның оештыручылары – «Сөембикә» журналы редакциясе һәм «Казан Кремле» музей-тыюлыгы. Фотосурәтләрегезне 31 октябрьгә кадәр җибәрә аласыз. Исегезгә төшерәбез: иң уңышлы дип тапкан эшләр журнал битләрендә дөнья күрәчәк, ә көзгә – Әниләр көнендә – Казанда, «Манеж» күргәзмәләр залында алардан күргәзмә оештырылачак. Җиңүчеләрне планшет, кесә телефоны кебек кыйммәтле бүләкләр көтә.
Конкурсның нигезләмәсе һәм шартлары белән сайтыбыздан таныша аласыз: www.syuyumbike.ru.



Фото: Анна Арахамия

БӨГЕЛГӘН БИЛ – СЫНМАС



Гөлнур САФИУЛЛИНА

Сезнең авылда лаеклы ялга чыккан өлкән апалар көннәрен ничек үткәрә? Кызык сорау, бөтен өлкән кешеләр кебек үк өй тирәсендә кайнашып, оныкларга күз-колак булып, телевизордан сериаллар караптыр инде, дисезме? «Бөтен өлкән кешеләр кебек» дип әйтеп ялгышмыйсызмы икән? Бәйрәкәдә, мәсәлән, алай түгел. Дөрес, хатын-кызның йорт эчендә тавык та чүпләп бетермәслек эше аларда да бар, алар да ул-кызларына оныклар үстерешә, бәлки, әле сериаллар да карый торганнардыр. Әмма аларның тормышы күпкә кызыграк! Алай гына да түгел – файдалырак, мәгънәлерәк, дөресрәк! Хәзер барысын да тәртибе белән сөйлим. Бәйрәкә – Ютазы районындагы иң зур авылларның берсе. Туксанынчы еллар башында аларда зур комплекска нигез салына: бер түбә астына клубны һәм спортзалны сыендырырга тиеш була ул. Тик илдә үзгәртеп кору еллары башлана да, төзелеш туктап кала... 2011 елда Бәйрәкәгә килгән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов шушы ташландык төзелешкә игътибар итә. Әлбәттә: «Бу урында нәрсә булырга тиеш иде?» – дип сорый. Җавапны ишеткәч: «Төзеп бетерергә кирәк. Яңа елга өлгертергә тырышыгыз», – дип боерыч та куеп китә. Өлгерттеләр! Шул көннән башлап, «Батыр» спорт комплексы Бәйрәкәнең тормыш кайнап торган бер үзәгенә әйләнә. Сүземнең очы кайсы якка барып чыгасын чамаладыгызмы инде? Әйе, авылның өлкән апалары көн саен иртән «Батыр»га ашыга аларда. Атнасына биш тапкыр! Ышанасызмы, алар инде «шпагатка» утыра! Гомер буе сыер сауган, балаларга дәрес биргән, авыруларга сихәт өләшкән апалар... Алай гына да түгел, алар җырлый, бии – республика күләмендә узган бәйгеләрдә лауреат исемен яулый! Тик боларның барысы хакында үзләре сөйләсә кызыграк булыр кебек. Әйдәгез, аларны тыңлыйк.

Кайда хәрәкәт – анда бәрәкәт.

Зәйтүнә Ямаева: «Агромир» хуҗалыгында 40 елга якын икътисадчы булып эшләдем. Аның бүгенге көнгә кадәр таралмыйча эшләвендә безнең дә өлеш бардыр... 59 яшемдә генә киттем лаеклы ялга. Туктыйсы килеп туктадым: олы кешенең иң кирәк чагы – оныклар үстергәндә... Миндә дә җидәү алар... Әмма гомер буе иҗтимагый эштә кайнагач – ә мин авылның хатын-кызлар оешмасын җитәклим – өйдә тыныч кына утырып булмый икән инде ул... Уннан артык хатын көн саен иртән сәгать тугыздан унга кадәр «Батыр»га гимнастика ясарга йөрибез. Эшкә барган кебек... Башта тренерыбыз белән күнегүләр ясыйбыз, аннан тренажерларга күчәбез. Һәркем булдыра алганча тырыша. «Шпагат»ка утырырга өйрәндек инде... Берәр сәбәп килеп чыгып, йөрми торсаң, сөякләр шыгырдый башлый. Ә анда барып кайткач, шундый рәхәт, җиңел... Бу төркемгә килеп кушылганга ике генә ел әле. Хәлемнән килсә, авылыбызның бөтен хатын-кызын җыеп, үзем белән алып барыр идем.

2012 елда Татарстан ветераннары арасында «Балкыш» үзешчән башкаручылар фестивале хәрәкәте башланды. Ишетеп, укып торабыз – бөтен җирдә ансамбльләр оештырдылар. Ул вакытта Мәдәният йорты директоры булып балачак дустым, гомер буе үзешчән сәнгатьтә бергә катнашып йөргән Зәрия Мөхәммәтҗанова эшли иде. Аның белән: «Әллә без башкалардан кимме?» – дип уйлаштык та, классташым, авылның иң моңлы җырчыларының берсе Сәрия Хисамиевага, гомер буе хуҗалыкта бергә эшләгән Әлфия Хаҗиевага да хыялыбызны чиштек. «Кызлар, тәвәккәлләп карыйбызмы?» – дибез. Гомер буе сәхнәдән төшмәгән кешеләр ләбаса без! «Моңлы саз» шулай туды... Шулай итеп, кышын атнага ике тапкыр кичке сәгать алтыга клубка репетициягә дә җыелабыз әле без. Өч-дүрт кешедән башлаган идек, инде унга тулдык. Репертуарыбызда егермедән артык җыр бар. Әмма һәр концертны Бату Мулюковның Рамазан Байтимеров сүзләренә язган «Бәйрәкәм» җырыннан башлыйбыз:

Әле ярый синдә мин туганмын.
Һәрбер көнең олы бер бәйрәм.
Кая гына китмим, кая гына җитмим,
Сагынып кайтам сине, Бәйрәкәм.

Миләүшә Галиева: авыл советында 32 ел секретарь булып эшләп лаеклы ялга чыктым. Эшемне бик яратып башкардым! Халык миннән риза булып калгандыр дип уйлыйм... Гимнастикага инде дүрт ел йөрим. Җанга да, тәнгә дә моның никадәр рәхәт икәнен белсәгез! «Әйдәгез, безнең янга килегез!» – дип чакыргач, терлек-туар, кош-корт асраучы кайбер хатын-кызлар: «Без өйдә дә җитәрлек шөгыльләнәбез», – диләр. Аерма зур шул! Йорт эчендә, абзар тирәсендә нидер эшләгәндә, йә бик озак бөгелеп кенә торабыз, йә авыр күтәрәбез... Ә тренерыбыз Гүзәл күнегүләр вакытында бөтен буыннарны хәрәкәткә китерергә ярдәм итә. Ирем йөргәнемә сөенеп кенә тора: «Гәүдәң матур сакланачак», – ди. Ялгышып та кыек сүз әйткәне юк. «Минем артист китте», – дип озатып кала, «Артистым кайтты», – дип каршы ала. Клубка Гүзәл янына биергә өйрәнергә дә йөрим бит әле, ансамбльдә дә җырлыйм – шуңа «артист» дип шаяртуы.

Фирдәвес Латыйпова: илле урынлы участок сырхауханәсе бар иде безнең Бәйрәкәдә. Гомер буе шунда шәфкать туташы булып эшләдем. Пенсиягә чыккач, кыскартуга эләктем, аннан инде сырхауханәбезне ябып ук куйдылар. Район үзәгенә барып эшләргә дә мөмкин иде, тик теләмәдем. Өйдә хуҗалык шактый зур иде: мал да асрадык, умарталар да тоттык. Хәзер инде умарталар гына калды... Абзар-кура,







Йөргәннең юлы үтәр, тик торганның көне үтәр.

бакча тирәсендә мәшәкать җитәрлек анысы, әмма өйдә генә утыруга күчү барыбер авыр булды... Өч баланыз өч якка таралды да, ирем белән икәү генә калдык. Ярый шушы гимнастика килеп чыкты. Дүрт ел йөрим инде... Бик файдасын күрәм – үземне күпкә яхшырак хис итәм. Кызлар белән дуслашып беттек – ял арасында да сагынып киләм аларны. Бәйрәмнәрне бергә үткәрәбез – күңелле итеп бергә чәйләр эчәбез...

Мин әле скандинав йөрүе белән дә шөгыльләнәм. Кич саен әнкәй янына барып киләм: ике чакрым – бер якка, ике чакрым – кирегә.

Илүзә Сәгыйтова: 38 ел сыер саудым. Ике ел элек лаеклы ялга чыктым. Эштән туктап калуның авырлыгын тояргa өлгермәдем, чөнки балаларым күбәеп китте. Үземнең өч кызым үсеп җиткәч, опекага тагын өчне алдым. Энекәшнекеләр... Дүрт ел үзем тәрбиялим мәнә – минекеләр кебек инде хәзер алар. Әниләренә кирәкмәделәр – Балалар йортына урнаштырганнар иде. Миннән: «Сез алмыйсызмы?» – дип сорадылар. Ризалаштым... Кечкенәсе алып кайтканда ике яшь ярымлык кына иде әле, анысы «әни» дип дәшә. Олысы – җиденче, уртанчысы икенче сыйныфта укый: алары күбрәк «апа», диләр. Тыңлаучан балалар, әйбәтләр... Алар мәктәптә чакта гимнастикага йөгерәм: гәүдәм җиңеләеп кайта шушыннан. Кеше белән аралашкач, күңел дә күтәрелә.

Эльмира Хәйруллина: без гомер буе Урыссуда яшәдек. Балалар бакчасында эшләдем. Пенсиягә чыккач, ике ел элек Бәйрәкәгә – төп йортка кайтып урнаштык. Өйләрне яңарттык, яңа мунча салдык, сарайлар төзедек... Эш җитәрлек анысы, әмма гимнастикага йөрергә дә вакыт табам. Ирем күп сөйләшә торган кеше түгел минем, ә монда кызлар белән рәхәтләнеп сөйләшеп, аралашып, яңалыклар белеп кайтам... Илүзә белән класстaшлар без – гимнастикага аңа ияреп килдем. Йөри башлаганга әле бер генә ел, әмма сәламәтлеккә файдасын бик сизәм: тәннәр язылып кайта. Рәхәт!

Галия Халикова: тренерыбыз Гүзәл спорткомплекска чакырган вакытта, эштән туктап, үземне кирәксезгә санап, күңелсезләнеп йөргән чагым иде... Мәктәптә 44 ел рус теле һәм әдәбияты укыттым. Бер көн кинәт балалардан аерылгач, үзеңне ярыштан кайткан ат кебек сизәсең икән... Җитмәсә, эштән кайтүгә аякны да сындырдым. Физкультураны мин укыганда ук яраттым. 60 яшькә кадәр чаңгы ярышларында катнашып йөрдем. Район күләмендә узган ярышларда призлы урыннарны да алганым булды. «Батыр»да шөгыльләнү сәламәтлегем өчен кирәк хәзер. Җитмешне уздым бит... Ә моннан энергия алып кайтам! Бик рәхәт кеше арасында. Уңай атмосфера да дару кебек тәэсир итә бит кайчак... Иремнең каршы килгәне юк: ул инде моңа ияләшкән. Укытучы кешедә җәмәгать эшләре күп була – гел өйдән чыгып китәргә туры килә иде. Кызларым да: «Әни, ташлама, йөр!» – дип кенә тора. Үзләре: «Бу җир, теге җир авырта», – дип зарлана башласа, «Гимнастика ясагыз!» – дим. Бер сәгать кенә вакыт табарга була – беребез дә тәүлегенә 24 сәгать буе гел эшләп тормый. Гимнастикага озаграк килми торсам, авырый башлыйм. Организм үзе таләп итә – монда ясаган күнегүләр буыннарым өчен бик кирәк.

Резеда Әрдәширова: озак еллар балалар бакчасында пешекче булдым, аннан колхозда эшләдем. Көн-төн йөгергәннән соң туктап калгач, кыен икән ул... Туктамас идем, операция кичердем, аннары инде эшләргә ярамады. Өйдә нишләп бетәсең?! Бәйләү дә бәйләп карадым, чиктем дә... Балалар инде таралган: берсе – Казанда, икенчесе – Октябрьскида. Оныклар да җәйгә генә кайта. Йөреп карыйм әле, өйдә нишләп утырыйм, дидем... Ирем – эштә, мин өй каравылчысы гына. Авыл җире дә башка бит хәзер – сыер булмагач, бер эш калмады. Аптырагач, кәҗә алдым менә... Авыл кешесе гел эшләп торырга өйрәнгән бит ул, кыймылдаудан туктаса, авырый башлый.

Күнегүләрне, әлбәттә, өйдә генә ясарга да мөмкин, әмма үзең генә булганда темпны дөрес алмыйсың: файда урынына организмга зыян салуың бар.

Кичләрен китап укырга яратам, ә чәршәмбе көнне клубка биергә өйрәнергә барам. Гүзәл: «Тиздән танго бии башлыйсыз», – дип ышандыра.

Нәсимә Лотфуллина: 34 ел китапханәче булып эшләп, узган ел гына пенсиягә чыктым. Туктап калу миңа да кыенрак булды... Шушы комплекс коткарды! Авыл, чыннан да, үзгәрде бит хәзер: капкаларны бикләп куйдык, бер-беребезгә керешмибез – телефон аша гына аралашабыз... Йомыш төшсә генә... Ә монда иртән бер-беребезне сагынып киләбез. Сөйләшүгә сусап та...

Тирә-күршеләр башта сәерсенгән иде, аннан ияләштеләр. Минем спорткомплекска сәгать ничәдә баруыма кадәр белеп торалар, «Аның бүген гимнастика көне», – диләр.

Гүзәл Бикчәнтәева: Бәйрәкәгә килен булып төшкәнемә ун ел. Аңарчы Октябрьский шәһәрендә тордым, бию түгәрәген җитәкләдем. Авылда беркайчан яшәгәнем юк иде. Төп нигездә 95 яшьлек кайнатам – сугыш ветераны берүзе калды да, аны карарга дип кайттык. Авылда яшәү хәзер миңа бик ошый! Монда кайтып урнашкач, спортзалны күрдем дә, шундый куандым. Иртәнге якта буш икәнен белгәч, тагын да сөендем. «Әйдәгез, өлкәннәрне җыям да күнегүләр үткәрә башлыйм», – дип җитәкчеләргә тәкъдим иттем. Миңа бит хезмәт хакы

кирәкми – үземнең шөгыльләнәсем килә. Ә өйдә андый мөмкинлек юк... Команда җыйдым менә. Берсе дә моңарчы гимнастика белән шөгыльләнгән кеше түгел. Әмма бөгелә дә алмаган чаклары артта калды хәзер. Нәтиҗә күз алдында – «шпагат»ка утыручылар бар!

Шәһәргә кунакка баргач, үземнең дусларга спортзалга йөрүебезне сөйлим дә, бөтен тренажерларның безнең өчен бушлай икәнен белгәч шаккаталар. «Их, ерак яшибез. Безгә бит бер тапкыр бару өчен дә 150 сум түләргә кирәк», – дип уфтаналар. Пенсионерлар өчен кыйммәтрәк, әлбәттә... Шуңа күрә Бәйрәкәдә өлкәннәрнең спорткомплекска күбрәк йөрүләрен телим дә.

Әмма иң зур хыялым бию белән бәйле минем... Чит илләрдә менә шундый яшьтәге өлкәннәр бергә җыелалар да танго, рок-н-ролл бииләр. Флешмоб кебек... Хәрәкәтләр катлаулы түгел, гади – һәркем кабатлый ала. Биергә килүчеләр шундый зур канәгатьлек алып кайтып китә. Өйрәтә башладым башлавын, тик халыкны кузгата алмадым әле. Әмма кузгатачакмын!

Ирем Азатның ялгышып та: «Нишләп йөрисең анда?» – дигәне юк. Киресенчә, кайсы көнне: «Нигә бүген бармыйсың?» – дип сорый. «Ничә кыз килә? Нигә күбрәк йөрмиләр?» – дип гел кызыксынып тора. Вакыт җитми, диючеләр белән килешмим – эшең күп булганда барысына да өлгерәсең! Шулай бит?!

Әлфия Хәҗиева: мин – Бәйрәкә авылының ветераннар советы рәисе. Лаеклы ялга чыкканчы Зәйтүнә белән бер коллективта эшләдек. Ул – икътисадчы, мин – кадрлар буенча инспектор. Элек тә колхозда бәйрәмнәрне бергә оештырып, смотр-концертларда катнашып йөрдек. «Балкыш» фестивале башлангач, бер чор кешеләрен үз тирәбезгә җыйдык. Гармунчыбыз Рәсим абый – Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, ул да элек безнең белән бергә эшләде... Палас сугучы Тәнзиләне ансамбльгә биергә дип чакырдык. Алар өчәү – Зөфәр Камаев, Тәнзилә һәм Зәйтүнә шаян татар биюе белән «Балкыш» фестивалендә катнашып, 2016 елда башкаладан лауреат исеме яулап кайттылар. Вера апа Әхмәтҗанованың ире мәрхүм булды да, берүзе калды – балалары читтә. «Чакыргагыз килер идем», – диде. Күптән түгел туган көнендә торт алып килгән: «Рәхмәт, сезнең янда кәефем күтәрелә», – ди... Флера Садыйкованы да пенсиягә чыгуга бер ел элек үзебез чакырып алдык...

Беренче костюмнарны үз акчабызга тектергән идек. Бөтенроссия «Түгәрәк уен» татар фольклоры фестивалендә катнашып, I дәрәҗә диплом алып кайткач, хуҗалык рәисе Сиринь Әхәтович: «Кайчаннан бирле бер костюмнан йөрисез, нигә сорамыйсыз?» – диде. Яңа костюмлы булдык шулай итеп...

Иң зур проблемабыз – безнең белән шөгыльләнергә махсус белемле җитәкче юк. Ике тавышка җырлый белмибез – югыйсә авылыбызның сәхнә яраткан өлкәннәрен туплаган ансамбльнең уңышлары тагын да күбрәк булыр иде.

Тәнзилә Мәрданшина: миңа инде 67 яшь. Гомерем буе балалар бакчасында тәрбияче булып эшләдем. Бу авылга килен булып килгәннән бирле сәхнәдән төшкән юк. Әле дә чакырып торалар – картаерга ирек бирмиләр. Аякта йөргәндә, ястыкка менмәгәндә йөрергә кирәк дип саныйм. Ирләребез риза булып торганда... Минеке: «Бар инде, соңга каласың», – дип озатып җибәрә, «Исән-сау йөреп кайттыңмы?» – дип каршы ала. Ансамбль белән бәйгеләрдә катнашабыз, яңа җирләр күрәбез – күңелле!

...Йә, ничек, кызыктыгызмы бәйрәкәлеләргә? Аларга кушылырга теләмисезме? Шулай, селкенгән сын – талмас, бөгелгән бил – сынмас... «Батыр» кебек комплекс бөтен җирдә булмаса да, клуб ишекләре сезнең өчен һәркайда ачыктыр. Теләк кенә кирәк!



■ «Моңлы саз»ны 2012 елда оештырган идек, шуннан бирле таралганыбыз юк менә. Яңа кешеләр дә өстәлеп тора.

ЧИТ ИЛДӘГЕ ТАТАР УТРАВЫ





Раилә ХӘЯЛИЕВА

Яшәү урыннары – Прага, кызыксынулары – иге-чиге булмаган дөнья, сулышлары – океан, тормыш фәлсәфәләренең чагылышы – балалары Сара белән Туранда. Без бүген чит илдә матур татар утравы булып яшәүче Лилия һәм Раил ӨМЕТБАЕВларда кунакта.

Көне буе өйдә кем хуҗа?! Әлбәттә инде, балалар белән декрет ялында утыручы әни кеше! Лилиянең өстәле һәрвакыт әзер: чизкейк сыйфатындагы Алман классикасы «Кейзекухен», сигезаяк салаты, җиләк-җимеш, тәмле чәй... Өйдә тагын бер зур хуҗа бар – нәсел дәвамчысы, яшь ярымын тутырып, әле күптән түгел генә тәпи киткән, бураннар уйнаткан Туран! Апасы Сараны балалар бакчасына илтергә дә ул булыша, әнисенә чех теле курсларында укырга, яшелчәләр алыр өчен базарга йөрергә, почтага кереп чыгарга, көнкүреш мәшәкатьләрендә кайнарга ул ярдәм итә әнә.

– Әниемнең тамырлары – Әтнәдән, әти Балык Бистәсе районыннан. Мин дә, Раил дә Казанда туган. Әнисенең тамырлары Биектау районына барып тоташа, әтисе – Чуаштан ягыннан, – дип гаилә тарихы белән таныштыра башлый Лилия.

Ә яшьләр үзләре 2012 елда... Прага шәһәрендә танышканнар. Бик кызык килеп чыккан ул. Раилнең «Татарстан–Яңа гасыр» телерадиокомпаниясендә эшләп йөргән вакыты әле бу. Испаниягә ял итәргә барганда Прагада узучы Сабантуйга кереп чыгарга уйлый ул. Лилиянең дә эше бик кызу – Берлинда магистратурада укып, имтиханнарга әзерләнеп йөргән вакыты. Шулай да кыз, укудан, бераз ял итеп алыйм дип, дуслары чакыруы буенча берничә генә сәгатькә Прагага милли бәйрәмгә килә. Менә шунда беренче тапкыр бер-берсен күрә алар. Исәнлек-саулык сорашудан узмаган гади генә аралашу була ул. Алай да Раил тагын бер атнадан үзенең Берлинда буласын әйтә, Лилиядән шәһәрне күрсәтүен сорый. Шулай итеп, Берлинда яңадан күрешергә сүз куешалар.

Уку, төрле курсларда белем ныгыту, телләр өйрәнү... Шулай, арып-талып өйгә кайтып егылган бер кичтә



Раилдән хәбәр килеп төшә: «Мин Берлинда, очрашабызмы?» Әйткән сүз – аткан ук, сүз бирдеңме – үтәргә кирәк. Әмма шулкадәр арылган... Раил тукталган җир шәһәрнең икенче очында булса очрашуга барып булмас дип уйлый Лилия. Ә Раил бер тукталыш аралыгында гына урнашкан икән! Очрашалар алар ул кичтә. Берлин белән танышалар, сөйләшәләр, тормыш кыйммәтләрен барлыйлар. Чынлап торып танышу шунда булгандыр инде.

...Март аенда Лилиянең укулары тәмамлана. Инде укуын Гонконгта дәвам итәргә максат куеп, гаризалар тутыра кыз. Димәк, сентябрьдән яңа илгә сәфәр чыгасы. Ә аңа чаклы Казанга, якыннар янына кайтып килергә дә була! Казанга кайткач, Лилия Универсиада дирекциясенә эшкә урнаша. Раил белән Фейсбукта язышып торалар. «Аралашкан саен, уртак темалар күбәйде. Раил тормышка да җиңел карый. Гаиләдә хатын-кыз тегенди-мондый булырга тиеш дигән катлаулы таләпләре дә юк кебек. Аның мөстәкыйль булуы бик ошады», – дип искә ала ул чакларны Лилия. Универсиадада эшләгәндә юллар яңадан кисешә яшьләрнең. Эш буенча очрашалар, кайчак киногa да бергәләп баралар. Һәм... җәй башында Раил Лилиягә тәкъдим ясый. Һич көтмәгәндә! Бу тәкъдим шундый көтелмәгәнчә була! Ничек инде, Лилия бит Гонконгка китәчәк. Тәкъдим ясавы да бит әле – «смс» аша!

– Чынлап әйтәм, шаяра дип уйладым мин аны, – ди Лилия. – Шуңа үзем дә җиңел генә җавап язып җибәрдем: «Әйе-е!» «Никахны кая укытабыз соң?» – дигән җавап килә, «Әй, үзең сайла инде», – дим, уйнап язышуны дәвам итеп. Шулай да бераздан күңелгә шом керде. «Син әллә чынлапмы?» – дим. «Чынлап! Хәзер әниләргә дә кереп әйтәм», – димәсенме! Минем әниләр шок хәлендә килде. Кызлары Кытайга китәргә җыена, ә без өйләнешү турында хәбәр итәбез! Никахны җәй башында укыттык. Туебыз 11 август көнне булды. Чынлыкта, туй да уздырасы түгел идек әле. Әмма минем әниләрнең кыз үстереп тә, туй ясамыйча бирәселәре килмәде.

Казанда – Универсиада, Өметбаевлар туй мәшәкатьләре белән гөр килә. Чын мәгънәсендә кызу җәй була ул!

– Гел үзем генә яшәргә күнеккәннән соң, дөньямда тагын бер кешенең барлыкка килүе бераз сәер иде миңа. Кемдер бертуктаусыз сине кайгырта! Әй рәхәт! Сентябрьдә Кытайга укырга киттем. Әмма Европада укыганнан соң, кытайларның тәртипләрен кабул итә алмадым. Банк хисабы, фәнни җитәкчеләр белән дә проблемалар чыга башлады. Бөтен дөнья: «Юк, бу синеке түгел», – дия иде сыман. Өч атнадан ташладым да кайттым. Шуннан соң Раил белән гел бергә без.

Лилия нинди генә максат билгеләсә дә, Раил беркайчан каршы төшми, үз иркенә куя. Казан университетына аспирантурага керәм дигәч тә... Юк, аспирантурага кергәнче, Лилия үз тормышын күздән кичерә дә, үзенә STOP! дия әле. Мәктәп, университет, чит илдә өч елга сузылган ике магистратура, Кытайдагы докторантура... Күпкә киткән бит! Һәм ул үзенә бер ел ял бирә. Язын яңадан аспирантурага керү хәстәрен күрә. Ул арада яшь гаиләгә әти-әни шатлыгын тату насыйп була.

Әти-әнинең яшәү рәвеше акрын гына балаларга да сеңә.

Сара белән Туран

Сара Казанда дөньяга килә. Ә Туранны Прагага яшәргә күчкәч «алып кайталар». Балаларга төрле телләргә күчергәндә дә язылышлары, әйтелгәндә хәрефләре үзгәрмәгән исемнәр сайларга тырышалар. Борынгы, төрки исем булуы да мөһим. Сара – дини яктан тарихлы, тамырлы исем. Сара – «ханым» (госпожа), Туран – «җир, дәүләт» дигәнне аңлата. «Ир баланың исеме кечле яңгырасын өчен «р» хәрефе дә булсын», – ди Раил.

– Беренче бала белән күземне йомып алга барганмын сыман, – ди Лилия көлеп. – Туран тугач, икенче сулышым ачылды кебек. Бала гына тапмадым, үземне дә таптым, зирәклек тә килде сыман. Баланың температурасы күтәрелсә дә, әллә ни ис китми, тыныч кына даруын бирәм. Туран елый башлаганчы үз эшләремне эшләп йөрим. Сараны тапкач, дөньядан артта калам сыман тоелган иде. Әле Сара тыныч ул, бик тәти кыз булды. Ә Туран көчле характерлы безнең, үзенекен итәр өчен умырып ташларга да күп сорамый. Чехларда шундый әйбәт гадәт бар, алар балаларын кечкә сигездә йоклатырга ияләнгәннәр. Әкренләп без дә шул режимга күчтек. Рәхәт... Балалар йоклагач, Раил белән үзебезчә яшәп алырга кимендә ике сәгать вакыт кала.

Әти кеше эштә, без Лилия белән мондагы яшәү рәвеше, гаиләдәге гадәтләр турында гәпләшәбез. Чит илдәге әниләрнең бала ялы ничек уза икән?

– Атнага ике тапкыр йогага йөрим, чех теле дәресләренә барам. Шимбәләрен китапханәдә фәнни эшләрем белән шөгыльләнергә тырышам. Анда өстәлләр дә, интернет та, кофе машиналары да бар. Раилнең мине аңлавы, теләгән вакытта теләгән эшеңне эшлә дип торуы бик мөһим. Америкадагы татар диаспорасы темасына яза башлаган фәнни эшемне тәмамлыйсым килә. Менә бу Туран исемле егетнең балалар бакчасына киткәнен генә көтеп ятыш...

Гаилә йолалары

Чит илдә татар гаиләсе булып яшәүнең читенлеге белән әлегә очрашмаган Раил белән Лилия. Гаиләдә фикер йөртү, сөйләшүләр татарча гына. Сара биредә узган Сабантуйларны бик ярата икән. Бала өчен милли рухтагы бәйрәмнәрдә бөтерелеп, җылы, якты истәлекләргә күмелеп үсү мөһим. Раил татар яшьләре оештырган төрле чараларга йөри. Прагада татар яшьләре бик актив икән.

– Сара белән Туран намазлыкка утырган әти-әнисен күреп үсәләр. Таләп итмибез, үрнәк күрсәтергә тырышабыз, – ди әни кеше. – Еш булмаса да, бергәләп татар җырларын җырлыйбыз. Раил ретро җырларны кабызып җибәрә кайчак. Сара күбрәк тыңларга ярата. Тыңлыйтыңлый да, аннары трамвайда йә урамда җырлап җибәрә. Биергә дә бик яратабыз.

Фото: гаилә архивыннан

Китап язарга миңа бернәрсә дә комачауламый иде, нияте яхшы булса, акчасы табыла аның.

Бу гаиләнең тагын бер яраткан гадәте – балалар белән сәяхәт итү. Туран тугач, Франция, Испания, Исландиягә барып кайтырга өлгергәннәр. «Безгә яңа урыннар күреп торырга кирәк. Сәяхәтләр безнең өчен китап уку, су эчү кебек зур бер ихтыяҗ. Яңа дөнья күрү балаларның үсешләренә дә уңай тәэсир итә дип уйлыйбыз», – ди үзләре.

Тәрбия фәлсәфәсе

– Бала белән бик күп сөйләшергә һәм аңа барысын да аңлатырга кирәк. Аңлатканда баланың башында мантыйк үсә. Әле күптән түгел генә Польша чигенә зур кыялар карарга барган идек. Сара шунда кап-кара төстәге күл күрде. Табигый рәвештә кыялар арасында җыелып торган, агач тамырларыннан каралган су иде ул. Кызым аңа шаккатып карап торды. Нишләп кара күл булуы турында сорады. Баскычлардан менә-төшә арып беткән булсак та, кызыбызга бу күл турында тәфсилләп сөйләргә туры килде. Икенче яктан, балалар үзләрен гел без уйлаганча гына да тотмый. Менә монда педальсез велосипедлар модада бит инде. Шундый велосипедларда йөреп ничә сапоги-кроссовканың башын тишкәнне белсәгез! Аңлатып карыйм, алай йөрергә ярамый дип. Юк! Аптырагач, тишек сапоги белән дә йөртеп карадым, вакыты җитмичә барыбер шул велосипедны ташламадык. Бу очракта аңлау үз вакыты белән килде.

Киемнәрне секонд-хендтан алырга тырышам. Моңа үз карашыбыз бар: планетада чүп бик күп, нишләп без дә тагын бер чүп сатып алыйк дип, аңлатам балаларга. Мондагы татарлар арасында балалар киемнәрен алмашу гадәте бар. Киемне нindидер кабык кебек кенә кабул итәм. Баланың тышкы кыяфәте аның үзе турында бернәрсә дә сөйләми дип саныйм. Уен мәйданчыкларына килгәндә дә әниләр алмаш кием белән килә. Балалар комда аунап рәхәтләнеп уйный. Бу – артыгын рөхсәт итү дигән сүз түгел, уен белән мавыккан балага дөньяны кабул итүгә ә бала бирелеп дөньяны кабул итүгә комачауламау гына. Бездә «ярамый, киемеңне чиста тот, әшәкеләтмә», – дигән әйбер юк. Андый чикләр куймыйбыз. Бала бит ул «ярамый»ларны җыя-җыя да, аннары үскәч, «ярамый»ларын шундый итеп чыгарырга мөмкин! Беркемнең дә иминлегенә зыян салмый икән – балага ирек бирергә кирәк. Сәер инде, әгәр дә син балага үз балачагын иректә уздырырга рөхсәт итсәң икән, бу аздыру кебек кабул ителә.

«Бану маҗаралары»

Игътибар иткәнсездер, быел татар дөньясы чит илдә яшәүче татар әнисенең татар балаларын мөстәкыйль рәвештә фикерләргә өйрәтүче китап язуы һәм аны бастырып чыгару өчен бөтен дөньядан иганәчеләр эзләве турында сөйләп, шау-шу килеп алган иде. Китап инде басылып ята. Ә бу китапны язучы – безнең героебыз Лилия була инде!

– Бану турындагы китап Сараның китаплар дөньясына кереп китү тарихы белән бәйле. Кызымны китаплар белән таныштыра башлагач, Казаннан кочак-кочак татарча китаплар алып килдем, берсе дә баланы кызыктырмый. Тәрҗемә итеп укып карадым, алай да бармый...

Чехиядә китапларны яратырга бик иртә өйрәтәләр. Атнаның бер көнендә Сара йөри торган балалар бакчасына әти-әниләрне китап укырга чакыралар. Анда теләгән китабыңны укый аласың. Инглиз, чех китаплары бала кабул итә торган рәсемнәр белән матур эшләнгән.

Танышларым белән заманча татар китабы турында сөйләшеп утырдык та, үзең язып кара әле, диделәр. Бу сүзләр бик илһамландырды, һәм мин 2019 елны китап язуга багышлап карыйм әле дип эшкә керештем.

Китап язу идеясе кызымның үсешен, балалар психологиясен өйрәнгәннән соң барлыкка килде. Әсәрнең герое Бану – җыелма образ, аның кайсыдыр бер өлеше үземнән, Сарадан һәм мин белгән яшь әниләрдән алынган. Китап язуым турында белдергәч, малайлар турында да шәп китаплар кирәк, дигән хатлар алдым. Ләкин китапны уйлап чыгарып кына язып булмыйдыр ул. Аның өчен башымда күзәтүләр җыелырга тиеш. Хәзер менә улымны күзәтәм. Бәлки, малайлар өчен дә берәр әсәр туар әле.

«Бану маҗаралары» күзәтүләрдән чыгып, җиңел тел белән язылды. Татар китаплары арасында әлегә андыйны очратканым юк. Бездә бит китап – супер-мега әйбер булырга тиеш кебек кабул ителә. Аны олпат язучылар гына яза ала кебек. Баксаң, балалар бестселлерларын, нигездә, балалар дөньясын яхшы аңлаган, күзәткән декрет ялындагы әниләр язган икән бит! Китап язу өчен балаларны аңлап, аларның күңеленә үтеп керергә кирәк. Олылар тарафыннан гына ничек булырга тиеш дип язылган китапларны алар кабул итми. Китап язып карау миңа бик ошады, яңа сулыш, яңа тәҗрибә булды.

Баланың китапны кабул итүен фәнни яктан өйрәнгән галимнәр фикеренчә, аны кая утырып уку, әти-әни белән сөйләшү, фикерләшү, баланың кулы җитәрлек урынга кую, тактиль рәвештә битләрен ачып, танып белү – болар барысы да китап уку мәдәниятен сеңдерүгә зур өлеш кертә, диләр. Минем дә татарча китап уку мәдәниятенә үз өлешемне кертәсем килә. Китап язып, бизнес проект эшләргә тели, дип гаепләүчеләр дә табылды. Әмма татар китабы язып супермиллионнар эшләп буламы соң? Гафу, әлбәттә... Минем кебек тагын ун әни балалар өчен татарча китап язарга алынса да шәп булыр иде әле! Туган телдә язылган балалар китаплары стена булып һәр өйдә өелеп торсын иде ул!

...Лилия һәм Раил Өметбаевлар гаиләсенең яшәү рәвеше, уйлау киңлекләре, фәлсәфәләре безнекеннән нык аерыла. Ничектер иркен аларның дөньясы, бернәрсәгә дә бәйле түгел. Алар белән аралашкан саен, иркен сулыш аласың, нидер үзгәртәсе килә башлый. Менә шундый татар гаиләләре – милләтнең төп байлыгы бит инде!

Тулысынча сайтыбызда: www.syuyumbike.ru

ЮМАРТЛЫК



Илнар хәзрәт
ЗИННӘТУЛЛИН,
«Туган авылым»
мәчете
имам-хатыйбы

Нәрсәне юмартлык дип әйтәбез?

– Юмартлык – үзеңдә булган әйберне башкалар белән бүлешә алу. Моңа мал, акча гына керми. Мәсәлән, пәйгамбәребез: «Адәмнең һәр буыны сәдака бирергә тиеш», – ди. Юмартлыкны без иң элек сәдака белән бәйләп карыйбыз. Әмма ислам дине аңа бик киң мәгънә бирә. Һәрбер буыны ничек була ул дигәч, пәйгамбәребез: «Кешегә атына утырырга булышу, йөген күтәрешү, атын тотып тору – болар барысы да сәдака», – ди. Ягъни вакытың һәм көч-куәтең белән бүлешү. Кардәшеңә елмаеп карау да сәдака. Хәтта «сөбханалла», «әлхәмдүлилләһ», «Аллаһу әкбәр» дип әйтү дә. Өйгә хатыныңа ризык алып кайтып бирү дә сәдакага керә ди пәйгамбәребез. Өйдә хатынның – иренә, ирнең хатыны өчен эшләгән эшләре дә. Кайвакыт байларны саран дип әйтәләр. Хәерче дә саран булырга мөмкин – ул башка яктан саран: кешегә булышмый, көнләшә, елмаймый...

Кеше мал ярата, шуңа күрә ул аны гел җыярга тырыша. Җыю халәтеңне җиңеп, булган әйбереңне кемгәдер бирә алсаң, димәк, син юмарт буласың. Коръәни-Кәримдә «яраткан әйберләрегезне кешеләр белән бүлешмичә торып, игелеккә ирешә алмаячаксыз» диелгән. Үзеңнән өзеп кемгәдер бирү – бик авыр. Кемдер: «Мин тырышып, хезмәт куеп эшләдем, хәзер болай гына нигә бирергә тиеш?» – дияргә мөмкин. Җавапка бернәрсә өмет итмичә кемгәдер нәрсәдер бирүне күпләр аңламый. Шуңа күрә юмартларның дәрәҗәсе зур да.

Пәйгамбәребез дә юмарт булган. Артык әйбере булса, ул борчылган, ә без, башкалардан артык әйбер булмаса, тынычлыкны югалтабыз... Кешеләр нидер сорап килгәндә: «Хәзерге вакытта акчам юк, ләкин базарга барыгыз да ни теләсәгез шуны алыгыз – минем исемгә яздырыгыз», – дигән. Әлбәттә, бу халәткә ирешү бик авыр.

Нинди өлкәдә генә юмарт булсаң да, Аллаһы Тәгалә аның әҗер-савабын вәгъдә итә. Бурычка акча биреп тору да – юмартлык. Пәйгамбәребез: «Күктә ике фәрештә бар. Алар көне буе дога гына кылып утыра. Берсе: «Йа Раббым, юмарт кешегә малын арттырып бир», – дип; икенчесе: «Саран кешенең малын юкка чыгар», – дип дога кыла. Шуңа күрә юмартлар, гадәттә, хәерче булмый, Малы күп дигән сүз түгел бу, алар, интегеп, хәерчелектә яшәми, тапканы бәрәкәтле, күңеле бай. Юмарт кешегә карата башкалар да юмарт була. Булган малларыбызның бөтенесе дә Аллаһы Тәгаләнеке. Саранланып аны үзеңә генә җыю – рәхмәтсезлек билгесе. Аллаһы Тәгалә сиңа биргән икән – бүлеш. Безнең авыруларыбыз да шуннан килеп чыга. Аллаһы Тәгалә: «Сәдака биргән кешенең авырулары дәвалана», – ди. Саранлык авыруга, хәтта физик авыруга китерә. Буыннардан сәдака кирәк дидек: кешегә булышмасаң, хәрәкәт итмәсәң, буыннарың сызлый башларга мөмкин.

Юмартлык күрсәтүгә без мохтаҗ да. Аллаһы Тәгалә: «Аларның (ягъни мөселманнарның) малында сорап килүченең яки берәр нәрсәдән мәхрүм булган кешенең өлеше бар», – ди. Малыбыз үзебезгә җитә һәм арта башлый икән, димәк, анда ниндидер мохтаҗның өлеше бар. Аллаһы Тәгалә малны биргәндә: «Менә мин сиңа күбрәк бирәм, син теге кеше белән бүлеш», – дигән. Бүлешмибез икән, кеше малын үзләштергән булып чыгабыз. Сәламәтлек белән дә шулай. Кемгәдер ул артыгы белән бирелә икән, сәламәт булмаган кешеләргә булышыр өчен дә бирелә.

Юмартлыкның чиге бармы?

– Пәйгамбәребез: «Бөтен малыгызны биреп бетермәгез», – ди. Әмма «алай ярамый» дигән сүз түгел бу. Кайвакыт андый адымнан соң: «Нәрсәгә эшләдем инде моны? Үземә нәрсә калды?» – дигән уй килә. Шулай үкенеп куйсаң, моның инде савабы булмый. Ләкин сәхабәләр арасында бөтен малын Аллаһ юлына бирүчеләр тарихта булган, һәм пәйгамбәребез аларны мактаган.

Коръәни-Кәримдә «кулларыгызны муеныгызга бәйләмәгез», ягъни саран булмагыз, әмма акчагызны исраф та итмәгез, диелгән. Тик акчаны курыкмыйча тоткан кеше, кысмырга караганда, яхшырак: аның акчасы кемгәдер хезмәт итә. Ә саран кешенеке ята, беркемгә файда китерми.

Үзеңә карата да юмарт була белергә кирәк. Кайберәүләр үзләреннән акча жәлли – берни алмый, тәмле ашамый... Пәйгамбәребез: «Аллаһы Тәгалә биргән малны үзеңдә дә күрергә тели», – ди. Чөнки ул бездә Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылуны арттыра.

Ир белән хатын бер-берсен юмартлыктан тыя аламы?

– Хатын-кыз ир кешене тыя алмый: аны бу очракта Аллаһы Тәгалә генә тыя ала. Чөнки иргә башта асыл хаҗәтләрне үтәргә кирәк. Хатыны, балаларының ашарына, киярене, торырга урыны булмаса, ул, мал таратып, юмарт булып йөри алмый. Бу вазыйфаларны үтәгәч кенә башкаларга өлеш чыгара. Хатын-кыз исә сәдака бирергә теләсә, иреннән рөхсәт сорарга тиеш. Бу – үзе эшләмәгән очракта. Әгәр эшли икән, үз акчасыннан сәдака бирә ала – ирнең аны тыярга хакы юк.

Кайбер кешеләр үләр алдыннан бик юмарт булып китә. Пәйгамбәребез нинди сәдака әйбәт дигән сорауга: «Яшь, сәламәт вакытта, фәкыйрь булырга курыккан чакта биргәне», – ди. Ә үләр алдыннан: «Бу әйбер – моңа, монысы – тегеңә», – дип ятуның савабы булмый ди. Малыңны калдырып китәчәгеңне аңлагач... Соңгы сулышта, юмартланып, барысын таратып, балаларыңны өлешсез калдырырга да ярамый. Аларның сиңа ачуы, нәфрәте барлыкка килүе мөмкин.



Рафаэль
СИБАТ

Мөдәррис Әгъләм архивын актарып утырганда, саргаеп беткән кәгазь битләрендә Рафаэль Сибат шигырьләре килеп чыкты. Укыдым. Сокландым. Чын шигърият кенә кеше җанына шулай тәэсир итә аладыр... Рафаэль Мөдәрриснең яшьтәше иде: аның белән бер үк елда, бер үк айда туган, тик Мөдәрристән өч ел алдарак кинәт вафат булды.
Бу баһадир егетне студент елларыннан ук хәтерлим. Хуҗин Рафаэль чагыннан ук. Сибат – тәхәллүсе. Мөдәррис аның янәшәсендә ат янында колын сыманрак кына күренсә дә, Рафаэль шагыйрь Мөдәррискә астан карап сөйләшә иде. Менә бу кулъязма-шигырьләрен дә ул аның хөкеменә тапшырган булгандыр. Очраклы кулъязмалардан Сибатның тормыш юлын күздән кичердем. Бөтен татар дөньясын шаулаткан «Ялгызак» романыннан соң, мин аны нишләптер «югалтып» торганмын икән...
Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач, 1970–78 елларда ул туган якларында балалар укыта, урта мәктәп директоры була, аннары Казанга килеп, Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында администратор хезмәтен башкара. Бераздан Кукмарага кайтып, район халык театрында режиссер, Киров шәһәрендә классик көрәш буенча тренер булып эшли. Ул үзе дә заманында мәйдан тоткан, күп мәртәбәләр батыр калган ир-егет ләбаса! Түбән Шөн авылы мәдәният йортында – сәнгать җитәкчесе, Киров өлкәсендә татар телендә чыгучы «Дуслык» газетасының әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире булып эшләгән еллары да күз алдында... Һәм шул елларда Рафаэль никадәр матур әсәрләр иҗат итте! Романнар, трилогия, тетралогия, роман-монологлар... «Ялгызак» (2001 ел), «Көлдән күтәрелгән гөлләр» (2002 ел), «Без дә җирдән күтәрелгән» (2003 ел), «Кайту» (2005 ел)... Кара инде, әйтерсең лә көрәшче бәйгегә көч җыйган да мәйданга атылган! Китәсен сизенгән кебек ашыккан каләм иясе: биш ел эчендә күпме әсәрне дөньяга чыгара алган һәм...
Бу кадәрләр дә ташу, яну, бу кадәрләр дә йөкне тартып бару өчен адәми затның йөрәге, бигрәк тә нәфис шагыйрь йөрәге ничек чыдасын – 60 яшен дә тутыра алмый китеп барган. Аны искә алу кичәләре булдымы икән? Шундый кичәдә булса да, каләмдәшемнең иҗатына соклану хисләремне түгәр идем...

Нәҗибә САФИНА

Ирләр

Ирләр ауса – илләр ава...
Алар моны белгәннәр.
Менә шуңа чын батырлар
Аягүрә үлгәннәр.

Ир еласа – илең елый,
Нык егетләр аңлаган.
Еласыга җырлаганнар –
Бөтен дөнья тыңлаган.

Ирләр бетсә – илең бетә,
Булмый монда бирелеп.
Шуңа күрә үлгәч тә бит
Кайткан алар терелеп.

* * *

Һич чамасыз ялган дан-шөһрәтне
Тик бер генә башка өйгәннәр.
Тапталганнар калка, түбән төшә
Үзен «бөек» диеп йөргәннәр.

Нигә кырыкканнар читләр уен?! –

Түбә шәрә икән, ян-як чәчле.
Пеләш калмый баш та бөтенләй.
Агач-фикерләре калганнарның
Сыек даны оча төтендәй.

Тал песие

Тал песие язны сизгән, –
Йомшак йоны кабарган:
Сөйкемләнгән, чибәрләнгән,
Моң сирпелә аңардан...
Җылы моң ул, җырлы моң ул:
Зәңгәрсу-аксыл төсләр.
Тал песие ботагыннан
Сикереп җиргә төшәр –

Ул моң агар гөрләвектәй,
Барлык сагышны басып.
...Тал песие ак моң сибә –
Кар әле, язның башы...

Төнге күккә карап уйлану

Күктән йолдыз коела,
Сибеп йөриме Ходай...
Берчак шулай безнең бабай
Җиренә чәчкән бодай.

Хыялында иң изге уй:
«Ипигә туячакбыз!»
Ә учында – безнең җаннар:
Тишелсә – туачакбыз!

Һәр бөртеген йолдыз итеп
Бабакай чәчкән бодай.
Шул инде безнең башлангыч,
Ул үзе – безнең Ходай!

* * *

Шапырынган, мактанганнар –
Уенчык шарлар бары.
Күпме еракка очса да,
Ахырда шартлый барып...

Булмаганны «Юк!» дияргә,
Нигә күкрәк кагарга?
Язлар җитсә каралачак –
Чын ак түгел ак кар да...

Ханым

Сезнең кочакка ташланам,
Ак чәчәкле баланнар.
Маңгаемнан үбегез сез, –
Әй шомыртлар, балам бар!

Һәм баланнар сөйли-сөйли
Ханымны коча гына:
«Ә әтисе бу нәнине
Ник алмый кочагына?»

Сорый аннан шомыртлары
Суырып үпкән хәлдә:
«Ә әтисе нарасыйның
Үбә белмиме әллә?»

Әйтеп куйды ул көрсенеп:
(Авыр сүзләр телдәге)
«Күп нәрсәне белә иде...
Ата була белмәде...»

* * *

Безне башта сөймәделәр –
Гаепләп сөйләделәр.
Яратмады читтәгеләр,
Якыннар – өйдәгеләр...

Ә соңыннан яраттылар,
Әйбәт сүз тараттылар.
Соңгы уй моңсу мидә:
«Янгын беткәч, су нигә?»

Яшәү фәлсәфәсе

1
Китаплардан укып түгел лә! –
Бу фикерем яшәп түгелә...
2
Бу дөньяда бар да үтәчәк!.. –
Һәрбер килгән бер көн китәчәк...
3
Мең иманлы түгел бу тормыш –
Бер иманда меңләп буталмыш...
4
Өметеңне салма беркемгә –
Өмет сүнәр гади бер көндә...
5
Һәрвакытта Рухны үсендер –
Иң зур байлык – тик син үзеңдер.
6
Саулык юкта байлык күренми –
Мал җыйсаң да җирдә иренми...
7
Чирләп ятсаң озак түшәктә –
Сөймәс сине ялкау ишәк тә...
8
Иң беренче үзең «Шәп!» булсаң –
Дөньяларны йөзеп шәп торсаң:
9
Дошманнарга гайрәт булырсың,
Дусларыңа гайбәт булырсың...
10
Кемнәр генә дөнья кичми лә –
Бер гөнаһсыз түгел һичкем дә...
11
Тормыш – диңгез, көймә –
атынчык,
Ишкәкләре – гөнаһ, чукынчык!
12
Башта торсын акыл-эшләпә:
Файдаң юкмы? Зыян эшләмә!!!

* * *

Хыялларның чынга ашары бар –
Бу гомернең күпме яшәре?!
Яшәү – яңгыр, коеп ява менә,
Иртән генә чыкты яшәреп.

Соңгы сорау булып бөтерелә
Зәңгәр күктә яшен камчысы:
Туфрактамы ширбәт-дымнар ята,
Үләндәме яңгыр тамчысы?!
Күкрәүләргә ятып китә яңгыр,
Кемдер әйтер: «Китте – бу үлгән...»
Нинди үлем булсын!
Терелә ул,
Тишеп чыкса җирне бер үлән.

Ике сорау

Безгә кадәр яшәгәннәр...
Вакытмы җиңнән тарткан –
Борылып алар караган:
«Кемнәр соң килә арттан?!»
Безнең гомер – чиккә җитәр...
(Хет ела, үкер, илер...)
Күңелләрдә бер ут-сорау:
«Бездән соң кемнәр килер?»
«Кемнәр киткән? Кемнәр килер?..» –
Ике сорау – бүгенгенең
Игезәк балалары.
Әнә шуларга бәйләнгән
Мәңгелек йолалары!

Уйлан, кеше!

(«...сезнең өчен фюрер уйлый...» –
фашистлар сүзе)

Кеше хыялының аркылысын
Космик корабльләр буйламас! –
Уйлагыз сез, төптән уйланырга
Сезнең өчен беркем уйламас.

Юк бәхәссез берни, тик ахмаклык
Бәхәссез һәм кире каккысыз.
Уйлан, Кеше! Хакыйкатьне эзлә!! –
Шуңа уйдан учак яккансың...

«Тираннар да килә һәм китәләр»...
Алар уе сеңми халыкка.
Уйла, Кеше! Яшәвең дә – Ирек,
Фикерең дә калмас коллыкка.

Әзер сүзне ятлап... хәтта этләр
Айга карап көн дә өрерләр.
Уйлан, Кеше! –
Синең өчен кемдер уйлый икән,
Туа Җиргә яңа фюрерлар...

Калыр бары моңнарым...

Беркөн йөрәк туктап,
Тәнем катып,
Күк иленә очса җаннарым –
Ни калыр соң миннән?!
Ниләр калыр??
Калса калыр – бары моңнарым...
Нәрсә соң ул кабер?! –
Өем балчык...
Шундамы соң бар туганнарым?
Миннән дә шул балчык
калыр микән?
Калса калыр
Бары моңнарым...





Марат ӘМИРХАНОВ

ЗӘЙТҮНӘ

(бәян*)

«Чын бәхетледер кулың тоткан колың...»
Габдулла Тукай

Зәйтүнәне барыбер төсләделәр. Иске бишмәткә томалап яткырдылар да, кипкән коры гөмбәне яндырып, җиң аша төтен җибәрделәр.

Иштирәк суы тирәндер, тирә-ягы тирәктер;
Зәйтүнә кебек матур кызлар бу илләрдә сирәктер...

* * *

Көзге көн алтынга манып алгандай кызгылт-сары төскә төренгән иде. Юл буенча тезелешкән яшь усакларга гүя ут капкан: җемелдәпме-җемелдәшәләр. Хәер, барча агач-куаклар да, таш диварлар, каралты-куралар да, хәтта Кабан күле дә нур эчендә йөзә иде.

Җиһан әнә шулай күктә балкыган кояш кочагында назлана. Дөрес, ул инде шактый сүрәнләнгән, шулай да җәйге учагы әле бөтенләй үк суынып бетмәгән. Кызулыгыннан битәр, яктылыгы белән алдыра.

Күктә – елмаюлы кояш, җирдә – яфрак ташкыны.

Зәйтүнә муенына сарылган көзге алтын көнгә аваздаш бизәкле алсу ефәк яулыгын җилфер-җилфер китереп, яфрак җыярга кереште.

– Тапты шөгыль, адә тизрәк, әнине көттермик, – дип, Бәдриҗиһан сеңлесен туктатмак итсә дә, Зәйтүнәнең үз туксаны туксан иде.

– Мөгаллимә апа көн матур чагында гербарийларыгызны өлгертегез дип кисәтте ич, – диде, – үзең дә ишетеп тордың, аннан соң, «адә»ләр, «цицка»лар Чистайда калды, апам, Казанча сөйләшергә сүз куешканны онытма.

Шәмсеҗиһан абыстай чыннан да кызларын капка ачып көтеп тора иде инде.

– Озакладыгыз бүген, – дип каршы алды ул аларны.

– Әнә, төпчегең бит, – диде Бәдриҗиһан, – урамга чыкса, тугарыла тәки...

Ул арада: «Әнием, мин сине фәрештәләр яратуы белән яратам, – дип, Зәйтүнә Шәмсеҗиһанга килеп сарылды, – бик-бик яратам...»

Мондый шайтани назга ничек чыдамак кирәк, Шәмсеҗиһан да балавыздай эреп акты.

– Пескәем-пескәем, пескәем, җан-җанашым...

Зәйтүнә килеш-килбәте, кыяфәте ягыннан әтисенә охшаган иде. Әтисенең ыспайлыгы, чибәрлек вә күркәмлеге тагын да мөкәммәлрәк сыйфатта мөслимәләргә генә хас нәфислек

---

* *Кыскартылып бирелә.*

белән кызына бирелгән иде. Ундүрт яшьтә әлеге сыйфатлар шактый тәгаенләнгән иде инде.

Кызганыч, Хәйдәр останың гомере генә кыска булды. Гаилә дә, ул бакыйга күчкәч, уллары Шакир һәм Габдрахман артыннан Казанга килеп урнашты. Кызлар белем алуны Русско-татарская школда дәвам иттеләр. Казан аларны мәдәни дөньяга язгы ташкындай бөтереп кертте.

Ә Зәйтүнә матур әдәбиятка, шигърияткә мөкиббән. Ул инде шактый каләм ияләрен әсәрләреннән таный. Бигрәк тә Тукай атлысын якын итә. Әле дә әнисе табын хәстәрләгән арада аның тезмәсен авыз эченнән генә көйли-көйли, өстәлдәге яңа басманы кулына алды.

Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап...

Басма «3 нче дәфтәр» дип исемләнгән иде. Авторы – әлеге дә баягы Тукай.

Җәй көнен яздым бераз; язый әле кыш, көзләрен,
Алсу йөзле, кара кашлы, кара күзле кызларын...

– Их, күрәсе иде бу шагыйрьне, – диде Зәйтүнә, – танышасы иде...

– Хыялый, без аңа ни хаҗәтемә, – дип иреннәрен бөрештерде Бәдриҗиһан, – таптың сүз.

Кызларының сүз көрәштерүен әниләре дә колак очында тоткан икән, ул да әңгәмәгә кушылды.

– Алай кистереп әйтмә әле, кызым, – диде Бәдриҗиһанга мөрәҗәгать итеп, – әһле каләм халкы кече күңелле була ул, әнә, Чистайдагы җизнәгез Нәҗип дамелланың агасы Зариф хәзрәтнең Мөхәммәтфатыйх исемле улы да әдип, берәүгә дә караңгы чырай күрсәтмәс, күңеле ак, йөзе күркәм. Сез телгә алган Тукай атлы шагыйрь белән дә таныштыр, мөгаен...

– Мин дә аны Аппаковлар өендә күреп калган идем бит, – дип, Зәйтүнә урыныннан ук сикереп торды, – бик тә ягымлы абый, үзе чибәр...

– Уф, үләм, чибәрлеген дә абайлаган, – диде Бәдриҗиһан, – чит ир-атка күз салмасаң теге...

– Фатыйх абый – безнең кардәш, чит түгел, – диде Зәйтүнә, – беләсең килсә, ул да мине күз уңыннан үткәргән, сеңлесе Фатыймадан кемлегемне белешкән.

– Чыбык очы, туган сиңа, тәтәңнең тәтәсе белән безнең кәҗә тәкәсе...

– Иртәгә берәр йомыш табып, үзләренә барып килермен, сезгә иң элек Мөхәммәтфатыйх белән очрашырга кирәк, – дип, арага янә әниләре керде, – каршы килмәс, шәт, ә сез әзерләнегез, үзегезнең әдәпле вә гыйлемле икәнегезне дәлилләгез.

– Борчылма, әнием, кызларың акны карадан аера белә, йөзеңә кызыллык килмәс, шулай бит, апам? – дип, Зәйтүнә инде Бәдриҗиһанга килеп сырпаланды.

Бу юлы сеңлесенең сырпалануы Бәдриҗиһанга хуш килде, күрәсең, үзе дә чәченнән сыйпап:

– Хак, акыл өләшкәндә абзар артында калганнардан түгел без, – дип, аның сүзен куәтләде.

Чынында исә Фатыйх катына кергәч, икесе тиң каушап төште, ык-мыкка калдылар. Чөнки фырт киеме, ялтыравык шома йөзе, каш өстенә генә эленгән кара кысалы зур күзлеге аны буй җитмәстәй һавалы вә тәкәббер кыяфәттә күрсәтә иде.

Кызларның бу шөбһәле халәтен ул үзе дә бик тиз төшенеп алды. Һәм ярдәмгә ашыкты. Ирен читләре аша гына елмаеп, тын өрә-өрә, сөттәй ак кулъяулыгы белән күзлеген сөрткәләде дә, кемсәләрен шаккаттырып:

– Төпчек агаем Нәҗип хәзрәтнең Бохар мачысы исән-саумы әле? – дип сорады.

Бермәлгә тынлык урнашты. Каршы як стенадагы бизәкле сәгатьнең вакыт санавы аермачык ишетелеп торды.

– Келт-келт, келт-келт...

– Җә, ник дәшмисез, авызыгызга каз мае каптыгызмы әллә, – дип, Фатыйх туташларны сынаулы мут карашы аша үткәрде.

– Мачы сиңа, ул тычканнарны да уйнар өчен генә тота ич, – дип, иң беренче Зәйтүнә пырхылдап көлеп җибәрде, – шаярта-шаярта да, шуның белән шул...

Әңгәмә, ниһаять, үз эзенә төште.

– Белүемчә, сез шагыйрь Тукай иҗатына мөкиббән, аның үзе белән танышырга да теләгегез бар дип ишеттем, бу хакмы? – дип сорады Фатыйх.

– Хак, Фатыйх абый, хак. Тукай белән күрешү безнең иң ихлас уртак хыялыбыз, – диде Зәйтүнә канатланып, – зинһар, булышсагыз иде, зинһар...

– Тукайга сез генә түгел, туганнан туган ике сеңлем дә гашыйк, болай булгач, дүртегезне дә Тукайга тотып бирергә туры килмәгәе әле, – дип көлде Фатыйх, – ә син, Зәйтүнә, дүртенче булырсың, яшь хатын...

– Теләсәгез, ундүртенче итеп, Тукайга гына бирегез...

– Ай-Һай, нәфесең, Чистапулия.

* * *

1908 елның март ае иде.

«Әлислах» редакциясе яныннан үткәндә ачык тәрәзәдән аларны Фатыйх күреп алды.

– Озакламый миңа Тукай килә, дусларыгызда озак тоткарланмагыз, – дип кисәтте.

Чыннан да, эшкә утырырга да өлгермәделәр, Гөлсем туташ килеп керде. Тыны-көне беткән.

– Әйдәң тизрәк, Тукай килде, – дип оран салды.

Аларны Фатыйхның туган энесе Ибраһим көтеп тора иде инде. Алар дигәнебез шул дүртлек инде: Зәйтүнә, Бәдриҗиһан һәм дә Әмирханнарның туганнан туган сеңелләре Гөлсем белән Фатыйма.

– Җә, Аллага тапшырдык, җан шигъри мөслимәләр!

Тартар теленнән табар, ди, тиктормас Зәйтүнәнең авызыннан да вазгыятьне катлауландырып: «Анда тагын кемнәр бар?» – дигән урынсыз сорау очты.

– Фатыйх, Тукай, Вафа Бәхтияр...

Фатыйма да шул сыңар.

– Юк, юк, кермибез, – дип авызын былчайтты, – Вафа әфәнде олы кеше, әйбәт түгел, юк, юк...

Зәйтүнә Ибраһим кулыннан, Гөлсем Зәйтүнә кулыннан, Бәдриҗиһан Гөлсем кулыннан ычкынды, төркем таралды.



Ибраһимның гына авызы ерык.

– Вафа нишләп олы кеше булсын, аның мыегы минекеннән дә кечерәк бит, ышанмасагыз, әйдә, кереп үлчәп карыйбыз, – дип бот чабып көлә.

Зәйтүнәнең дә иреннәренә елмаю кунды.

– Пәй-дәр-пәй, тезелегез минем арттан, керәбез! – дип, вазгыятьне дә үз кулына алды.

Фатыйма тагын сатулашырга керешмәкче иде дә, Ибраһим ирек куймады.

– Бигайбә, туташлар, үкенергә туры килмәгәе, – дип ишек катына атлады.

Зәйтүнә аңа иярде, Гөлсем белән Бәдриҗиһан да кушылды.

Редакциянең зур залы. Урам як тәрәзә каршында бер карават тора. Фатыйх коляскасын читкәрәк куеп, шул караватка утырган, алдында кечерәк кенә өстәл.

Калганнар тирәли урнашкан, гүя догага оеганнар.

– Мәрхәбә, кызлар-йолдызлар, әйдүк-әйдүк, рәхим итегез, – дип каршы алды аларны Фатыйх, – без бик шат...

Аннан соң һәрберсенең исемен атап, дусларына тәкъдим итте.

– Чистапулия кайсыгыз була, – дип кызыксынды Габдулла, күрәсең, ул «Мишәр кызлары» мәкаләсе белән таныш иде.

– Мин, – дип атылып чыкты Зәйтүнә, – апам да...

Тукайның өстендә кара пинжәк, галстук тагылган юллы күлмәк, аягында орчыктай очлы башлы ботинка. Үзе яланбаш, чәче озын да, кыска да түгел, заманча модный тараш.

Тач китаптагы сурәте, дип бәясен дә биреп куйды Зәйтүнә, буй-сыны да күркәм, сакал-мыек та үстерми икән...

Билгеле, ул шагыйрьнең шигырь укуын көтә иде. Ә аларның, ни гаҗәп, дурактан кәрт сугып утырулары. Дөрес, Зәйтүнә үзе дә ярата бу уенны. Кичләрен абыйлары белән еш кына көч сынашалар.

Күренә ки, Тукайның уены бармый. Шуңа бик борчыла, ахры, колодадан кәрт алган саен буш кулы белән чәчен сыпыргалый-сыпыргалый:

– Шул инде, бәхетсез кешегә һәрвакыт кире килеп тора, – дип зарланып-зарланып алгалый.

Зәйтүнәнең йөрәге әрни, ничек бәхетле итәргә соң шагыйрь абыйны? Бу хөсне ниятне ничек тормышка ашырырга?

Юкка гына ниятне ярты гамәл димиләр икән, әмәлен тапты бит, тапты: уенга керергә! Менә күреп торырлар, ул шагыйрьне әлеге сазлыктан тартып чыгарачак.

Адәм сөйли, язмыш көйли, ди, бу уе ярты юлда өзелеп китмәсенме: көтмәгәндә алгы якта әнисенең тавышы ишетелде. Ә алар монда килергә аннан рөхсәт сорамаганнар иде. Апасы белән бер-берсенә карашып алдылар да, парадный ишектән генә чыгып та шылдылар.

Тәүге очрашу әнә шулай уңайсызрак төгәлләнде. Әйе, ул көтелгәнчә булмады, әмма ләкин эзсез калмады, чөнки аралашуга юл ачты. Хәзер Тукай белән танышлар ич инде алар!

Беркөнне Екатеринская урамыннан барганда яннарыннан гына гөрләтеп трамвай узып китте.

– Карагыз, кара, бер фартавый егет кәмәше сезгә карап бәбәген тондырган, үзе аләнчек бәрәндәй башын цайкый, – диде Чистайдан кунакка килгән Рабига апалары, – әллә бер-бер танышыгызмы?

Бәдриҗиһан күзен сирпеп кенә карады да:

– Тукай ич бу, – диде. Аннан шук кына елмаеп әйтте, – мәхәббәт белән ютәлне яшереп булмый бит аны, апа, ул егет кәмәше төпчегебезгә күз салган...

Наянлыкта Зәйтүнә дә өлгер, шундук җавабын да җиткерде:

– Нишләмәк кирәк, һәр Мәҗнүнгә бер Ләйлә, – дип борынын чөйде, – чүлмәгенә күрә капкачы.

Бәдриҗиһан такмакка күчте:

Карар инде, карар инде, карап туялмас инде,
Ни кадәре караса да, ул сиңа булмас инде.

– Борчылма, апаем, без чистапулияләр, үз өлешебезне ятларга бирүчеләр түгел.

– Хак, нәкъ өстенә бастың, – дип хуплады, ниһаять, Бәдриҗиһан сеңлесен, – Фатыйх – миңа, Тукай – сиңа, өлеше барның өмете бар.

Аны Зәйтүнә элеп алды.

Бүген күргән өч егетнең җем-җем итә кигәне,
Фатыйх – алма, Ибрай – хөрмә, Тукай – кура җиләге...

* * *

Бу көнне Шәрык клубына кадимилек-карагруһ тышауларыннан арынган, җәдитчеләр мәйданында үз урыннарын табып, үсеш-тәрәккыяткә омтылучы татар яшьләренең каймагы җыелган иде. Алар милләтнең киләчәген бөтенләй яңача күрә, бөтенләй яңача күзаллый. Иң изге максат – милли асыл сыйфатларга зыян салмыйча татарны мәдәни алгарышлы, сәнәгать вә сәнгатьле, театрлы вә китаплы, саф вә югары үзаңлы дөнья цивилизациясенә чыгару.

Килеш-килбәтләре, киенү ысулары, үз-үзләрен тотышлары да инкыйлабча.

Егетләр ауропача тегелгән бериш ыспай кара костюм-чалбардан, аякларында – штиблет. Башларындагы кара кәләпүшләре дә шушы фасонга туры килеп тора. Нәкъ бал-маскарад кавалерлары.

Ә туташлар? Гүя очарга талпынган гүзәл аккошлар. Үкчәләренә кадәр сузылып төшкән нечкә билле озын ак күлмәк, ак калфак аларны серле вә әкияти хөсне җамал итеп күрсәтә иде.

Зәйтүнә генә башкалардан аерылып тора. Дөрес, аның да күлмәге ак, ә менә кызыл хәтфә калфагы кичә кагыйдәсенә туры килми. Башта хафага төшкән иде дә, шөкер, сүз әйтүче булмады.

Кызыл төс исә аңа бик тә килешле иде, гүя тәрәзә төбендәге шау чәчәкле тамчы гөл, менә-менә тамып китәр төсле. Хәер, үзе дә дастаннардагыча алтын егач – тутый кош: карлыгач канатыдай сызылып киткән кара каш, нурлы йөз, гөләндәм буй. Шуңа күрә игътибар үзәгендә: кемнәрдер сокланып, кемнәрдер көнләшеп карый.


Рәсем: Наталья Васильева

– Сак бул, урлап китмәгәйләре, күр, бөтен егетләрнең күзе синдә, – дип бармак янады Фатыйх.

– Беләсез ич инде, Фатыйх абый, миңа Тукайдан башка кеше кирәкми, – дип шаяртты үз чиратында Зәйтүнә.

Ул арада кичә дә башланып китте. Алып баручы сәхнәгә Тукайны чакырды. Ул да башкалар кебек үк киенгән, кулында бөтәрләп тоткан бер кәгазь дә бар иде.

Сәхнәдән озын буйлы, мәһабәт буй-сынлы, төшләренә кереп тә Зөләйха кебек тәкәббер шаһинәләрнең һушын алырдай әфзали зат булып күренә иде Тукай, һәрхәлдә, кызга шулай тоелды. Ә шигыре – әнтә нурүн, фәдка нур! Ниһаять хыялы тормышка ашты, Тукайның үз авызыннан шигырь укуын ишетте.

Бу «Утырышу» шигыре иде.

Кайвакытта кара күзле, кара кашлы
Матур берлә утырамын кара-каршы...

Антракт игълан ителүгә, Зәйтүнә тиз генә конфетти сатып алды да, сәхнә ишеге янына барып басты. Тукай күренүгә, учына мул итеп алып, аңа конфетти сипте.

Шагыйрьнең чәче, кәләпүше, киемнәре аллы-гөлле матур кәгазь кисәкләре белән бизәлде.

– Минем кебек шайтан таягын да чәчәккә әйләндердегез, – дип көлде Габдулла, – рәхмәт...

Зәйтүнә аны тыңлап бетермәде, җитәкләп алды да, кеше арасыннан читкәрәк алып чыкты.

– Әһле әдиәбанә муаффәкыятегез белән ихлас күңелдән котлыйм, – диде, – шигырегез искиткеч тәэсирле, бик самими интонация белән укыдыгыз...

– Рәхмәт...

Залда музыка танцы көйләрен уйный, яшь-җилкенчәк бөтерелепме-бөтерелә. Кызларның күкрәгендә – чәчәк, егетләр бантлар таккан. Югарыдан кәгазь тасмалар төшерәләр дә, барча катнашучылар бергә серпантинга бәйләнеп биилəр. Бик матур тамаша.

– Сез танцевать итмисезме? – дип сорады Габдулла әлеге тамашаны күзеннән кичереп, – Әллә теләмисезме?

– Әле дәресләр генә ала башладым, өйрәнгәч, сезнең белән генә танцевать итәргә телим, – диде Зәйтүнә җиңелчә елмаю аша, – бергә танцевать итәрбез, яме?

– Сүз бирәм, өйрәнгәч, мин дә фәкать сезнең белән генә танцевать итәрмен.

– Килештек, алайса, безгә бер-беребезгә якыная тору фарыздыр, мөгаен, – диде Зәйтүнә шул ук шаярулы кимәлдә, – бәлкем кичәдән дә бергә кайтырбыз?

Ул яфрак өстендәге иртәнге чык тамчысыдай мөлдерәмә саф-чиста күзләре белән егеткә төбәлде.

Тегесе бу самими караштан җебеп төште, бермәлгә хәтта тел куәсен дә югалтып торды.

– Гафу, кичерегез, зинһар өчен, мин шундый күңел йөдәткеч зат инде...

Егет, аңына килеп, юк, юк, Аллам сакласын, нинди йөдәткеч дигәндәй, кулларын буташтырып алды да:

– Бу кулай тәкъдим, туташ, мин... ни... риза... бик рәхәтләнеп, – диде.



Тик кичәдән соң Зәйтүнә аны көтеп ала алмады. Сөмсере коелды чибәркәйнең. Әле генә бөтен җиһанны кочагында тоткандай шатлык-куаныч дәрьясында хозурлык кичерә иде ләбаса...

Яше белән бергә бу шатлык-куанычлар да мизгел эчендә юылып төште. Йөдәткеч кенә түгел, барып җитмәгән нәрсә ул, аңгыра бәрән. Тукай кебек зур шагыйрь ниндидер ярлы мишәр кызына карый димени?! Янында, әнә, энәдән-җептән генә киенгән күпме кызыл иренле бай хәтимәләр бөтерелә. Ә ул, җүләрнең җүләре, шигырь укыганда аннан күзен алмавын чынга исәпләп, кыз башы белән кулларыннан тотып сөйләште бит әле. Җитмәсә, танцы турындагы мәгънәсез буш гәп... Ояты ни тора...

Тукай исә бу вакытта күптәннән күңел түрендә йөрткән бер шигыренә капылт кына яңа аһәң табуына дәртләнеп, аулакта авыз эченнән шуны көйләп куана иде.

Күңелемдә көн һаман аяз – һаман да яз,
Шагыйрь күңелендә кыш булмый да кар яумый...

Бәгъзеләр аның бу сәер гадәтен, ялгызлыкны хубрак күрүен сырхавы, күзендәге зәгыйфьлегенә ишарә итеп аңлаталар иде.

Күн-фәйәкүн! Бу дөреслеккә туры килми. Аллаһы Тәгалә Габдуллаҗанга туганда ук ятимлек, кагылу-сугылулар аша бөекләр генә ирешә ала торган илаһи ирек тә насыйп иткән иде. Ул хәзерендә шул ирек хозурында. Шундый пәйгамбәри югарылыкка күтәрелгән иде ки, ничек яшәргә теләсә, шулай яши. Тәхете дә, бәхете дә – ирек!

Ирек – чын шагыйрьнең мәңгелек юлдашы ул.

Акрын-акрын Зәйтүнә дә тынычланды. Кешегә сагыз кебек ябышырга ярамый ич инде, дип, Тукай белән күрешү җаен эзләүләрдән дә туктады.

Шулай да араны уптым-илаһи гына өзеп тә булмый ич әле. Зәйтүнә әлеге кичәгә кадәр үк «Ак юл» балалар журналы мөхәррире Фәхрелислам Агиевтан Тукайның «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» исемле шигырен табып бирүен үтенгән иде. Ул, күрәсең, бу хакта авторның үзе белән дә сөйләшкән булган, һәм, һич көтмәгәндә, әлеге шигырьне Зәйтүнәгә Тукай үзе җибәрде.

Аралашуга янә юл ачылды. Тик озакка түгел. Шәмсеҗиһан, җәй җитүгә, кызларын алып Чистаена кайтып китәргә әзерләнә башлады.

– Укуыгыз әрәм була күрмәсен берүк, – диде Тукай бу хәбәрне ишеткәч, – милләт сезнең кебек алгарышка омтылучы гыйлем иясе мөслимәләргә бик мохтаҗ.

– Рәхмәт, бу югары бәягезгә үзегезнең шигъри юлларыгыз белән җавап бирү урынлы булырдыр, мөгаен:

Укы, яз, бел, тырыш син,
и мокаддәс яртыбыз безнең!
Кеше булмак өчен иң-иң беренче шартыбыз безнең!

– Вәгъдә – иман, мин үзем шәхсән белем эстәвемне дәвам итәчәкмен, – диде Зәйтүнә.

– Шатландырдың, Зәйтүнә, күңелем буалары ерылып китте...

Йөрәктән чыккан сүз йөрәккә сары майдай сарыла бит ул, әүвәл Зәйтүнә сискәнеп куйды, аннан эчетышы язгы ташкындай шатлык-куаныч белән тулышты. Чөнки егетнең аңа тәү тапкыр Зәйтүнә дип, исеме белән мөрәҗәгать итүе иде.

– Чистай ерак җир түгел, Аллаһы боерса, аралашып торырбыз, – дип, киләсе очрашуларга күпер салырга да өлгерде үзе, – шулай бит, Габдулла абый?!

– Мин бик хуш булыр идем, Зәйтүнә...

Тукай аларны фуражкасын селки-селки озатып калды.

* * *

Чистайга кайтып урнашуга, Шәмсеҗиһаннар йортын балга сарылган чебеннәр кебек яучы-димчеләр сырып алды: берсе килә, икенчесе китә, бирмәсәләр – бирмәсләр, сандыкка да салып куймаслар, имеш. Шулай булмыйча, кызлары нинди бит: үзләре чибәр, үзләре эшчән, үзләре гыйлемле, ырулары затлы, алтын бәһасе.

Җиткән кыз – киткән кыз, ди, артык сайлансаң, утырып калулары да ихтимал, чәчәкне вакытында өзү мәслихәт, һәм, ниһаять, әни кеше Бәдриҗиһанга фатихасын бирде. Ике туйны бергә ясыйк, дип, төпчегенә дә нәфсе сузганнар иде сузуын, бусы яшь әле, үземнең дә ялгыз каласым килми, дип анысына ризалашмады.

Зәйтүнә кышын Курсабаш авылында яңа ачылган җәдид мәктәбендә балалар укытты. Эшен ошатты, әмма әлеге белем халәте аның үзен һич тә канәгатьләндерми иде. Тукайга биргән вәгъдәсенә туры калып, Иж-Бубый мәктәбенә укырга китү хәстәрен дә күрә башлады.

Ләкин... Уналты яше тулган кыз энә очында бии бит ул. Аны янә, тын алырга да ирек бирмичә, кияүгә димләргә тотындылар, сәгате сукты, янәсе. Әнисен дә үз якларына аударганнар.

Уналтыда кыз – солтан, – дип ул да яучылар сүзен куәтләде, – китап та багардай вакытта урнашып калуны хуп күрә.

Зәйтүнә, чыннан да, мәмрәп пешкән анар җимешедәй тулышты, нәкъ риваятьтәгечә: яулыгын кыя салып, күргәннең исен алып, хур кызыдай балкыды. Акылзиһене, дөньяга карашы да яңа, үзгәреш дулкынында тәгаенләнде.

– Әнием, мең-мең рәхмәт, карадың, үстердең, – диде Зәйтүнә, – тик әле минем укуымны дәвам итәсем, милләтемә файда китерердәй гыйлем иясе буласым килә, гаиләмне дә яраткан кешем белән корырмын, Аллаһы боерса...

Бәхәскә абыйлары да кушылды, әниләренә: «Зәйтүнәне көчләү булмасын», – дип кисәтеп, хат юлладылар. Шуннан соң гына ярәшү хәлләре тынып калды.

Инде, әнә, мең тугыз йөз унынчы елның җәе дә җитте. Җир-Ананы ялкынлы аҗаганнары белән иркәли-иркәли күкрәүле яңгырлар явып узды. Җиһан яшеллеккә күмелде. Карап туймаслык чәчәкле-чуклы, аллы-гөлле яшеллек.

Зәйтүнә шушы нәфисәи матурлыкны ачык тәрәзәдән күзәтә-күзәтә чигү чигә. Нәфис бармакларына күз ияр-

ми, ак тастар өстендә болын манзарасын хәтерләтеп, бер-бер артлы әле күксел-кызыл күкчәчәк тәлгәшләре, әле акбаш чәчәгенең таҗ яфраклары, әле кыңгырау чәчәкнең асылмалы нәзберек бүрекчекләре пәйда була...

Шул вакыт капка төбендә үткән-сүткәнгә сүз кушудан тәм табып утыручы тау асты Мәрьям урыныннан купты да:

– Зәйтүнә, каршы ал, сезгә кунаклар килә, – дип хәбәр салды.

Күп тә үтми, рөхсәт сорап, өйгә кардәше Ибраһим белән бер чит кеше килеп керде.

– Таныш бул, «Сәйяр» труппасы җитәкчесе режиссер Габдулла Кариев, – дип тәкъдим итте Ибраһим әлеге кунакны.

Зәйтүнә аны Казан чорыннан ук ишетеп белә иде. Уртача буйлы, акыллы йөзле, мөлаем карашлы күркәм егет икән. Өстендә килешле кара костюм, утыртма якалы ак күлмәк, аңа күбәләк-галстук беркетелгән, әлбәттә инде, штиблетлар... Әйтерең бармы, коеп куйган артист.

Нәкъ Тукай, дигән уй йөгереп узды кызның башыннан, ошашканнар да... Хәер, икесе тиң Габдулла лабаса!

– Казан егетләрен утлы гыйшык учагына салган гүзәл кыз Зәйтүнә Чистапулия белән танышуыма ихлас шатмын, – дип артистларча йөгнәде Кариев, – шушы секундтан үзем дә әлеге бичара мәгъшуклар сафына басам, каршы килмәссезме?

– Тәртибегез ничек булыр бит? – дип Зәйтүнә дә шаярулы мөгамәләне кабул итте.

Тәртибемә тел-теш тигезмәле түгел, туташ, менә хәзер ике дә уйлап тормастан аяк астыгызга йөгәнәм...

– О-о, әфәндем, миңа аяк астындагылар түгел, кыю, тәвәккәл, горур егетләр ошый төшә шул, – дип бүлде аны Зәйтүнә, – бигайбә...

– Спектакль кую өчен бер хатын-кызлары җитми аларның, сиңа да шул үтенеч белән килдек, – дип, Ибраһим әңгәмәне җитди юнәлешкә борып җибәрде.

– «Яшь хатын» драмасында карт хатын ролен башкару турында сүз бара, – диде режиссер елмаебрак, – сезгә өметебез бик зур.

– Ә яшь хатынны кем уйный?

– Актрисабыз Сәхибҗамал Гыйззәтуллина, – диде Кариев, – ул сезгә дә ролегезнең асылына төшенергә булышыр, бик зур талант иясе.

Сәләтең булган кимәлдә дә, берничә репетиция белән генә артистлык һөнәрен үзләштерү мөмкин түгел, әлбәттә. Шулай да, Сәхибҗамал Зәйтүнәнең тәүге чирканчыгыннан риза-бәхил калды.

Кариев Зәйтүнәне озата килде.

– Сезгә җиткерәсе әманәтем бар, икәүдән-икәү генә сөйләшә алырбыз бит? – диде.

– Һичшиксез.

Әүвәл тәмләп чәй эчтеләр, спектакль турында фикер алыштылар. Режиссер кала тамашачыларының әдәплелегенә соклануын да белдерде.

– Ә әманәт? – дип, Зәйтүнә кунакның күзләренә текәлеп бакты, – алдан котыртып куйдыгыз да, инде менә түземлегем тәмам төкәнде...

Кариев күз карашы белән генә елмаеп куйды да:

– Тукайның сезгә багышлаган шигырьләрен күргәнегез бармы? – дип сорады.

– Юк, кайсы шигыре минем хакта? – дип сораугa сорау юллады Зәйтүнә, – белмим... юк... – Фаразан, менә бу «...гә» шигыре.

Очраган юлда, сине күргән, иелгән ул бүген;
Ул шуңар да шатлана бит: чын җүләр түгел диген!
Күргәнең бармы әле Коръәндәге мәдхияни?..

– О-о, шагыйрьнең «гә»ләре сансыз-хисапсыздыр, мөгаен, мин бит – Зәйтүнә.

Кариев янә күз очлары белән елмаеп, тәфсилләде:

– Тукай әлеге шигырен иң элек миңа укып күрсәтте, ничек уйлыйсың, бу кем турында, дип сорады. Ә мин, туташ, Коръән-хафиз, сезне белмәсәм дә, Зәйтүнә исемле берәр чибәркәй турындадыр инде, дидем. Ник дисәң, ул игътибарны Коръән-Кәримгә юнәлтә, ә Коръәннең «Нур» сүрәсендәге 35 нче аятендә Зәйтүн агачы телгә алына. Шагыйрь сезгә мөнәсәбәтендә дөньяга нур сибүче зәйтүн мае балкышын образ итеп файдаланган. Шул рәвешле «гә» «Зәйтүнәгә» әверелә дә куя. Бу яшерен мәхәббәтнең серенә, шәт, төшенгәнсездер?!

– Ә әманәт?

– Әманәт тагын бер кире каккысыз дәлил, туташ, Тукай сезгә күптин-күп сәлам юллады, бәлкем әле, без калада вакытта, үзе дә монда килеп чыгар, шундыйрак нияте бар.

– Алдакчы ул сезнең Тукаегыз, сүзендә тормый, – диде Зәйтүнә уены-чыны белән. Ә үзенең тавышында зеңләп, сагыш яңгырап китте.

Кариев хәлне төзәтергә ашыкты.

Җир яшәрмәс, гөл ачылмас – төшми яңгыр тамчысы;
Кайдан алсын шигъре шагыйрь булмаса илһамчысы...

Ул кесәсеннән дустының үзенә бүләк итеп биргән фоторәсемен алды да, «Һәдиядән Һәдия» дип язып, Зәйтүнәгә бирде.

* * *

«Сәйяр» хушлашты, Тукай килмәде, көз җитүгә, Зәйтүнә үзе дә Курсабашка укытырга китте. Әйе, бу тормышта һәркемнең үз юлы, үз урыны, үз вазыйфасы, һәм кемсә аларны үзе сайлый. Бу аңа Күкләр тарафыннан бирелгән ирек. Ләкин инсан Тәкъдир дәфтәрен үзгәртү көченә ия түгел. Урман-кырлар, басу-яланнар, таш-таулар аша үтә-үтә дәрьяга койган елгалар кебек әлеге ирек тә иртәме-соңмы барыбер Тәкъдир дәфтәрендә теркәлгән язмыш капкасына килеп терәлә.

Зәйтүнә дә, күп уйланулардан соң, Тукай белән ике арадагы мөнәсәбәтләрнең яшьлек мавыгуы гына булуы белән килешкән иде инде.

Һәм көтмәгәндә (янә көтмәгәндә!) Чистайдагы якын туганының хаты аның әүвәлге уй-хыялларын уалган пыяладай чәлпәрәмә китереп туздырып ташламасынмы. Шулай булмыйча, анда: «Фатыйх абый сине Тукаевка димләп хат язган. Без: «Үзенә яз», – дип адресыңны җибәрдек», – дигән йөрәгенә якын җөмлә бар иде.



Шуннан соң озак та үтми Курсабашка Фатыйхның үзеннән дә хат килеп төште. Хат шактый озын иде, хатирәләргә уралган иде. Хәтта «Пескәем-пескәем» уенын да искә алып: «Кулларыңның сугылудан кызаруы беттеме әле?» – дип тә шаяртып белешкән иде.

Һәм иң сәере – Вафа Бәхтияровның Зәйтүнәне үзенә соратырга булган нияте турында хәбәр иткән иде. Хатның бер почмагына: «Тукай да сине онытмый», – дип тә өстәгән.

Зәйтүнә коелып төште, башы катты, кәефе кырылды, ике-өч көн күзенә йокы кермәде. Чөнки мондый эчтәлекле хат көтмәгән иде ул.

Их Фатыйх абый, Фатыйх абый, мөселман кызы – мыскылга салынмаган ак ефәк бит ул, гафифәнә вә мәгъсуманә зат, аны шулай кимсетергә ярыймы соң? Ә син, һич тә кыенсынмыйча, алдын-артын уйламыйча, икеле-микеле тәкъдимле хатлар юллыйсың? Болай каты бәгырьле түгел идең ич син, Фатыйх абый?!

Зәйтүнә җавап язмады. Ә көзен яучы-димчеләрне тынычлыкта калдырып, узганнар белән, ниһаять, араны тәмам өзеп, Иж-Бубый кызлар мәктәбенә укырга китте. Ике ел күзгә-башка күренми, бар булган вакытын, тырышлыгын гыйлем алуга багышлады.

Зәйтүнә Казанга уникенче елның җәендә генә килә алды. Ул Тукайның хастасыннан хәбәрдар иде инде, янына ашыкты.

Ниндидер һич тә җәйгә хас булмаганча салкынча бер сытык көн иде. Күкне оеш-оеш кара кучкыллы болыт каплаган, менә сытылам, менә сытылам дип кенә тора. Ара-тирә эре тамчыларын җиргә сибештергәләп тә куя үзе. Яуса яумый, аязса аязмый, тик күңелгә тиеп тора.

Хәер, көн генәме, кешеләр, йортлар, агач-куаклар – барысы-барысы да сырхаулы сәер халәттә иде. Әнә, трамвае да, гомер булмаганны, ташбака тизлеге белән бара. Зәйтүнә түзә алмады, төшеп калды.

Йөгерә-йөгерә атлаганда чак кына күптәнге танышы Фәхреислам Агиев белән чәкешмәде.

– Кая болай ашыгасыз? – дип сорады тегесе, – бәреп ега яздыгыз бит.

– Тукай янына, – диде Зәйтүнә, гыжылдаулы сулышын көч-хәл белән басып, – хәлен белергә барам.

– Минем шуннан чыгышым, сез анда кермәгез, – диде танышы ялварулы кыяфәттә.

– Ничек инде, минем аны күрәсем, хәлен беләсем килә...

– Туташ, зинһар, кермәгез, әгәр Тукайны сөйсәгез, кермәгез, һәлак итәрсез аны, дөрес аңлагыз мине, зинһар...

Зәйтүнә Тукай дигән мөкатдәс хөрмәт иясе хакына илаһи теләк-омтылышларын корбан итеп, яшьләрен агыза-агыза, ниһаять, коеп ява башлаган күкрәүле яңгырга күмелгән шәһәр диварлары арасына кереп югалды.

...Тукайның вафаты турында ишетүгә, янә Казанга җыйналды. Пароходтан төшүгә, туры зиратка килде. Бу юлы аны туктатучы булмады.

Табигатьнең шатлык вә куаныч белән тулы мәле. Җиһан, күк капусы ачылгандай якты, нурлы, тыныч. Яфракларда тамчы җил юк.

Ә Тукай, иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун, гүрдә. Кабере өстендәге туфрагы әле кипшенергә дә өлгермәгән. Гап-гади кабер. «Шагыйрь Габдулла Тукаев» дип язылган калай кисәге генә аның җәсәде монда җирләнгәнен күрсәтеп тора.

Зәйтүнә кыйбла ягына карап, авыз эченнән генә озаклап Хәтем догасын укыды да теләкләрен юллады.

– Раббым, мәрхүм Мөхәммәтгариф улы Габдуллаҗанның рухларын шат кылып, гөнаһларын ярлыкасаң иде. Коръән һәм Тәүхид нурлары белән каберен нурлы кылсаң иде. Ярабби...

Фатыйх белән күрешкәнче аңа тынычланырга кирәк иде. Шуңа күрә Яңа бистәдән Арча кырына кадәр җәяүләп килде.

Фатыйх аңа ничектер олыгаеп киткән төсле күренде. Шалкандай шома йөзе купшакланган, зәгъфрандай саргаебрак тора. Тулы калын иреннәре дә үзенекенә охшамаган, гүя тыны чыгарылган каз куыгы.

– Фатыйх абый, чыраең качкан, авырмыйсыңдыр бит? – дип сорады Зәйтүнә хәл-әхвәл белешкәч.

Бу дуамал сорау иде, әлбәттә. Фатир хуҗасына да ошамады. Алар арасында кискен борылышлы чәкешү булып алды.

– Тукай үлде, – диде Фатыйх.

– Шулай икән шул, нигә үтердегез? – диде Зәйтүнә.

– Мин синнән сорыйм, нигә үтердең? – диде Фатыйх.

– Алып калырга янында түгел идем, – диде Зәйтүнә.

– Ә нигә янында түгел идең? – диде Фатыйх.

– Сөйләп-сөйләп тә димли белмәдегез ич, – диде Зәйтүнә.

Шуннан соң тынып калдылар. Сәгать суккан тавыш кына бу тынлыкка әрнүле аһәң өсти иде.

Беренче булып Фатыйх телгә килде. Ул инде үзен кулга алган иде. Тавышы да йомшарган.

– Мин сине Тукайга соратып Чистайга хат язган идем, ә аннан отказ килде, – диде, – Тукайның сырхавы комачаулады, ахры...

– Вафа Бәхтияров белән буташтырасыз түгелме?

– Юк, сеңлем, анысы аның әлеге отказдан соң булган хәл. Син бит Казанда бик абруйлы кәләш идең, күз дә каш урынына күрәләр иде...

– Йәә Гафуру, йәә Аллаһ, ни үкенеч... И әнием...

– Валлаһе әгъләм биссәваб, Тукай сине бик ярата иде, – дип дәвам итте Фатыйх, – аны син генә коткарып кала ала идең...

Зәйтүнә, гүя зилзиләле тойгы дәрьясында күбәләктәй талпынып очкан сагыш йомарламы, хисләре ташып чыкты:

– Габдуллаҗан... Мәҗнүнем минем...

27 ПИРАМИДА ОКТЯБРЯ 17:00

#ҖАНЛЫКОНЦЕРТ



ТУРЫ ЭФИР

ВЕДУЩИЕ: ГУЛЬНАЗ САФАРОВА, АЙВАЗ САДЫЙРОВ, АЙСЫЛУ ЛЕРОН, РАМИЛЬ ШАРАФИЕВ

ЭЛВИН ГРЕЙ, АЙДАР ГАЛИМОВ, ГУЗЕЛЬ УРАЗОВА, ФИЛЮС КАГИРОВ,
АНВАР НУРГАЛИЕВ, ЭЛЬМИРА КАЛИМУЛЛИНА, ХАМДҮНА ТИМЕРГАЛИЕВА, ИЛЬХАМ ШАРИФ,
АЛСУ АБУЛЬХАНОВА, ИЛЬСАФ, БУЛАТ НИГМАТУЛЛИН, ЛАНДЫШ НИГМАТЗЯНОВА
РАДИК ЯРУЛЛИН-АЙРАТ САФИН, МИНДИЯР ШАЙМАРДАНОВ, РАМИЛЬ АЙМЕТДИНОВ
ИЛЬДАР АХМЕТОВ, АЙГУЛЬ РАХИМОВА, САЛАВАТ МИННЕХАНОВ - ГҮЗАЛЕМ, АЙЛИН
ЧЭЧКЭ, РАМИЛЬ ГАЛИМЗЯНОВ, ЭЛЬМИРА СУЛЕЙМАНОВА, АЛИНА ДАУТОВА, ЛЯЙСӘН ГИМАЕВА

Организаторы





TATAR RADIOSI
сеть радиостанций



ВСЕ БИЛЕТЫ KASSIR.RU


297-43-77

Бренд-партнер



6+

РЕКЛАМА



Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Көне буе телефон шалтырауларына, интернеттан килгән кыска һәм озын хатларга ияләшеп барабыз. Кайчак барысына җавап бирергә өлгерми дә калабыз, онытып та куябыз. Ә менә бер шалтыратуны гомердә дә онытасым юк.

– Син исәнме ул? – элекке хезмәттәшемнең куркып кына дәшүе сискәндереп җибәрде.

– Исән идем әле, – дим, – ачуланмасаң...

– Мәктәп директоры белән урынбасары синең номерны эзли, алыштыргансың ахры. Син үлгән дигән хәбәр килгән, – дип әйтеп ташламасынмы...

Эсселе-суыклы булып киттем. Үләргә һич исәп юк иде югыйсә. Яңа гына бик яхшы итеп дәваланып алдым, шифаханәдә дә булып кайттым. «Кайдан чыкты икән бу сүз?» – дип уйлап бетерүем булды, телефон шалтырый башлады. Түзеп кенә тор! Исән булуымны белгәч, китте бер-бер артлы явып сөенечләр, шатлыклар! Баксаң, миннән дә яхшырак кеше юк икән һәм булмаячак та ди әле! Төрле яклап идеаль кеше булуыма үзем дә ышана башладым. Әмма ләкин кыенсынып куйдым: танышларым кызганып беткәч кенә, исән икәнлегем турында хәбәр тарала, имеш. Кызык, араларында: «Шулай булса, шәп булыр иде!» – диюче булдымы икән? Булмый калмас, гомер буе дошманнарсыз гына яшәп тә, лаеклы ялга чыкач, аларның бөтенләй юк түгеллеге беленде.

Сүз башы кайдан китүе тиз ачыкланды: интернет галәмәте. Улымның контакттагы сәхифәсен ватып, бар танышларына: «Иртән әнием инсульттан вафат булды, ярдәм итегез», – дип хәбәр салганнар. Акча күчерү өчен карта номерын да күрсәткәннәр. Хәтта үземә дә юлларга онытмаганнар. Иманда икән чикләвек! Мошенниклар акча табуның яңа бер ысулын уйлап тапкан икән. Имеш, мине күмү өчен балаларым аптырап калмасын. Танышлар кызганыр, анысы, ләкин бу тозакка кем генә эләгер икән? Интернет кешеләрне куша да, аера да, үтерә дә диюләре чындыр, күрәсең...

Миннән соң, улыма шалтырата башладылар. «Ун еллап аралашмаган дусларга кадәр хәлемне белде. Борчыла барысы да», – ди үзе, ни шатланырга, ни кайгырырга белми. Бар да ышанган бит. Бездә шулай: беренче ике сүзне ишетсәләр, калганын тыңлап тормыйлар.

Әлеге дә баягы интернеттан карыйм: нәрсәгә юрарга соң бу хәлне? Озак яшәргә дигәнне күп тапкырлар ишеткән булды инде. Киресе дә очрый икән. Бер кыз хастаханәдә ятканда әти-әнисенә аның үлеме турында хәбәр итәләр. Якыннары төн буе хәер әзерли, азык-төлек ала. Иртән барсалар – кызлары исән. Икенче кеше белән бутаганнар! Кичкә ул кызның кинәт кенә үлүе турында чын хәбәр килеп ирешә. Монысы инде, кызганыч, ялган булмый.

Боларны ишеткәч, мин дә берике көн куркыбрак йөрдем.

Районда Тукай һәйкәле ачасылар иде – анда да бармадым. Улымны иярттем дә зиратка киттем. Үлә калсам, урын калдымы икән, дип түгел, якыннарымның каберен караштырып, чүп үләннәрен утап кайтырга дип уйладым. Рәнҗеп ятмасыннар, без дә шунда барасы бит! Әстәгъфирулла, бу арада гел шул турыда уйландыра. Шәһәрдә матур җирләрдә фотога төшеп, дусларыма җибәргәч, «Син кайда булдың?» – дигәнгә: «Оҗмахта», – дип җавап биргән булган идем. Болай сөйләнергә ярамый, күрәсең!

Иң ахырда ерак районнан кодагый шалтырата: «И кодагый, исәнсең икән әле. Бигрәкләр кайгырдым. Икегезгә дә шалтыратам, телефонны алмыйсыз гына бит. Елаплар беттем. Эштә тынычландыру дарулары эчереп, ушка китерделәр. Исән булыйк әле, кодагый, без бит әле балаларга, оныкларга кирәк!» – ди.

Әйе шул! Әле бит алтмышка да җитмәгән! Йөз планнарым, мең эшләрем бар, аны миннән башка

кем эшләр? Юк, юк, үлмибез әле, яшибез. Кайда ул?!

Әлфия ШӘЙХЛИСЛАМОВА.
Туймазы районы,
Кандра авылы.

Яши-яши бер нәрсәгә ныграк инана барам: авылда халык ихлас, ярдәмчел һәм кешелеклерәк. Табигатькә якынрак булу белән аңлатыла микән бу, авылның артык зур булмаган җәмгыятендә бер-береңә ярдәм итми яшәп булмавы беләнме?..

Без хәзер елның яртысын шәһәрдә яшәп, яртысын Кама Тамагы районының Каратай (Уразлино) авылында яшибез. Үзебезчә йорт җиткезеп киләбез. Җәйләребез хәзер шунда – Кама белән Идел кушылган төбәктә – Тау ягы дигән матур табигать кочагында уза. Авылның үз рәхәтлекләрен дә, иртә таңнан торып җиң сызганып эшләргә кирәген дә язуым түгел, мине иң сокландырганы – авыл халкының тырышлыгы, булдыклылыгы.

Тырыш, уңган хуҗалар яшәгәнен йортлары, капка-коймалары әллә каян әйтеп тора. Авылларда да йортларны бик матур, иркен итеп салырга тырышалар хәзер. Сулар да краннан гына ага... Утын әзерләп тә мәшәкатьләнәсе юк, авыллар инде күптәннән зәңгәр ягулыкта. Өйләр генә түгел, күпләрнең мунчалары да газ белән җылытыла. Әле кайчан гына авыл урамнарына коры көндә генә кереп була иде, хәзер урам-тыкрыкларга таш түшәлгән. Рәхәтләнеп яшә генә! Әмма авылда калучы яшьләр генә сирәк. Эшләргә эш булмау яшьләрне читкә китәргә мәҗбүр итә бугай. Авылда үз көченә бик ышанганнар, авыр эштән курыкмаганнары гына каладыр.

Бүгенге авылдашларым, танышларым – нәкъ менә шундыйлар. Мал-туар тотучылар сирәгәйсә дә, бакчасын тутырып яшелчәсен, җиләк-җимешен, матур-матур хуш исле гөл-чәчәкләр үстерүче, тавык-чебеш, каз-үрдәк үрчетүчеләр күп әле авылларда. Аерата уңганнарның бал кортлары да бар. Умарта тотучыларга гомер-гомергә сокланып караганнар. Теләсә кемнең кулыннан килердәй шөгыль түгел бит ул. Бал кортын бик чиста, сабыр, түзем кеше генә карый ала. Бал үзе дә иң кадерле, затлы тәгамнәрдән санала. Шуңа да балчылар авылда бер-ике генә була.

Шундыйларның берсе – Олы Бортас авылыннан ахирәтем Фидалиянең җизнәсе Вәлиев Фәрит абый да бик оста балчы. Гомере буе «Искра» колхозының алдынгы шоферы булып дан тоткан кеше ул. Аның умартачы булып китүенә берничә ел гына әле. Бик тә тырыш, уңган-булган, дөньяның ямен, тәмен белеп яши алар хатыны Дания апа белән. Туганнарын, дусларын бер елны да хуш исле балларыннан авыз иттермичә калдырмыйлар.

«Бал ару, җитмеш төрле авыруга дару», – дип, халык мәкале белән әйтергә яраткан авылдашыбыз Әхмәтев Халит тә әтисеннән калган умарта кортларын таратмыйча, аның төсе итеп яратып, чын күңелен биреп, тиешле хасиятен күрсәтә белә. Яңа бал суырткач, яшьлек дустым дип, ул да бал белән сыйламый калмый. Һәр елны шулай – тырыш хезмәте белән тапканыннан туганнарына, күршеләренә дә өлеш чыгара.

Шушы авылның тагын бер мөхтәрәм агае – Әлфит абый, безне шаккаттырып: «Быел балым күп булды, яхшы кешеләрне сыйлыйсым килә», – дип, гәрәбәдәй сапсары, хуш исле, бик тә тәмле бал кертеп чыкты. Бер безгә генә түгел, башка авылдашларын да ел саен яңа аерткан бал белән сыйлый икән ул шулай. Равия апа белән Әлфит абый Хәбибуллиннар – авылның үрнәк гаиләсе. Заманында «Кама» колхозының алдынгы механизаторы булып тырыш хезмәт куйган ул. Авырлыкны да күп күргән алар, ләкин беркайчан да уфтанып, зарланып йөргәннәре юк. Умартачылык белән дә күптәннән шөгыльләнәләр дип беләм. Гомумән, нәрсәгә тотынса, шуңа кулы ята торган кеше ул Әлфит абый.

Авыл халкына гына хас юмартлык, эчкерсезлек, күрше хакын хаклый белү, авылдаш, дус дип якын итү үрнәге инде бу. Табигатьнең үзе кебек юмарт та, чиста да, ихлас та бит ул авыл кешесе!

Фирдәвес ИСМӘГЫЙЛЕВА.
Кама Тамагы районы,
Каратай авылы.

Уйламаган җирдән генә кулыма «Сөембикә» журналы килеп керде. Бәхетемә, дим мин аны. Беренче битеннән үк бу журналга гашыйк булдым. Молодцы!

«Сөембикә» тиз-тиз генә укып чыгып, кырыйга этәрә торган журнал түгел ул. Аны әле кайта-кайта алып укыйсың. Кулга алган саен, яңа ягы белән ачыла бара. Почтага барып, тизрәк язылыйм дигән идем, икенче айдан гына язылып була, диделәр. Кайсы айдан булса да булыр, минем өчен яраткан журналыма юл ачылды инде.

Сөенечемнән төпчек кызыма шалтыраттым: «Казанда басылучы «Сөембикә» дигән бик шәп журналга язылдым, – дидем. – Аны укып карасаң, исең китәр. Ләкин башта берәр татарча китап табып, укып чыгарга кирәк булыр, балакаем». Минем өч балам да балалар бакчасыннан башлап урыс телендә сөйләште шул. Укулары да урыс телендә булды. Әниләреннән калганда төпчек кызыбызга 12 генә яшь иде әле. Ни эшлисең, язмыш.

Мөнир ХАРИСОВ.
Башкортстанның
Бакалы районы,
Бакалы авылы.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru



«ИҢ АВЫРЫ – ЯКЫННАР ХЫЯНӘТЕ...»

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Нахак сүз йөрәкне үтәли тишеп керә икән ул... Күңелең төпкелендә нәрсә ятканны белмичә, синең белән авыз чайкаучылардан, балаңа булган саф хисләреңне таптап, «күке ана» диючеләрдән бары Аллаһы Тәгаләгә сыенып кына сакланып була. Кемнәрдер сине «адашкан җан» дип саный, ә син бәхетеңне эзлисең. Беләсең: ул бар, якында гына... Бәхеткә юллар урау икән шул, аңа юлны Аллаһы Тәгалә генә күрсәтә ала... «Татарстан – Яңа гасыр» телеканалындагы «Хәбәрләр» программасының хәбәрчесе, бүгенге көндә Австралиядә яшәүче Финзия ГАЗИЗОВА әнә шулай уйлый. Аның белән ачыктан-ачык сөйләшәбез...

Авыр вакытларымда күккә карыйм да, күңелемә бер хәдистән юллар искә килә: «Сиңа авыр булса, түбәннәргә кара...» Йә Алла, бу фаҗига түгел бит әле, аяк-кулларым бар, күзләрем күрә, акылым саф, көчле булырга тиешмен, мин аны барыбер ерып чыгачакмын дип уйлыйм. Бу сүзләрне тормышымда күп тапкырлар кабатларга туры килде...

Кеше бу дөньяга җандаш табарга килә. Ул терәк тә, фикердәш тә, синең белән бер якка карап гомер итүче дә, назга күмүче дә... Ансыз яшәп булмый! Университетның өченче курсында укыганда ук шундый кешене таптым дип уйладым. Туйлар ясап өйләнештек. Мин Казанда укып йөрим, ул – авылда Мәдәният йорты җитәкчесе. Тик ике арада яшьлек дәрте генә янган, күрәсең, берберебезгә карата хөрмәтнең әсәре дә булмаган икән. Мин намаз укыдым, аның дингә исе дә китмәде. «Әби» дип атарга да күп сорамый иде. Кул да уйнаткалады. Бәлки, үземдә дә гаеп булгандыр – телем әче иде. «Бу минем кеше түгел икән бит», – дия идем үземә. Киләчәгемне аның белән берничек тә күз алдыма китерә алмадым. Ике ел яшәгәннән соң аерылыштык. Миңа дус булып йөргән кызлар белән чуала башлады. Ирем хыянәтеннән бигрәк, кызларның мондый адымга баруы йөрәгемә күбрәк тигәндер әле ул вакытта. Ә дуслар синең бәхетле булуыңны бик авыр кабул итә икән. Кат-кат авызым пешкәч кенә аңладым моны.

Башка кияүгә чыкмыйм дип кайттым. Күңел төшенкелегенә бирелдем. Ир-атлар белән аралашу түгел, алар ягына борылып карый да алмадым. Күңелемдә көчле затларга карата нәфрәт кенә иде. Мине ул вакытларда кыргый дип атыйлар иде хәтта, чөнки бер кеше белән аралашмадым, беркем, бернәрсә кызыксындырмады. Депрессиягә бирелүемнең тагын бер сәбәбе: әти белән әнинең өметләрен акламадым, йөзләренә кызыллык китердем дип борчылдым. Кызлары ирдән аерылып кайтты бит! Ата-ана өчен моннан да зур гарьлек юктыр дип уйладым. Ул вакытта нигәдер үзең турында түгел, алар хакында уйлыйсың икән. Андыйлар бер мин генә түгел. Бик күп хатын-кыз якыннарын борчуга салмыйм дип интегеп яши. Ләкин үзеңне корбан итү кирәк микән? Безгә гомер бер генә тапкыр бирелә бит...

Ул вакытларда намазларымны калдырырга тырышмадым. Аллаһы Тәгаләгә сыендым. Берзаман бик каты башым авырта башлады. Таш аскан кадәр авырайды ул. Мәчеткә өшкертергә йөрдем. Коръән аятьләрен укый гына башлыйлар, башым үзеннән-үзе әйләнә... Туры торарга, туктатырга тырышам, булдыра алмыйм. Сөйләсәләр һич ышанмас идем. Ул вакытта да әнә шул хәдисне искә төшердем. Өшкергән вакытта тирә-ягымда үгез булып кычкырган, ни кылганганын аңламаган кешеләргә карап, минеке алай ук куркыныч түгел дип уйладым. Аллаһы Тәгаләдән сорый-сорый гына кеше халәтенә кайттым. Ул вакытларда Коръәнне укып чыктым, бик күп хәдисләр өйрәндем. Фикерем дә үзгәрде. Кияүгә чыгам, тик дини кешегә генә дип үземә сүз бирдем. Аллаһ исеме белән яшәгән ир-атлар хатыннарын хөрмәт итә, авыр сүз әйтми дип фикер йөрттем. Күз алдыма һәрвакыт мөселман гаиләсе килде. Диннән ерак булган кешеләр белән бөтенләй аралашмадым.

Бу бит романтика, һәм монда хыянәткә урын, гомумән, юк иде.

Һәм шундый кешене таптым. Ул биш вакыт намазын укучы, ике дөнья әдәп-кануннарын саклап яшәүче. Сөенүләремне күрсәгез... «Йә Аллаһ, бу бит минем кешем. Кемне эзләдем, шуны таптым», – дип уйладым. Төс-кыяфәте европача, үзе матур, алты яшькә өлкән булуы да куандырды гына. Димәк, тормыш тәҗрибәсе зуррак, хаталар ясамаска яхшы булыр. Кызыклы әңгәмәдәш, белемле, укымышлы иде. Тарихи китаплар, урыс әдәбиятын су урынына эчә. Чын зыялы мөселман кешесе инде. Аның хәтта сөйләшүе дә башкача иде. Никах көненнән башлап без идеаль гаилә булып яшәдек. Әтиәнисе дә мине кабул итте. Икәү бергә басып намаз укыйбыз, җомга саен Мәрҗани мәчетенә йөрибез, яллар җитсә, Татарстанның төрле тарихи урыннарына сәяхәткә чыгып китәбез... Аларның Кызыл Байрак авылында дачалары бар иде. Теплоходка утырып шунда йөрдек. «Мин синсез яши алмыйм», – дия иде. Ул сүзләр уртак якты киләчәккә ышанычны көчәйтте. Дөрес, авыл кызы булуыма гел төрттерә иде. Ләкин кимсенмәдем. Авылдан чыкканнар гына бик тырыш, үз максатларына курыкмый бара торган була гадәттә. «Авылга кайтып кара әле, мин эшләгәннәрнең яртысын да белмисең бит», – дигәч, бер дә каршы әйтми иде. Без бит эшләп үскән авыл кызлары!

Балага да тиз уздым. Көмәнне дә бик җиңел күтәрдем. Бәхеткә чорналып яшәгән хатын-кызның тормышы әнә шулай келтер-келтер генә бара икән ул! Кызыбыз туды. Без хәзер чын гаилә! Түгәрәк бәхет менә шундый була икән дип куандым. Балага җиде ай тулгач, бераз авылда, әти белән әни янында кунак булып килдем. Фатирга кайтып, әйбер куярга дип шкафны ачсам, ул – буп-буш. Аптырап киттем. Аңа шалтыратам, телефонын алмый. Бары тик «смс» җибәрде: «Вакыты җиткәч, мине аңларсың...» Кая, кемгә киткәнен дә әйтмәде. Барысы да яхшы иде бит, мондый борылышны бөтенләй көтмәдем. Шок хәлендә калдым. Кечкенә сабыем белән кеше фатирында ялгыз утырып калдым. Уйлана торгач, аның: «Бергә университетта укыган кызны кибеттә очраттым. Ул очрашуга чакырды, бармыйм, минем бит хатыным, балам бар», – дип сөйләгәнен исемә төшердем. Ул вакытта бу сүзләргә бөтенләй игътибар бирмәгәнмен икән... Соңыннан гына белдем, ул чынлап та студент чакта яратышкан шул хатынга киткән... Шул китүеннән югалды. Аның кызыбызны бер тапкыр да килеп күргәне юк. Биш-алты айга бер тапкыр: «Привет. Как она?» – дип «смс» җибәрә. ОНА! Исеме белән дә атамый, кызым да дими... Акчага интексәм дә, алиментка бирмәдем. Картлык көнендә кызымнан алимент таләп итеп ятуын теләмим.

Аны югалтуны бик авыр кичерсәм дә, артыннан ялынып йөрүне кирәк тапмадым. Әти-әниләренә дә шалты-

Бераздан ул килеп керде һәм....
бөтен дөньям яктырып
киткәндәй булды.

ратмадым. Алар да хәлемне белешмәде һәм хәзерге көнгә кадәр оныклары белән кызыксынганнары юк.
Ә бит шундый зыялы кешеләр! Салкын ноябрь ае иде бу. Кешене өмет яшәтә бит. Мин аны көттем. Яңа елга кайтыр әле дип яшәдем. Ләкин ул ишек какмады. Һәрвакыт Аллаһтан «хәерлесен бир» дип сорадым. Шул айларда җиде килограммга ябыктым. Гел догалар укыдым, алар мине шундый тынычландырды. «Кешеләрнең ирләре тәгәрәп тә үлә әле, өчәр бала белән ялгыз калалар. Тырышалар, аякка бастыралар. Бер баланы гына үстерерсең әле, көчле бул, Финзия. Әти белән әни бар. Яши алмасаң, авылга кайтырсың», – дип әйтә идем үземә. Ул вакытларда акылдан язудан кызым гына коткарып калгандыр, мөгаен. Бала сизә, аңа яшьне күрсәтергә ярамый дип уйлый идем. Җитмәсә, минем хакта теләсә нинди гайбәтләр таралды. «Егылсын да, тора алмасын әле», – диючеләр булгандыр инде. Эштәге хезмәттәшем киңәш бирде: «Бер колагыңнан керт тә икенчесеннән чыгар. Ул кешеләргә ачу-үпкә дә саклама, тормышыңнан сыз да ат». Бик ярдәм итте! Мин башкаларга да шулай эшләргә киңәш итәр идем.

Яңа ел узгач, бала белән авылга, әти-әни янына кайтырга җыена башладым. Фатирга түләп торырга акчам да бетте, гел болай ялгызлыкта яшәп тә булмый иде инде... Бер көнне танышым шалтырата: «Австралиядән бер кеше килгән, әйдә, таныштырыйм әле шуның белән», – ди. Корт чаккандай куркып киттем: «Юк, бетте! Башка ир-атлар ягына борылып та карамыйм, миңа беркем дә кирәкми», – дим. Берничә көннән тагын телефон шалтырый. Ят номер. «Исәнмесез. Сезне күрәсебез килә», – ди бер ханым. Елап җибәрдем. Язмышка үпкә булды микән ул, көчсезлегемнән гарьләнүме... «Беркем белән дә танышырга теләмим. Бик авыр вакытым, зинһар, миңа башка шалтыратмагыз», – дим сулкылдап. Икенче көнне иртән тагын теге ханым шалтырата: «Адресыгыз ничек? Хәзер сезгә киләбез», – ди. Өйдә кеше кабул итмим, дип баш тарттым. Бу хәлләрне аралашып яшәгән күрше хатынына сөйләдем.

– Җүләр булма әле. Гомерең буе салкын мендәреңне кочаклап елап ятарсыңмыни? Балаңны үзем алып калам, барып кайт. Бәлки, ошар, – диде күршем.

Ә минем сөйләшү түгел, хәтта, берәүне дә күрәсем килми. Бөтенләй ятлар белән нәрсә турында әңгәмә корасың инде?.. Тагын чакырып шалтырткач, икеләнеп кенә риза булдым. Билгеләнгән очрашу урынында теге ханым гына басып тора иде. Бераздан ул килеп керде һәм... бөтен дөньям яктырып киткәндәй булды. Ул мизгелне әлегә кадәр хәтерлим. Миңа нindидер бер җиңеллек, рәхәтлек иңде кебек... Елмаеп килеп басты яныбызга. Таныштык. Татарча авыррак сөйләшә иде. Теге ханым безгә тылмач та булды. «Австралиягә алып китәргә хатын эзлим», – ди Рифкать. «Мин риза түгел, Татарстаннан беркая да китмим», – дим. Үзем сөйләшәм, үзем балам хакында уйлыйм. Ул елап, ярсып беткәндер кебек. Ахырда гафу үтенеп, балам янына кайтырга кирәк дип чыгып киттем. Икенче көнне социаль челтәрләр аша аннан хат килде. Очрашуга чакырсам, вакытыгыз булырмы дип сорап язган. Әнигә шалтыратып сөйләгәч: «Бәлки, аралашып карарсың, үзеңә бер юаныч булыр», – ди. Үземә дә ошады кебек. Әнинең энесенә охшаттым мин аны. Шуңа якын тоелды микән әллә? Тагын очрашуга киттем. Бу юлы тылмачсыз гына аңлаштык.
Ул аерылган. Дин тоткан татар кызы белән тормыш корасы килә икән. Баланы ташлап, гел очрашып йөреп булмый. Икенче тапкыр үзе безгә килде. Ул көнне буран иде, минем поликлиникадан балага дигән сөт-кефирларны алып кайтасым бар. Һаман шул хакта уйлыйм. Борчылуымны сизде, ахрысы. «Нәрсә булды?» – дип кызыксынды. Мин сөйләп биргәч: «Эмилия белән үзем утырып торам, барыгыз, алып кайтыгыз», – дип ярдәмен тәкъдим итте. Шунысы кызык: бала миңа гына ияләнгән, кешегә бик бармый иде, ә Рифкатьтән ятсынмады. Икеләнеп калдым... Кызымны интектереп йөртәсем дә килми. Уйлый торгач, тиз генә киендем дә йөгерә-йөгерә чыгып киттем. Юл буе баланың нишләгәнен язып торды. «Борчылмагыз», – дип тынычландырды. Кайтып керсәм, бала йоклап киткән. Ул аны караватына да салмаган, күтәреп йөри. Аңа хөрмәтем артты. Үз әтисе болай күтәреп йөрми, тизрәк бишегенә сала иде дигән чагыштыру узды башымнан...

Рифкать безгә килеп йөри башлады. Бер-беребез белән «сез» дип кенә сөйләшәбез. Бер килүендә: «Гафу итегез, башым авырта, сөйләшеп утыра алмыйм. Ялгызым гына каласым килә», – дидем.

– Эмилияне үзем карап торам. Сез шопингка барыгыз, күңелегез нәрсә тели, шуны алыгыз, – дип акча сузды.

– Юк, юк, кирәкми, – дим. Ир-аттан акча алып өйрәнгәнмени инде без?! Үзем булдырам дип яшәүчеләр кавеменнән бит. Ә алай дип яшәү дөрес түгел икән ул. Мин монысын да яши-яши генә аңладым. Бәлки, икенче ирем белән аерылу сәбәбенең тамыры да «мин, үзем» дип яшәүгә барып тоташадыр әле...

Сөйләшә торгач, Рифкать акчаны алырга да, кибеткә барып кайтырга да күндерде. Якындагы сәүдә үзәгенә барып витриналар карап йөрдем, нинди акча туздыру инде... Шулай да, кыйммәт булмаган бер тушь алдым. Кайткач, калган акчаны аңа суздым. Ул миңа шундый сәерсенеп карап куйды. «Миңа акча кирәк түгел, аны сезгә тотарга бирдем», – ди. «Тоттым, алдым, рәхмәт, калганы кирәк түгел. Тушь сезнең бүләк булыр», – дим. Акчаны алмады, үзе күрмәгәндә куртка кесәсенә салып куйдым. Югыйсә акчам да юк. Һаман да: «Юк, Финзия, син үзең булдырачаксың, кирәкми сиңа кеше акчасы!» – дим. Бер килүендә: «Әти-әниләрегез ерак яшиме? Аларны күрәсем килә», – диде. Әнидән сорадым. Алар минем бик кунакчыл, «кайтсын», диделәр. Безнең әле кулдан да тотышкан юк. Ул үрелсә дә,

мин тизрәк кулымны алам. Якын да утырмыйм. Кыргыйлыкмы, ирләрдән курку булганмы инде ул... Ә балама, миңа ул ошый башлаган иде инде. Авылда бик тиз уртак тел таптылар. Әти-әни дә ошатты Рифкатьне: акыллы, дини, биш вакыт намазын укый... «Финзия миңа бик ошады, тик минем белән Австралиягә китәргә риза түгел», – дип, читләтеп кенә кулымны сорады. Ә мин исә: «Финзия, тәртәгә типмә әле. Австралия бит ул, син анда тиз генә барып җитә алмассың. Күпме документ тутырырга кирәк. Синең кызыңа илдән чыгып китәргә кем рөхсәт бирер икән... Ике-өч ел вакыт узмый калмас», – дип, үз-үзем белән сөйләшәм. Никах укыттык. Ул Австралиягә кайтып китте, мин монда калдым.

Көннәрдән бер көнне авыр вакытларымда ярдәм иткән кешеләрнең миңа карата мөнәсәбәтләре бөтенләй кире якка үзгәрде. Бәхетле булуымны гафу итә алмадылар, күрәсең. Рифкатькә минем хакта теләсә нинди гайбәтләр сөйләгәннәр. Сүз бит ул үтерә. Сизәм, ул да суынды... «Миңа башка төрле хатын кирәк булган икән», – дип язды. Ялынмадым, Аллаһы Тәгалә ничек куша, шулай булыр дип уйладым. Шул көннәрдә башка зур кайгы килде: операциягә киткән җиреннән әти үлеп кайтты. Бик зур югалту булды ул. Әти дә китте, Рифкать тә югалды. Депрессиягә бирелеп, акылдан шашмаудан эшем генә алып калгандыр. Балтачтан иртән автобуста Казанга чыгып китәм, көне буе телевидениедә сюжетлар төшерәм, монтажлыйм да, авылга кайтырга юлга чыгам. Эшкә тәмам чумдым, башка уйларга һич вакыт юк. Беркөнне Рифкать хәбәр җибәрде: «Улым иртән чыгып киткән җиреннән әлегә кадәр кайтмаган...» Мин – әтине, ул улын җирләде... Берничә айдан Рифкатьтән кабат хәбәр килә: «Синең белән сөйләшергә кирәк». Татарстанга кайта алмый, эше буенча Малайзиягә командировкага бара, мине дә шунда чакыра. Билгесезлектән шундый туйган идем. Ходай каршында мин ирле, ә тормышта ул юк... Әни дә риза булгач, җиде ят җиргә аның белән очрашуга чыгып киттем. Күрештек. Үзгәргән. Бөтенләй икенче кеше. Корылык, салкынлык сизелде. Шулай да Балига ял итәргә барырга тәкъдим итте. Соңыннан гына әйтте: хушлашу сәяхәте итеп оештырган икән. Еллардан соң минем белән сәер генә саубуллашты. Ул – Австралиягә, мин Татарстанга кайтып киттем. Шуннан соң ул тагын югалды. Үзем бар да бетте дип уйласам да, күңелдә өмет яшәде. Истихара намазыннан соң күргән төшләрем дә бар да яхшы булачагын белгертте. Ләкин күңелне иң куырганы: туган кебек якын күргән кешеләрем безнең арага керде. Тормышта берәүгә дә ышанасы түгел икән!

Һаман Балтач белән Казан арасын таптап булмый. Сөйләшеп, артыннан йөри торгач, элек яшәгән тулай торагыма кире кайттым. Кияүгә чыкканда: «Туйдым бу тулай торактан, бүтән монда кайтмыйм», – дип, ишекне ябып чыгып киткән идем югыйсә. Бервакытта да алай дип әйтергә ярамый икән. Тормышта төрле хәлләр чыгарга мөмкин, барысына да әзер булырга кирәк. Ул вакытта күңелем бик төште. Һаман да әнә шул хәдисне искә алып: «Аллага шөкер, кайтып йоклар почмагым бар», – дип үземне тынычландырдым. Күпмедер вакыттан соң Рифкать кабат яза башлады. Бу юлы инде миндә аңа карата салкынлык туды. Ә ул һаман яза да яза. «Тиздән Кытайга барам, билет алам, син дә килче», – ди бу. Уйладым-уйладым да, барып карыйм әле дидем. Әни белән сөйләштем дә, үз хисабымнан ял алып, тагын чыгып киттем. Кытайда ул икенче төрле иде инде. Һаман минем көйне генә көйләргә тырышты. Дуслашып аерылыштык. Шул сәфәрдән авырга узып кайттым. Азатны бик авыр күтәрдем. Көмәнем 13 атналык вакытында аркам юешләнгәннән уянып киттем. Карасам, бөтен урын-җирем кан. Ашыгыч ярдәм машинасында хастаханәгә алып киттеләр. Инде төште дигән баланы табиблар саклап кала алды. Өченче УЗИ үткән вакытта: «Хәзер үк хастаханәгә ят, балаң да төшәчәк, үзең дә үләчәксең», – диде табиб. Ай буе тормый ятканнан соң, 36 атнада операциягә әзерли башладылар. Башта ук бик авыр операция була, икегезнең дә исән калу мөмкинлеге бик аз, диделәр. Операция өстәлендә мин үләндә калдым. Күп кан югалтканнан һушымны җуя башлаганда: «Аллаһым, исән калсам, башыма яулык ябар идем», – дип уйладым... Өч көн реанимациядә, бер айлап хастаханәдә яттык. Безне хастаханәдән каршы алырга ирем кайтты. Аның белән Австралиягә генә китә алмадык. Миңа виза бирмәделәр. Азатка ун ай булгач кына юлга кузгалдык. Кызыма рөхсәт ала алмагач, ул әни янында калды. Әни дә әти үлгәннән соң биреште. «Шушы бала гына юаныч миңа», – ди иде. Әнинең баланы миннән яхшырак тәрбияләгәнен белгәнгә дә калдырып китә алдым бугай. Дөрес әйтмим, үзем китсәм дә, йөрәгем кызым белән калды. Көнгә берничә тапкыр сөйләшеп тордык. Әни, бала бүген авырый әле дигән көннәрдә үземә урын таба алмадым. Ул да бит минем бәгырь итем. Ул да минем балам, нарасыем. Минем хакта «күке әни» дигән сүзләр ишеттерделәр. Бик күп якын күргән кешеләрем: «Ничек баланы ташлап китә алдың инде?» – дип яздылар. Үрсәләнеп елаган вакытым күп булды, ирем, игътибар итмә, ди иде. Ничек игътибар итмисең инде, чит-ят кешеләр түгел, якыннар арага тоз салды бит. Эмилиясез сигез ай яшәдем. Кайтып, баланы илдән алып чыгып китәр өчен суд аша әтисеннән рөхсәт алдым. Аллаһы Тәгалә мине ишетте, хәзер матур гаилә булып яшәп ятабыз. Үзебезнең кечкенә дәүләтебезгә артык кешеләрне кертергә кирәк түгеллеген мин дә, Рифкать тә аңладык инде. Аның янында үземне якланган дип хис итәм. Беренчедән, хәзер мин үзем дип әйтмим инде; икенчедән, ул ничек әйтсә, шулай була. Элекке гаиләләремдә баш булырга тели идем, хәзер муен гына булып яшәргә риза. Алай күпкә рәхәтрәк икән бит. Хәзер иркә хатын булып кына яшим. Эмилиянең әтисенә дә үпкә тотмыйм. Мин аны аңладым. Һәркемнең бәхеткә хокукы бар. Шулай язган булган. Беренчесенең дә гаиләсе бар. Гөрләп яшәп яталар. Исән-сау яшәсеннәр. Әле без яши генә башладык. Барысы да – алда. Тормыш сабаклары күп булды инде ул. Күпләрдә кара көнчелек утының каты янганын аңладым. Алар – бәхетсез. Бәхетлеләр башкалар тормышына кысылмый...



КЫРЫС ЭЛЬБРУС КЫРЫСМЫ?



Эльза НӘБИУЛЛИНА

Быелгы җәйне мин үземчә көттем. «Ул башка җәйләрдән аерылып торачак, үзгә һәм әчтәлекле сәяхәтләргә бай булачак. Юкка түгел! Быел җәй безнең кызыбыз Галиябануга 1 яшь тула, ә 1 яшьлек бала ул инде дөньяга яңа аваз салган нарасый түгел. Аның белән юл мәшәкатьләре күпкә азрак, җиңелрәк. Ел әйләнәсе Казан тирәсен, Татарстанның төрле шәһәр-районнарын бер генә урамадык бит. Димәк, инде әзерлек бар...» дип уйладым. Тик уйлау – ул бер нәрсә. Ә чынлыкта нәрсә килеп чыкты? Хәзер сөйлим.

Узган җәй азагында ук инде (кызыбызга ул вакытта нибары ике ай!): «Кавказга!» – дигән шигарь белән берничә тапкыр юлга чыгарга талпынып карадык, әмма насыйп сәгать сукмаган булган, күрәсең: җыенып чыгып китә алмадык. Күңел әллә кайчан: «Алып китегез мине тауларга, бер генә сәгатькә булса да...» – дип моң-зар елый, чөнки озын юлга чыкмаганга инде ике кыш. Күз алдыгызга китерәсезме? Озын ике кыш! Бу – даими сәяхәтче өчен, минем кебек «күчмә тормыш» җанатарына бик озак вакыт. Бөтен өметем быелгы җәйге ялда иде.

Мәңгелек кебек тоелган зур бозлыклар да, эреп, тау елгаларында шаулап ага.

Ниһаять, карар кабул ителде: «Әйдә, янә Кавказга!»

Без Кавказны бик яратабыз: күп тапкырлар тикшерелгән, ышанычлы маршрут, монда һәркем үзенә хуш килердәй шөгыль таба алачак. Мәһабәт таулар, саф һава, шифалы чыганаклар, йөреп туя алмаслык төрледән-төрле маршрутлар... Төшләргә кереп саташтырган гүзәл табигате турында әйтеп тә торасы юк. Ел әйләнәсе кунакларын колач җәеп каршы ала, яхшы ният белән килгән мосафирларына шатлана. Таулар безнең өчен тагын бер әһәмияткә ия: гаилә булып яши башлаганнан соң, иң элек нәкъ менә Каф тауларына сәяхәт кылган идек. Ә бу юлы без бирегә яңа рольдә – әти-әни буларак киләбез. Көт безне, Каф тавы, без инде юлда! (Ният – ярты юл диләр бит!) Зур ачышлар иленә, сәяхәт дөньясына кереп китәргә синең фатихаңны алырга дип, кызыбыз Галиябану да килә.

Әзерлек

Әзерлек дигәннән, безнең очракта «бер вагон чемодан һәм ун пакет» турында сүз бармый. Мин күбрәк эмоциональ һәм психологик халәтне кайгыртам (нәкъ теге җырдагы кебек «Главней всего погода в доме...»). Чөнки юлдагы көтелмәгән хәлләрне, планнарның яки теләкләрнең кискен үзгәрүен дөрес кабул итә белүне тәэмин итәрдәй нәрсә унберенче пакетта онытылган булырга мөмкин. Алдан ук үземне «монда һәм хәзер» дулкынына көйләдем, ягъни һәр мизгелдән, һәр вакыйгадан, урыннан ләззәт аласың. Еш кына «барсам – кайтасы килә, кайтсам – барасы килә» режимында йөрибез бит. Бу юлы алай булырга тиеш түгел!

Сәяхәтебезне, әйткәнемчә, Кавказга дип тәгаенләдек. Безне кызыктырган берничә урын бар: Домбай, Джылы су (безнеңчә Җылы су була инде) һәм Эльбрус. Ниндидер аерым төзегән маршрут юк: без, гомумән, беркайчан да сәяхәтебезгә катгый таләпләр куймыйбыз. Еш кына үзебезгә экспромт, импровизация рөхсәт итәбез: телисең икән – юлдан кире борыл, башка юл буенча бар, теләсәң, кайсыдыр урында озаграк тукта. Үз машинаңда хәрәкәт итү эшне тагын да җиңелләштерә. Шуңа күрә бу юлы да үз машинабызга утырып сәяхәт итәргә булдык.

Экспромт дигәннән, шуны да истә тотарга кирәк: хәзер без юлга бала белән чыгабыз. Кайбер шартларны (тукталышлар, ашау-эчү, йокы мәсьәләләрен) истә тотарга кирәк. Бәләкәч кәефсезләнсә, бу сәяхәттән берәүгә дә рәхәт булмас.

Р-228 трассасы

Балалар һәрнәрсәгә җайлаша анысы... Әмма дөресен әйтергә кирәк, моңа кадәрле йөргән юлларым бик күпкә уңай булган икән, кем әйтмешли, «ерунда». Җәннәт! Моны мин сәфәребезнең беренче көнендә үк аңладым. Ләкин артка юл юк иде инде.

Өйдән чыгып киткәндә, үзебезгә бурычның иң зурысын куйдык: аңа-моңа карамый, алны-ялны белми, иң беренче ноктага кадәр барып җитәргә. Ул нокта – Казаннан 1834 чакрым ераклыкта урнашкан Карачай-Чиркәс Республикасының таулар арасында утырган Домбай курорт бистәсе.

Машинабыз Р-228 трассасы буйлап хәрәкәт итә. Тыштан карaганда, башкалардан әллә ни аерылып тормаган транспортыбыз эчке яктан балалар бакчасының «ясле төркемен» хәтерләтә: Галиябану белән пирамидалар төзибез, әкиятләр сөйлибез. Инде егерменче тапкыр йомшак китапны актарабыз, утызынчы кат «Без-без-без идек»не уйныйбыз. Әти-әни дуэты башкаруында n нчы тапкыр «Кояшлы ил» җыры яңгырый. Ниһаять, черем итеп алабыз... Бала йоклаганда, мин тиз генә алгы утыргычка күчеп утырам. Үз-үземә биргән вәгъдәмә тугры калып, тирә-юньне күзәтәм, матурлыкка сокланам.

Кара диңгез буена ял итәргә баручыларның юлы да шушыннан уза. Машиналар шактый күп, юл тыгын, өстәвенә, юл төзәтү эшләре дә җәйге чорга туры килә. Безне юл өстендә калучы шәһәрләр әллә ни кызыксындырмый. Шуңа күрә Сарытау, Волгоград, Элиста кебек шәһәрләрне мөмкин кадәр тиз генә урап узабыз.

Домбайга юл кая?


Бер тәүлек дигәндә Ставрополь краена җиттек, ә бу инде Кавказның итәге, башлам өлеше. Димәк, безгә кирәкле Карачайлар иле каядыр якында гына. Әкренләп җирлек үзгәрә: калкулыклар сизелеп арта, бара-бара алары тауларга әверелә. Вакыт төшкә авышканда без инде Домбайга якынлаша идек. Домбай юлы искиткеч гүзәл: куе урманлыклар, мөселман авыллары, тау башында салынган ярымайлы мәчетләр – барысы да күңелдә якын, җылы хис уята...

Ниһаять, Домбай! Без арыган, ләкин монда булуыбызга шатбыз. Кунакханәгә урнашып, кунакчыл хуҗабикәбез белән аралашып алганнан соң, татлы йокыга талабыз.

Алдагы көннәребезне актив ялга багышладык. Домбай Теберда тыюлыгында урнашкан, җәен дә, кышын да туристларны үзенә җәлеп итә. Кышын – тау чаңгыларында шуарга, ә җәен дистәләгән маршрутлар буенча җәяүле походларга чыгарга, альпинизм белән шөгыльләнергә, күлләр, шарлавыклар, бозлыклар белән танышырга менә дигән урын. Өстәвенә, җирле Нарзан чыганаклары тәнгә сихәт бирә. Биредә бик чиста, карачай халкы ачык һәм кунакчыл, ә инде аларның «фирменный» яңа пешкән хычиннары... ммм... Шагыйрь әйтмешли: искә төшсә, йөрәк яна. Кыскасы,

Автор фотолары

Тауларда – йокы бөтенләй башка! Монда син тау елгалары шавына изрәп йоклап китәсең.



искиткеч тәмле, бигрәк тә оста хуҗабикәләргә юлыксаң, авыз итми китәргә һич ярамый. Домбайда карачай халкы яши. Татарча-карачайча сөйләшеп, рәхәтләнеп аңлашырга була.

Әгәр миннән бүген менә: «Гаилә белән ял итәргә кая барырга киңәш итәсең?» – дип сорасалар (еш кына сорыйлар да), ике дә уйламый, күземне дә йоммый: «Домбайга!» – дияр идем. Норвегия дә, Исландия дә, Таиланд, Индонезия дә түгел, ә Карачай-Чиркәскә!

Иң элек без Теберда тыюлыгындагы Тур күленә илтә торган юл буенча сәяхәт иттек. Якынча сигез чакрым чамасы озынлыкта, әмма төрле маршрутлар, төрле сукмаклар бар. Бу – бик уңайлы юл. Туристлар машинада уза, әмма мин җәяү барырга киңәш итәр идем. Җәяү бөтенләй башка тәэсирләр бит: янәшәңнән шаулап тау елгалары ага, чишмәләр чылтырый, киң итеп һава сулап куясың да, ташларга үсеп чыккан мүкләрне капшап карыйсың, ул арада яңгыр сибәли... Яңгыр дигәннән, яңгыр чапаныгызны алырга онытмагыз, алдан кисәтеп тормый мондагы болытлар – килә дә ява. Ява дию аз – ишә. Кайту юлында шулай шәп кенә иште дә, безгә машина ялларга туры килде.

Юлда беренче тукталыш – Альпинистлар зираты. Биредә танылган альпинистлар җирләнгән. Карап узу тәэсирләндерә, файдалы да дип уйлыйм. Киләсе тукталыш – Алибек альпинистлар лагере. Монда туктап ял итәргә була. Ары китсәң, ерактан Алибек бозлыгы «теле» күренә торган яланга юлыгасың. Бозлыкларга минем аерым хөрмәтмөнәсәбәтем бар. Дөньяда бернәрсә дә мәңгелек түгел дигән фәлсәфәгә барып тоташа ул.

Һәм, ниһаять, иң чыдам юлчылар Турье күленең үзенә үк барып җитә. Без исә әтиебезнең телефонга төшергән фотоларына карап кына күлнең гүзәллегенә сокландык.

Домбайдагы калган көннәрне дә әйләнә-тирәдәге кызыклы урыннар белән танышып үткәрдек: Шайтан Тегермәне шарлавыгы, Туманлыкел, Сухум-хәрби юлы, Гоначхир тарлавыгы һәм башка төрле табигать гүзәллекләре белән таныштык.

Шулай итеп, дүрт көнгә сузылган Домбай ялыбыз тәмам, ә без юлыбызны алга таба Кисловодскига таба дәвам итәбез.

Ачы су – Джылы су

Ачы су – карачай халкы Кисловодскины шулай дип атый. Әлеге курорт-шәһәр үзенең шифалы чыганаклары белән дан тота. Күпләргә билгеле, үзенә күрә популяр урын. Кисловодск – бик ягымлы шәһәр, әмма без биредә озаклап туктап тормадык. Шифалы чыганаклардан берничә йотым гына авыз иттек тә кабат юлга кузгалдык. Безне яңа ачышлар көтә! Алга таба узачак юлыбыз – дөньядагы иң матур юлларның берсе дип вәгъдә итә юлкүрсәткеч язма чыганаклар.

Безне кызыксындырганы – Джылы су дип аталган урын. Бу торак пункт түгел, әмма кавказлылар өчен зур әһәмияткә ия үзәнлек: мондагы кайнар чыганаклардан сихәт алырга дип ераклардан киләләр. Чыганаклар күз авыруларын, үпкә ялкынсынуын, репродуктив органнарны һәм башка төр авыруларны дәвалый.

Безне исә гаҗәеп таулы манзаралар җәлеп итте. Кисловодск – Джылы су юлы 85 чакрымга сузылган. Шөкер, сәяхәтчеләрне кайгыртып, яхшы асфальт юл җәелгән. Юл буенда торак пунктлар очрамый, бары тик җәйләүләр, көтүлекләр генә күренеп кала.

Дүрт үткел, өч тарлавык аша бара торган әлеге юл, чыннан да, тәэсирләндерә. Өстәвенә, биредә Европаның иң биек ноктасы – Эльбруска гүзәл манзара ачыла. Ләкин һава шартлары без теләгәнчә үк уңай булмады – Эльбрус чал башын гына күрсәтеп алды. Хәер, шул да җитә калды – биек тауны бер күргән кеше аны беркайчан



Ә күтәргеч безне канат юлы буенча салмак кына өскә алып менә: тирә-якта карлы биеклекләр, аста – шарлавык, елгалар, ара-тирә болытлар уратып ала...

оныта алмый. Һәм без, һичшикчсез, Эльбрус белән якыннан барып танышырга булдык.

Галиябану Эльбрусны яулый!

Безнең кебек махсус әзерлек узмаган сәяхәтчеләргә Эльбрусны күрү өчен өчен иң уңайлы юл – Эльбрус итәгендә урнашкан Азау аланы (Кабарда-Балкар Республикасына карый). Чаңгычылар өчен көйләнгән канат юлы, шөкер, җәен дә эшли. Канат юлы 2350 метр биеклектән башлап, берничә этапта 3780 метр югарылыкка кадәр күтәрелә. Җәен легендар биеклекне яуларга дөньяның төрле почмакларыннан альпинистлар җыела.

Күптәннән игътибар иткәнем бар: сәяхәттә йөргәндә, әллә нинди җанга якын, ягымлы, ачык кешеләр очрый. Бигрәк тә – тауларда. Тауга гади кешеләр йөрмидер ул. Яки аларны таулар үзгәртә торгандыр.

Ә гомере буе тауларда яшәүчеләр? Беләсезме, алар чыннан да үзгә. Без – җир кешеләре, алар – таулылар. Алар янында без – шул таулылар дәрәҗәсенә үрмәләргә маташучылар гына. Менә шундыйрак фәлсәфи уйлар килде. Икенче яктан башымда Владимир Высоцкийның җыр сүзләре яңгырый:

Я спросил тебя:
«Зачем идете в горы вы? –
А ты к вершине шла,
а ты рвалася в бой, –
Ведь Эльбрус
и с самолёта видно здорово...»
Рассмеялась ты – и взяла с собой.

Ә күтәргеч канат юлы буенча салмак кына өскә алып менә: тирә-якта карлы биеклекләр, аста – шарлавык, елгалар, ара-тирә болытлар уратып ала, кулда бала. Аңа берни түгел, биеклектәге басым өчен дә кайгырасы юк: тауларда йөри торгач, Галиябану да биеклеккә күнекте. Шылт та итми, җылы киемнәренә төренгән дә тормышыннан канәгать кыяфәт чыгарып утыра. Яшең тулыр-тулмас, Эльбрусны «яуласаң», син дә канәгать булыр идең! Тагын Высоцкий искә төшә:

Альпинистка моя, скалолазка моя!

Беренче карашка – кырыс, ләкин бер күргәч инде – оныта алырлык түгел. Минем үземә Эльбрус нык тәэсир итте. Бирегә, һичшиксез, кабат-кабат әйләнеп кайтырга кирәк.

Дөресен әйтим, миндә Россиядәге теләсә нинди төр ялга бераз өстен карау бар иде. Янәсе, фи-и, шушы да булдымы ял һәм сәяхәт. Кичерегез мине, Кабарда-Балкар, Карачай-Чиркәс Республикалары, кичерегез, Каф таулары. Ялгышымны таныйм һәм чиксез соклануымны белдерәм!

Ә безнең җәйге сәяхәтебез әле моның белән генә тәмамланмады. Юлыбызны Гөрҗистанга таба дәвам иттек. Тик бу инде бөтенләй башка бер хикәят...

«ИР – ТАБУЧЫ, ХАТЫН БҮЛҮЧЕ БУЛСЫН»



Фәрит УРАЗАЕВ, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура әгъзасы, Татар эшмәкәрләре ассоциациясенең башкарма директоры; гаилә стажы – 35 ел; ике бала атасы.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, тегe яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя... Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Күзләргәдер... Ни өченме? 65 процент мәгълүматны вербаль булмаган рәвештә алабыз. Кешенең күз карашы бик күп нәрсәне сөйли ала. Без кайчак кайбер парлар турында: «Алар бер-берсен ярты сүздән аңлый», – дип әйтәбез. Ә бит бер-берсен күз карашыннан аңлаучылар да бар... Булачак хатынымда иң элек нәрсәгә игътибар иттемме? Үзенең әнисе турында «әнкәй» дип сөйләвенә! Без Сарман районында әти белән әнигә «әткәй-әнкәй» дип эндәшәбез. Ә ул Буа кызы, Кильдураз авылыннан. Әнисе Баулыдан булып чыкты, шуңа күрә аларны кечкенәдән үзенә «әнкәй» дип әйтергә күнектергән.

2 Нәрсә өчен сез бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Баласына зыян китергән, аны ятим иткән хатын-кызны кичермәс идем... Бала хакы һәм «ана» төшенчәсе дигән кыйммәтләр бар. Адәм баласы өчен бу дөньяда иң авыр мизгел – ятим калу, аны әнисе ташлап китү, тәрбияләмәү: бу – баланың күңелендә беркайчан узмас эз салачак, аны гомер буе озата барачак. Үпкә, рәнҗеш, аңламау, кимсенү... Безнең татар халкында бик күп матур җырлар әнкәйләргә атап чыгарылган. Алар – баланың анага мәхәббәте чагылышы. Ул җырлар һәрберсе әнкәебез турында да... Безнең әнкәй җиде ир-егетне аяккa бастырган һәм әткәйне тәрбияләгән кеше. Әнкәй бакыйлыкка күчеп, сигезебез басып калгач кына аңладык без моны...

3 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Ирне ир иткән дә, җир иткән дә хатын-кыз, диләр. Өйдәге хатын-кыз һәрвакытта да ир кешегә якын. Ир-ат бит ул, гомумән, үзе дә кечкенә бала сыман. Үз тормышыбыздан чыгып әйтәм моны. Әткәй белән әнкәй кырык өч ел бергә тордылар. Әткәй аннан калып ун ел яшәде. Зиратка баргач, ул һәрвакытта бер сүзне кабатлый иде: «Әниегез мине кырык өч ел буе тәрбияләде...» Бу зур бәя! Өйдәге хатын-кызда җылылык та, яктылык та, балалар хакы да, ир хакы да. Минем өчен дә икенчесе якынрак.

4 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Хәтерлим! Волгоград физик культура институтының Казан филиалын тәмамладым. Тулай торагыбыз Батыршин урамындагы 23 нче йортта урнашкан иде. Күршебездә – 25 нче йортта – сәүдә өлкәсендә эшләүчеләр тора. Булачак хатыным да икмәк кибетендә, кондитер бүлегендә эшли иде. Яз көне ике тулай торакта торучылар җыелышып волейбол уйный идек. Шунда таныштык... Укуны тәмамлаганчы Гөлзидә белән бер-ике ел дуслашып йөрдек. Бергә безнең якка да кайткаладык, аларга да. Диплом алганнан соң, ел ярым армиядә хезмәт иттем. Ул минем янга Мәскәүгә килгәләп йөрде. Үзем дә ялда булып киттем. Калган вакытта ике араны хатлар ялгады... Июль аенда кайттым, 18 августта инде өйләнештек. 1984 ел бу. Сарманга ул чакта әле самолетлар оча иде. Буалар – унбишләп кеше, тулы бер самолет булып кайттылар. Мин аларны аэропортта каршы алдым. Алдан уйлап, килешенеп, бер-беребезне белеп кавыштык. Икебезгә дә 24 яшь иде бу вакытта. Икебез дә ноябрь аенда туганбыз, тик мин аннан 20 көнгә алданрак... Туй Сарманда, ресторанда узды. Әнкәй мәрхүмнең: «Карале, болай җиңел икән, әзерлисе дә, табак-савыт та юып азапланасы юк», – дип әйткәне әле дә истә. Мин гаиләдә алтынчы малай. Туйлар шактый күргән иде инде әнкәй... Олы абыем Рафисны, Сарман ягында Илһам абыйдан кала, икенче җырчы дип йөртәләр. Ул Бохарада укыды, 30 яшьтә генә өйләнде. Икенче абый Бохарада өйләнде – әти белән әни туйга анда барды. Өченче абый армиядән кайту белән яшьли авылда өйләнде. Дүртенче абый хәрби иде: туе Казанда булды. Яшьрәк чакта, алдан сөйләшеп, барыбыз бергә ялга әткәй-әнкәй янына кайта идек. Җиде ир-егет, җиде килен, ундүрт онык... Биш тәрәзәле авыл өендә утыздан артык кеше булабыз. Ай буе шунда торабыз, күмәкләп зур эшләрне башкарабыз, балаларны аралашты-

рабыз... Туган-тумачалар – бүген дә иң зур байлыгыбыз. Төп нигездә 60–70 кеше җыелу – безнең өчен гадәти күренеш. Аралашу, нәсел-нәсәпне белү, барлау – ул бездә бар. Балаларга да иплэп кенә сеңеп бара бу: алар да үзара аралаша, бездән башка да туган якка кайтып йөри.

5 **Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?**

– Алай дип әйтмәс идем. Әнкәйнең җиде килене булды. Җидесе җиде гаиләдә тәрбияләнеп үскән – җидесе җиде төрле. Әмма дуслар! Без дус булгач, алар да үзара якын. Әнкәй барлык киленнәр белән дә уртак телне тапты. «Улым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла» төшенчәсен әнкәй бик матур, нечкә һәм төгәл итеп уздыра белә иде. Ул беркайчан киленнәренә сүз әйтмәде. Фәкать безгә генә әйтер иде. Әмма киленнәр ишеткәч: «Кемгә әйтте ул моны – миңамы, улынамы?» – дип, бик озак уйлый торганнар иде. Алар әнкәйне чын мәгънәсендә ихтирам итте, хәзер дә бик сагынып искә алалар.

6 **Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?**

– Мал табу төшенчәсе бүгенгә көндә дуамаллык формасын алып бара. Чаманы белмәү диган нәрсә еш очрый. Безнең күрше Миргалифан абзый бар иде. Бик укымышлы кеше иде. Үзәктә чыга торган бөтен газета-журналларны алдырды. Ул гел бер сорау бирә иде: «Патша ничә коштабак аш ашыймы икән? Мин менә берне генә ашыйм...» Элек җәмгыять тормыш асылын шулай итеп куйган: ир – табучы, хатын аны дөрес итеп бүлүче булган. Һәркем үз урынын белеп яшәгән гаиләләр бүген дә ныграк: ягъни ир – табучы, хатын бүлүче булганда. Бу язылмаган кагыйдә безнең гаиләдә сакланды: әткәйдә дә, бездә дә. Җидебез дә хатыннардан күбрәк алып эшләдек. Һәм бу ир кеше өчен канун булырга тиеш дип саныйм.

7 **Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?**

– Болай да хатын-кыз һәрвакыт үзе белдерә бит инде... Ир-ат кына, ялгышып: «Аны мин таптым, аны мин үземә караттым», – дип уйлый. Юк, һәрвакыт беренче адымны хатын-кыз ясый, ул безне сайлый. Хатын-кызлар мең төрле – безне үзләренә бәйләп куюда да һәрберсенең үз сере. Бу яктан ир-ат хатын-кызга караганда көчсезрәк. Гадирәк һәм беркатлырак.

8 **Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?**

– Мин һәрвакыт «ияләшерсез» дим. Нинди бар – мин шундый: яраклаша белмим. Ияләшә икән, ул миңа иярә, юк икән – кала.

9 **Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?**

– Матурлык туйда гына кирәк диләрме әле халыкта? Тышкы кыяфәт үзгәрүчән бит ул. Күңел матурлыгы, аның чисталыгына игътибар итү – бөтен очракта да отышлырак. Алары кешене гомер буе озата бара. Ул ана сөте белән килә торган әйбер дип уйлыйм.

10 **Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.**

– Хатын-кызның юлын Хак Тәгалә үзе генә белә, диләр... Шуңа күрә аны һәрвакыт аңларга тырышырга кирәк... Мин әйбернең бер урында ятуын, төгәл урыны булуын яратам. Ә хатын азрак күчергәли... Минекен кузгатма, үзеңнекен күчерсәң дә ярый дим. Һәрбер әйбернең төп-төгәл урыны булу вакытны сарыф итмәскә мөмкинлек бирә. Тормыш иткәндә тирәнрәк һәм катлаулырак мәсьәләләр белән эш итәргә, фикер йөртергә вакыт калдыра. Һәрнәрсәнең төгәл урынын белгеләсәң, шул урыннан барып аласың, шунда илтеп куясың. Китереп биргәнне көтеп тормыйсың. Әнкәй безне шулай тәрбияләде.

11 **Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.**

– Башта юл куеп, азактан шушы әйбергә яңадан әйләнеп кайтып, вакыты җиткәч төгәлрәк аңлатсаң – дөресрәк. Берең ишекне – бер ягыннан, икенчең икенче ягыннан тартып яшәп булмый. Син шулай ыгы-зыгы килгән арада тормыш читтән үтеп китәргә дә мөмкин. Кызганыч, андый гаиләләр дә байтак... Әмма принципиаль әйберләр бар: алар турында ирләрчә кистереп әйтә белү кирәк. Монысы – башка мәсьәлә.

12 **Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, арыдым дип, диванда кырын ятып тора.**

– Мин беркайчан хәләл булмаган ризыклар ашамыйм. Әмма ашау-эчүдән проблема да ясамыйм. Аннан, хатыным алып кайтып биргән әйберне җиренә җиткереп әзерли белә. Безнең өйдә төп таләп – өстәлдә сәламәт ризык булырга тиеш. Суыткычлар беркайчан буш түгел. Бөтен нәрсәне дә белгән кешеләрдән алам. Без – авыл балалары өчен түгел инде ул пицца... Безгә натураль, экологик яктан чиста продукт булсын, андыйның кадерен беләбез.

13 **Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан. Бу сезнең ачуны китерәме? Китерә икән, бу хәл белән ничек көрәшәсез?**

– Мин көрәшеп тормыйм: биш минут көтәм дә, чыкмаса, китеп барам. Әйе, киткән чаклар булды. Шуңа күрә аның соңга калганы юк... Дусларның кайберләре: «Хәзер киләбез», – дигәч тә, бер-ике сәгатьтән килеп төшәргә мөмкиннәр. Алар өчен ул гадәти күренеш. Минем өчен биш минут алдан барып куюым, биш минут соңга калып килүгә караганда хәерлерәк. Әлбәттә, тормышта синнән генә тормый торган хәлләр дә була. Юлдагы бөкеләр, мәсәлән...

14 **Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә. Сез алган бүләкләрнең иң ошаганы һәм ошамаганы?**

– Бүләкне зурга-кечкенәгә, ошый-ошамыйга бүлмим – миңа мөнәсәбәт кадерлерәк. Бүләк – бүләк инде ул... Юлда күп йөрим – күчтәнәчсез кайтканым юк. Алган әйберләремне ошаталар. Кытайдан хатынга, кызга, киленгә шарфлар алып кайткан идем менә, яраттылар.



Астигматизм чир түгел

«Баласында астигматизм булуын белгән әти-әниләр югалып кала, хафалана башлый. Чирләрнең халыкара классификациясендә астигматизм дигән сүз гомумән дә юк. Астигматизм – чир түгел, ул баланың туганнан соң күз рефракциясенең үзенчәлекле үсеше», – ди Республика балалар клиникасы офтальмология бүлегенең югары категорияле офтальмологы, Татарстанның атказанган табибы Наилә ХӘБИБУЛЛИНА. Бүгенге сүзебез дә балаларда еш очраучы астигматизм күренеше хакында булыр.

Кешенең күзе үскән чакта нормаль рефракциягә ирешеп, соңыннан шуны озак еллар дәвамында саклау өчен программалаштырылган. Нормаль рефракцияне – күзнең оптик системасында яктылык нурларының сыну процессын контрольдә тотучы механизмнар күзнең челтәр катламында урнашкан. Әлеге катламның үзәк чокыры балага 3 яшь тулганда гына формалашып җитә. Сәламәт күзләр яктылык нурларын челтәр катламның бер ноктасына җыя. Астигматизм күзәтелгәндә, ул нурлар бер фокуска җыелмый. Яңа туган балаларның күзләре камил түгел, шул сәбәпле, аларда астигматизм бик югары була. Алты айларга күзнең мөгез катлавы тыгызлана төшә, астигматизм да кими. Шуңа күрә дә без, табиблар, үзара аралашканда яңа туган балаларның әти-әниләренә астигматизм турында әйтмәскә дип килешәбез. Югыйсә алдан хафалана, кайгыра башлыйлар, дәвалау юлларын эзлиләр.

Баланың күзләре белән ниндидер проблема барын игътибарлы әти-әни үзе дә тиз сизеп ала. Әйтик, кечерәк балаларның рәсемнәр караганда күзләре яшьләнү, кызару, еш кына баш авыртудан зарлану астигматизм билгеләре булырга мөмкин. Укучы балаларда ул хаталы язу, тактадагы язуларны дөрес укымау, язганда юл өстенә яки юл астына төшеп китү кебек билгеләрдән күренә. Астигматизм булганда әйберләрнең чикләрен бала ачык итеп күреп бетерми. Мәсәлән, нокта аңа сызык яки овал булып күренә, укыганда хәрефләрне бутый... Яхшырак күрү өчен ул башын боргалап, үзенә уңайрак позиция эзләргә яки күзләрен кысарга мөмкин. Болар барысы да баланы күз табибына күрсәтеп, күзнең күрү үткенлеген һәм рефракциясен тикшертү өчен җитди сәбәп булып тора.

Һәр төр астигматизм да дәвалауны таләп итми. Мәсәлән, 1,5 диоптриягә кадәрге симметрияле астигматизм күзнең күрүенә берничек тә йогынты ясамый, аңа коррекция дә таләп ителми. 1,5 диоптриядән күбрәк булып, бала үзенең ничек күрүе турында дөрес итеп әйтә алырлык яшьтә икән, ул очракта инде, әлбәттә, коррекция кирәк. Астигматизм күзәтелгәндә цилиндр пыялалы күзлек яки линзалар билгеләнә. Күзлек кия башлагач, баланың бер-ике көн башы авыртырга мөмкин. Гадәттә, ул тиз үтә. Озакка китсә, димәк, линзалар дөрес сайланмаган. Олылардагы астигматизмны операция ярдәмендә коррекцияләр, әмма балаларга операция билгеләнми. 18 яшьләренә кадәр күз әле үсеп, формалашып җитми.

Астигматизм килеп чыгуның сәбәпләре күп. Күп очракта ул нәселдән дә килә. Әти-әнисенең күз белән бәйле проблемалар булса, балада да шул ук проблемалар күзәтелү ихтималы зур. Баш һәм күз белән бәйле травмалар, баланың казналыгы дөрес формалашмау шулай ук астигматизмга китерә ала.

Тагын бер сәбәп – күрү гигиенасын үтәмәү. Баланың артык якын килеп телевизор каравы (хәзер инде телефоннарга текәлеп утыралар), караңгыда дөрес әзерләве яки китап укуы күзләргә җитди нагрузка тудыра.

Бернинди җитди сәбәп булмаса да, баланы табибка күрсәтүне гадәткә кертегез. Вакытында коррекция билгеләп, астигматизмны кисәтергә, хәтта бөтенләй бетерергә дә була.

Табиб киңәше

- астигматизмны кисәтү өчен яктылык режимын үтәү мөһим. Баланың өстәле тиешенчә яктыртылырга тиеш, әмма артык көчле яктылык шулай ук зыянлы;
- баланың күзләрен зур көчәнешләрдән саклагыз. Ярты сәгать укыганнан соң, күзләрен йомгалап, әле якынга, әле еракка карап, күз гимнастикасы ясауны гадәткә кертегез;
- күзләр арып китсә, аларны йомып, бармак битләре белән күз алмасына җиңелчә генә массаж ясагыз;
- сабый балаларның коляскасы яки караваты өстенә уенчыкларны артык якын элмәгез. Баланың йөзе белән уенчык арасында 30–40 см ара калсын.



«Кояш витамины» кытлыгы

Балачакта әлеге витаминның тәмен татымаган кеше сирәктер. Үскән чорда безгә аны кашык белән каптыралар иде. Халык телендә «балык мае» дип йөртелгән бу витамин балаларга гына түгел, урта һәм өлкән яшьтәгеләр өчен дә мөһим. Д витамины кытлыгы сөякләр зәгыйфьлегенең генә түгел, җитди чирләрнең дә сәбәпчесе булырга мөмкин. Республика медицина профилактикасы үзәгенең гигиена тәрбиясе табибы Роза АЛИМОВА белән Д витамины хакында сөйләшәбез.

Бу витаминга иң беренче сөякләр һәм тешләр сизгер. Озак вакытлар организм аңа кытлык кичерсә, кариес, сколиоз, буыннар сызлавы күзәтелергә, остеопороз чире башланырга мөмкин. Сөякнең ныклыгы кимегәнлектән, җиңелчә генә егылулар да куркыныч тудыра.

Д витамины кытлыгы хатын-кызларга да ир-атларга да яный, әмма хатын-кыз организмы аны аеруча авыр кичерә. Җенес гормоннары синтезында катнашканлыктан, аның тиешле күләмдә булуы бик мөһим. Д витамины җитешмәү күрем циклының бозылуына китерергә мөмкин. Шушы витамин җитмәүдән күкәй күзәнәкнең өлгерүе туктала. Нәтиҗәдә, яшь ханымнарның бәбигә уза алмавы күзәтелә.

Д витамины хатын-кызларның матурлыгын саклаучы да әле ул – тән тиресе, чәчләр, тырнаклар торышы өчен җавап бирә. Тырнаклар сынса, катлам-катлам булып купса, чәч коелып интектерсә, тән тиресе купшакланса, корыса – организмда әлеге витамин аз дигән сүз. Ул шулай ук күзәнәкләрнең үсеш-бүленешен контрольдә тотуда да мөһим роль уйный. Хәтта яман шеш авыруы килеп чыгуны да кисәтә. Ә иң әһәмиятлесе – Д витамины иммунитетыбызның ныклыгы өчен кирәк.

Йокысызлык, аппетит булмау, хәлсезлек, тиз ару – боларның да сәбәбе әлеге дә баягы шушы витамин кытлыгыннан. Тирләү, хәтер начарлану кебек билгеләрнең барлыкка килүе ихтимал.

Аның нормадан аз булуы психологик халәттә дә чагыла. Кәеф үзгәрү, күңел төшенкелеге, апатия – менә аның билгеләре. Организмында Д витамины җитмәүчеләр салкын тиюгә һәм гриппише чирләргә тиз бирешүчән. Ир-атларда исә ул симерүгә, көзән җыеруларга китерә.

Д витаминының күп өлешен организм үзе синтезлый. Ләкин бер төп шарты бар: ул бары тик кояш нуры җитәрлек булганда гына үзләштерелә ала. Менә шуның өчен дә урамда йөрүнең, кояшта кызынуның әһәмияте зур.

Моны белү мөһим:

- Кыска көн төбәгендә яшәүчеләр өчен Д витаминының көндәлек нормасы 7,5 мкг. Хатын-кызларга климакс чорында һәм 60 яшеннән узгач, 15 мкг күләмендә таләп ителә.
- Организмның Д витаминын үзләштерүе эчәклекнең сәламәтлегенә дә бәйле. Дисбактериоз, глютенга аллергия, муковисцидоз булганда, ул начар үзләштерелә.
- Д витамины белән дәваланганда ысланган, маринадланган һәм майлы ризыклардан тыелып торырга кирәк. Шулай ук составында кофеин булган эчемлекләрне дә кулланмый торсаң яхшы.

Кызыну өчен иң яхшы вакыт булып 11–15 сәгатьләр арасы санала. Ләкин кызынырлык кояшлы көннәр безнең полосада алай ук күп түгел. Хәтта җылы, кояшлы якларда яшәүчеләргә дә ультрашәмәхә нурларның җитешмәве ачыкланган.

Әлеге үтә дә мөһим витаминның бер өлешен без ризык белән дә үзләштерәбез. Азык-төлек арасында диңгез балыгы, икра, сөт ризыклары, каты сыр, атланмай, эремчек, тәрәч балыгының бавыры, терлек бавыры, йомырка сарысы Д витаминына бай санала.

Үзегездә югарыда саналган билгеләрне барлап, Д витамины кытлыгыннан шикләнсәгез дә, белер-белмәс дәваланырга ярамый. Шул ук вакытта Д витаминының кирәгеннән артык булуы күп очракта зарарлы булырга да мөмкин – йөрәк, бавыр, бөер эшчәнлегенә зыян килүе бар.

Д витамины төрле формаларда җитештерелә – май тамчысы, судагы эремәсе, таблеткалар рәвешендәгесе. Кемгә нинди формадагысын кулланырга кирәклеген табиб хәл итә. Шуңа күрә витаминны куллана башлаганчы башта табиб белән киңәшү мәслихәт.

Таҗикча люля-кебаб

Памир тавы, зәңгәр күлләр, уңдырышлы үзәнлекләр, җиләк-җимеш бакчалары, тарихи шәһәрләр, көнчыгыш кунакчыллыгы... Монда башка мәдәнияттән кергән бер әйбер дә юк диярлек. Шау-шулы мегаполислар да, очлары болытларга тигән таш йортлардан торган шәһәрләр дә әле төзелмәгән. Таҗикстанда табигать үзе хакимлек итә!
Таҗик гаиләсенә кунакка буш кул белән килү каралмаган. Күчтәнәчкә татлы ризык яки чәчәк алыгыз. Кунакларны кабул иткәндә алар беренче эш итеп кулны юып, сөртергә чиста сөлге тәкъдим итәләр. Юеш кулны һавада селкү өй хуҗасына хөрмәтсезлек билгесе санала. Бу халыкның гореф-гадәтләрен белеп торырга кирәк, чөнки таҗиклар үзләренең йолаларын бик хөрмәт итә.
Таҗиклар матур, төсле тукымадан тегелгән мамык ястыкларга утырырга ярата. Бу ястыкка кырын ятарга яки аякларны алга сузып утырырга ярамый. Идәнгә эскәтер җәелгән булыр. Ашар алдыннан Аллаһка рәхмәт, килгән кунакка хөрмәт белдереп дога укыла. Аннары җыелган кунаклар арасыннан иң яше чынаякларга чәй ясый. Башта үзенә ясаганына да гаҗәпләнергә кирәкми, элек-электән килгән гадәт бу: эчемлекнең агулы түгел икәнен башкаларга шул рәвешле исбат ителә. Ипи таҗик өендә иң изге ризык санала. Ипи валчыкларын чәчмәскә тырышыгыз. Таҗик кабартмасын кисәргә ярамаганын да истә тотыгыз, аны ике куллап сындырырга гына кирәк. Табигый сыйларга өстенлек биргән таҗикларның аш-сулары Урта Азия халыкларныкы белән бик охшаш. Ләкин үзләренә генә хас үзенчәлек тә байтак! Лалә чәчәкләре яки беренче умырзая бәйрәмендә алар пылау, төрле камыр ризыклары пешерергә ярата. Ә итле ризыкларны аеруча оста әзерлиләр – күбрәк Корбан бәйрәменә, туйларга пешерәләр. Куватали НӘЗИРОВ – пешекчеләр нәселеннән. Бабасы, әтисе, хәзер инде улы да – аш-су осталары. Ул безгә сыер итеннән таҗикча люля-кебаб әзерләргә өйрәтте. Люля-кебаб учакта, кайнар күмер өстендә әзерләнә.





Кирәк:
- 1 кг сыер ите;
- 150–200 г эч мае;
- уртача зурлыктагы 2 баш суган;
- тоз, борыч;
- кориандр, зира аш тәмләткечләре;



Фото: Анна Арахамия

Эш барышы:

■ Ит, майны ваклап турап, аш тәмләткечләре белән бутыйбыз да бер төнгә морозилкага куябыз. (Итне күбрәк тә алырга була, без бер кило исәбеннән эшләдек.)

■ Иртән итне морозилкадан алып, суган кушып, иттарткычтан чыгарабыз.

■ Фаршны кисәкләргә бүлеп, тимер шампурга кигертәбез һәм фотодагыча аерым формага кертәбез.

■ Шампурларны кайнар күмергә тезеп, 15 минутлап кыздырабыз. Көеп китмәсен өчен шампурларны бик еш әйләндереп торырга кирәк.

■ Пешкәч, люля-кебабларны зур тәлинкәгә тезеп, янына кыяр-помидор, түгәрәкләп туралган суган, яшел тәмләткечләр белән өстәлгә чыгарабыз.

Тәтен һәм ит исе аңкып торган сусыл люля-кебаб һәр бәйрәмнең иң тәмле бизәге була ала!
Вах!



Люля-кебаб белән ашар өчен томатлы соус

Кирәк: 1 баш суган; 1 данә лимон; ярты стакан су; 2 тырнак сарымсак; чили борычы; 2 аш кашыгы зәйтүн мае; 200 г томат.

Суганны ярым боҗралап турыйбыз, лимон согы сибеп, 1 сәгатькә калдырабыз. Чили борычын һәм сарымсакны зәйтүн маенда алтынсу төскә кергәнче кыздырып алабыз. Шуңа ярты стакан су, томат салып яхшылап болгатабыз һәм 5 минут утта тотабыз. Суганны аерым савытка алып, өстенә үзебез әзерләгән кайнар соусны салып, люля-кебаб белән өстәлгә куябыз.
Ашларыгыз тәмле булсын!

Мастер-классны оештыруда ярдәм иткәннәрә өчен Татарстан халыкларының Дуслык йортына рәхмәт белдерәбез.

PRESSA

Спагетти яратсагыз, ләкин углеводларга бай булмаган ризык белән тукланырга теләсәгез – бу рецепт сезнең өчен! Бу юлы Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА спагеттины цукини – ташкабакның бер төреннән пешерергә тәкъдим итә. Аны әзерләр өчен әллә ни күп вакыт та кирәкми, ә менә тәме ошамый калмас.



Ташкабактан – спагетти

Цукинины төрлечә турарга була, ләкин иң яхшы ысул – спагетти өчен махсус кискеч куллану. Кибетләрдә яшелчәләр турый торган махсус пычаклар да сатыла. Кул астында беренчесе дә, икенчесе дә булмаса, кишерне озын саламлап чыгара торган угыч та ярап тора.

Цукинины юып, угычтан озын токмач рәвешендә чыгарабыз. Әлеге ризыкны пешерәсе юк, ул шуның белән кызыклы да – барлык витаминнары һәм файдалы матдәләре саклана.

Кыргычтан чыккан пастаны – безнеңчә әйтсәк, токмачны, соус белән катыштырып, 2 сәгатькә суыткычка куябыз.

Соусларның төрлесен ясарга була, без исә өч төрле вариантын тәкъдим итәбез.

Беренче ысул. Томат, тоз, сарымсак һәм күңелегезгә хуш килә торган тәмләткеч үләннәрне, мәсәлән, орегано, рәйхан, тимьян (үләннәрнең әзер катнашмасын да алырга була, әйтик, Италия яки Сицилия үләннәре җыелмасы) блендер белән ваклыйбыз. Токмачны 2 цукинидан әзерләсәгез, 1 томат та җитә. Соусны спагеттига кушып, бер аш кашыгы зәйтүн мае салабыз, тәменчә тоз өстибез дә яхшылап болгатабыз.

Икенче ысул. Кешью чикләвеген 3-4 сәгатькә сугага салып куябыз. Чикләвекне, авокадо, сарымсак, аш тәмләткеч үләннәрне блендерда ваклатабыз, тоз өстибез. Соус куерак килеп чыкса, аз гына су кушабыз.

Өченче ысул. Соусның монысы да кешью чикләвеге белән ясала. Блендерда чикләвек, суган, сельдерей, кинзаны ваклатып, аз гына лимон суты һәм тоз өстибез.

Чикләвекле соуслардан каймак тәме килә һәм алар крем кебек йомшак була. Кешью чикләвеге тәмле булу белән бергә, витаминнарга һәм минералларга, аминокислоталарга да бай әле ул. Аның составында туендырылган май кислоталары булу да бу ризыкның кыйммәтен арттыра. Менә шулай тиз һәм җиңел генә итеп файдалы да, тәмле дә ризык әзерләргә мөмкин!

Фото: Камилә Димөхәммәтова

Кучкар. Яңа идеяләр керемнәрегезне арттырырга ярдәм итәр. Көнләшүчеләр дә булыр. Бәхет тынычлыкны ярата дигән гыйбарәне истән чыгармагыз.

Үгезбозау. Җайлы һәм тыныч ай. Катлаулы мәсьәләләр сезнең файдага хәл ителәчәк. Хезмәттәшләрегез алдында артыгын сөйләмәгез. Ялгыз Үгезбозауларны язмышларын үзгәртерлек романтик очрашулар көтә.

Игезәкләр. Ниндидер артык зур үзгәрешләр, яңалыклар көтәсе түгел. Көчегезне сәламәтлегегезне ныгытуга, шәхси мөнәсәбәтләрне җайлауга тотсагыз әйбәтрәк.

Кысла. Эштәге күңелсезлекләрне өйгә алып кайтмагыз. Гаиләдәге атмосфера да сезнең кәефкә бәйле булачак. Зур мөмкинлекләр бирә торган яңа эш табу мөмкинлеге бар.

Арыслан. Элеккеге дусларыгыз, аралашып йөри торган танышларыгыз белән саграк булырга киңәш ителә. Китаплар, күңелне күтәрә торган кинолар карап, буш вакытыгызны тынычлыкта уздырырга тырышыгыз.

Сөмбелә. Шәхси тормышыгызда көтелмәгән уңай үзгәрешләр килеп чыгар. Язмыш бүләге булырдай кешене очратырга мөмкинсез. Ә менә гаиләле Сөмбеләләрнең сәяхәткә чыгып китүе бар. Акчаны саклык белән тотыгыз!

Бизмән. Эчке энергиягезне саклагыз, юкка-барга хәсрәтләнмәгез. Чынлыкта сезнең өчен бик әйбәт ай килә. Матераль хәлегез яхшырыр, эшегездә югары дәрәҗәләргә ирешү мөмкинлеге туар. Күңелсез кебек тоелган эшләрдән ваз кичмәгез, файдасы – көткәннән дә күбрәк булачак.

Чаян. Елмаюыгыз белән күпләрнең күңелен яуларсыз: яңа дуслар, сезгә гыйшык тотучылар, бизнеста ышанычлы партнерлар барлыкка киләчәк. Ай ахырында сәяхәткә чыгып китүегез ихтимал.

Укчы. Йолдызлар барлык яктан да уңыш һәм бәхет вәгъдә итә. Һөнәри яктан үсү мөмкинлеген кулдан ычкындырмагыз. Үзегезнең көчегезгә һәм сәләтегезгә ышаныгыз!

Кәҗәмөгез. Күп тырышлык куеп башкарган эшләрегезнең нәтиҗәсен күрерсез. Бу айда сезнең өчен алтын кагыйдә – эмоцияләрегезне тышка чыгармагыз! Мәхәббәттә компромисска юл куегыз.

Сукояр. Киләчәккә яңа максатлар билгеләр вакыт. Олыларның зирәк киңәшләренә колак салыгыз, гаилә конфликтларыннан сакланыгыз. Көндәшләрегез белән кискен сөйләшүләр булырга мөмкин.

Балык. Килеп туган четерекле хәлләрне вакытында хәл итә торган чак. Табибка баруны кичектереп торган булсагыз – бу айдан да калдырмагыз. Яшүсмер балаларыгыз белән җайлап кына сөйләшегез, аңлашылмаучанлыклар килеп чыкмасын.

зирәк кешедән зирәк сүз

КАРТЛЫК – ЗИРӘКЛЕК

Бер илнең патшасы сиксәннән узган картларны биек тауга илтеп куярга боерган. «Алардан безгә бер файда да юк», – дигән ул. Әнә шулай итеп, бик күпләр тау куышында ач бүреләргә азык булган.

Ике ул үстергән атага да беркөнне сиксән тулган. «Фәрманны үтәмәсәгез, үзегезне җәзага тартырлар, мине тау куышына илтегез инде», – дигән ул. Патшага каршы барып булмый: уллары әтиләрен тауга алып менеп киткән. Юл буе карт агач ботакларын сындырып, сукмакка ташлый барган. «Нишлисең, әти?» – дип сораган аннан балалары. «Кайтасы юлыгызны билгеләп барам», – дигән ул.

Уллары әтиләренең зирәклегенә сокланып: «Ул безгә бик кирәк бит әле, ник без аны монда илтәбез соң?» – дип уйлашканнар да, кире алып кайтып китеп, базга яшергәннәр.

Беркөнне патша елга буенда йөргәндә су төбендә ялтырап яткан кыйммәтле таш күргән. Хезмәтчеләре суга чумып эзләсәләр дә, ташны таба алмаганнар. «Су төбендә түгел, агач башындагы кош оясында ул зәбәрҗәт», – дигән теге карт бу хәлне ишеткәч. Егетләр патшаның хезмәтчеләренә кош оясын карарга кушкан. Таш, чынлап та, ояда булган.

Патша егетләрне үз янына чакырткан: «Моны кайдан белдегез, дөресен әйтегез», – дигән ул. «80 яшьлек әтиебез әйтте», – дияргә мәҗбүр булган алар. Патша уйга калган: «Өлкәннәрдә яшьләрдә булмаган зирәклек, тәҗрибә бар икән бит. Алар безгә әле бик тә кирәк икән!» Һәм икенче көнне патшалыкта яңа фәрман яңгыраган: «Өлкәннәрдән зирәклеккә өйрәнергә!»

* * *

Көч һәм чибәрлек – яшьлек бизәкләре; картлыкныкы исә – зирәклек.

Демокрит (борынгы грек философы).

Кеше, өметләнүдән туктап, хатирәләр белән яши башлагач картая.

Фрэнк Зандерс (Америка язучысы, галим).

Олы кеше була белү – сәнгать, һәм ул бөтен кешегә дә бирелмәгән.

Франсуа Ларошфуко (француз язучысы).

Гаярьлек үлгән көннән картлык башлана.

Андре Моруа (француз язучысы, галим).

Картлыкта гамәлләр аз булса да, ачышлар күп.

Юрий Нагибин (рус язучысы, журналист).

Барыбыз да озак яшәргә тели, әмма беребезнең дә карт буласы килми.

Джонатан Свифт (ирланд язучысы).

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Лилия ГӘРӘЕВА, Раилә Хәялиева әзерләде.





РӘССАМ КУЛЫНДА... МӘДӘНИ КОДЛАР

С

– «Сөембикә да Винчи»?!

– Әйе, Сөембикә дә, Леонардо да Винчи да бер чорда яшәгәннәр. Ул вакытта Италиядә Ренессанс, бездә... – Татар рәссамы Булат Гыйльвановның остаханәсендә тынлык урнаша. Сүзсез генә аңлашыла торган уйлар... Тарих сандыгына шул рәвешле ачкыч ярата белә рәссам. Булатның иҗатындагы романтик төсмерләр белән сурәтләнгән тарихи реализм үзенең археологик чынлыгы белән ышандыра. Идел буе Болгар дәүләте, аның башкаласы шәһре Биләр, Алтынчәч... «Иҗат кешеләре өчен бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы болар. Эш чыганагы. Иртәме-соңмы, кем икәнлегебезне белер, нинди икәнлегебезне аңлар өчен без бу материалны үзләштерергә тиеш. Тәмам рефлексия һәм анализ ясаганчы. Чөнки ике урындыкта берьюлы утыру мөмкин түгел», – ди рәссам, Алтын Урда чоры сугышчысын сурәтләгән эшенә ишарәләп. Аристократ яугир руслар «татарник» дип атаган шайтан таяклары үскән дала буйлап яуга китеп бара, йөзендә – хәсрәт... Рәссам белән килешми мөмкин түгел: Булат Гыйльвановның «Алтынчәч» сериясен генә искә төшерик. Моннан шактый еллар элек рәссам аны «Алтынчәч» риваятендәге кызлар санынча 40 эштән торачак дип ышандырган иде. Эш дәвам итә...

2017 елда археолог Константин Руденко үсмерләр өчен «Биләр. 1236 елның көзе» дигән китап чыгарган иде.

– Бу китап Болгариядә болгар телендә дә басылып чыкты. Анда Идел буе Болгар дәүләте тарихы белән кызыксыну көчле, безнең халыкны да алар тугандаш халык дип саный, – ди рәссам.


Китапта Биләрнең монгол яуларына каршы тору тарихы археологик материалларга таянып сурәтләнгән. Анда рәссамның 18 иллюстрациясе урын алган. Китап белән танышканнан соң, аларны иллюстрация генә итеп кабул итәсе килми башлый: һәркайсын мөстәкыйль эш итеп күрәсе килә.

2018 елда Татарстан китап нәшриятында чыккан «Татар халык әкиятләре» китабы да Булат Гыйльванов рәсемнәре белән бизәлгән...


Б. Урманчы, М. Җәлил исемендәге премияләр лауреаты Булат Гыйльвановның милли тарихны сурәтләгән реалистик эшләреннән тыш, икенче бер юнәлештә иҗат итүе дә мәгълүм. Рәссам үзе әйтмешли, «күңел өчен» язылганнары. Сәнгать белгечләре аны этнофутуризм дип бәяли. Мәсәлән, аның «Алмалар» триптихына тукталабыз. Күптәнге ул, рәссам аны шактый еллардан соң берәүнең шәхси коллекциясеннән яңадан үзенә сатып ала. Беренчесендә гашыйклар парлашып тәмләп чәй эчә:

– Безнең халык өчен чәй эчү – үзе бер фәлсәфә. Медитация. Ул чәй эчкәндә генә ял итә. Безнең халык кайнар чәйне чөмереп эчә. Бусы – ингаляция. «Чөмереп» сүзе бездә генә бар. Мин үзем дә чәйне чөмереп эчәм. Алай дөрес түгел, культурасызлык, диләр миңа. Үз культурасын белмәгәннәр сүзе бу...

Ландыш ӘБҮДӘРОВА










Фото: рәссамның шәхси архивыннан һәм Елена Сөнгатова - elena@art16.ru

БУЛАТ ГЫЙЛЬВАНОВ





«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ:

ярты елга – П2204

бер елга – П8299



Татарстаннан читтә яшәүчеләр әлегә «Роспечать» каталогындагы элеккеге индекс буенча языла алалар 73002

2020 елның беренче яртыеллыгы өчен газета-журналларга язылу дәвам итә



Сайтта: www.syuyumbike.ru

ВКонтактеда: vk.com/suumbike

Фейсбукта: www.facebook.com/syuyumbike

Инстаграмда: www.instagram.com/suyumbike_journal

Журналыбызга онлайн режимда : http://podpiska.pochta.ru сайтында (теркәлеп) языларга мөмкин



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була. **iPad** һәм **iPhone** кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.

Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була.

16+

РЕКЛАМА